www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 15 (1431) 19 апрель 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

12

Эшмәкәр, актив җәмәгать эшлеклесе Ринат Исламов җитәкләгән проект авыл мәчетләрен матурлап яктырту белән бәйле.

14

Тарихчы галим Таһир Кәримов Башкортстанның Бакалы районында «башкорт»ларның ничек барлыкка килүен ачыклый.

24

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында хәттат, галим Нәҗип Нәккашның шәмаилләр һәм тугралар күргәзмәсе ачылды.



Хакка илтер юлыбызны һәрчак Ислам нуры торыр яктыртып!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казанның былтыр капиталь ремонт ясалган 1 нче номерлы балалар музыка мәктәбе эшчәнлеге белән танышты.
- Г.Камал театры спектакльләренең видеоязмалары Курск, Оренбург, Пермь, Саранск, Чабаксар, Энгельс, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә кинопрокатка чыга.
- Минзәлә театры артистлары Ютазы, Лениногорск, Азнакай, Нурлат һәм Чирмешән районнарында гастрольләрдә булды.
- Татарстан Язучылар берлеге бинасында «Әдәби карта» конкурсының җиңүчеләрен бүләкләделәр.
- «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә Бөтендөнья татар яшьләре форумы «Татар теле рәисе»н игълан итәчәк.
- 29 апрельдә Бөтендөнья татар конгрессы Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә яшәүче татар активистлары белән берлектә Дубай шәһәрендә Сабантуй оештыра.
- Башкортстанның «Агыйдел» әдәби журналы үзенең гасырлык юбилеена төрле илләрдә басылып чыккан 100 хикәядән торган ике томлык чыгарды.
- Танылган журналист, Татарстан Рәисенең элеккеге матбугат сәркатибе, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Эдуард Хәйруллин 54 яшендә вафат булды.
- «Әкият» курчак театры Саратов шәһәрендә гастрольләрдә Г.Тукайның «Кәҗә белән Сарык» спектаклен татар телендә тәкъдим итте.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ким МИҢНУЛЛИН, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры:

«Гасырлар буе халык күңелендә яшәгән образлар турында сүз барганда, бик сак булырга кирәк. Без нәрсә белән калабыз? Мондый гамәлне бүген безнең файдага эшли дип санамыйм. Кочне, игътибарны аңа әрәм итмәскә иде. Халык күңелендә яшәгән икән, яшәсен. Галимнәрнең дә ышандырырлык дәлилләре җитеп бетми. Биш гасыр элек булган вакыйгалар бит. Катлаулы чорларда яшәгән язучыларыбыз белән дә шул ук хәл».

СЫНАМЫШЛАР

Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була ● Каен суы тәмсез булса – игеннәр уңа ● Усак чәчәге күп булса, арпа уңа ● Үрмәкүч, пәрәвезенә төренеп, почмакта утырса, төнге кыраулар көтелә ● Ай кызарып чыкса, җылыта йә яшенле яңгыр ява.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 31 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 56 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **14 сәгать 25 минут.** Алдагы тугыз көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **40 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **28 апрельдә 15 сәгать 05 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

21 апрель – режиссёр, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Равил Рәхим улы Тумашевның тууына 100 ел (1923–2016).

22 апрель – язучы, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Марат Әмирхан улы Әмирхановка 90 яшь (1933);

– балет биючесе, педагог, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Мансур улы Әхмәтовка 55 яшь (1968) .

25 апрель – шагыйрә Халисә Сәгыйть кызы Мөдәррисовага 70 яшь (1953).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 21, 26, 27 апрель.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(20-28 апрель)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 28 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Индус ТАҺИРОВ

Яратыйк илне, яратыйк туган телне!

Шушы сүзләрне язганда Салават Фәтхетдиновның «мин сине яратам Татарстан» дип җырлавы яңгырап киткән кебек була. Гомумән, бу сүзләр җырда гына түгел, халык телендә ягымлы рәвештә һәрвакыт кабатлана тора.

Башка илләрдән килүчеләр дә Татарстаныбызны ярата. Менә шуларның берсе – Казанга медицина өлкәсендә белем алырга килгән 24 яшьлек һинд кызы Поулами Чаттерджи. «Татарстанны яратам! Биредә татарлар гына түгел, башка бик күп төрле милләтләр яши. Алар үз мәдәнияten, милләтен данлап көн күрә. Бу миндә горурлык хисе уята», – дип әйткән ул. Бәлки, бу кыз татар һәм һинд моңнары арасындагы уртаклыкны тоемлап, татар моңын үз моңыдай яратып кабул иткәндер...

Татарларны аларның гомерлек күршеләре мари, удмурт, чуашлар якын күрә. Бабаларының Казан ханлыгы бәйсезлеген корал тотып үз бәйсезлекләредәй яклап сугышканнарын хәтерләрендә саклыйлар, шушы көннәрне исләренә төшереп, Татарстанны, татарларны хөрмәтләп яшиләр.

Поляклар да Гданьск шәһәрендә татар сугышчысына һәйкәлне юкка гына куймаган. Бу – аларның татарларның илләренең бәйсезлеген саклауга, яшәешенә зур өлеш кертүен тануның якты чагылышы. Чыганакларда Польша Президентының һәйкәлне ачканда татарларга дан җырлаган сүзләрен тыңлаганда, аның тантанада катнашкан әнисенең күзләреннән шатлык яшьләре тамган, дип язылган. Гомумән, Польшада татарларга ихтирам зур. 1939 елны Гитлер гаскәрләре Варшавага бәреп кергәндә татар сугышчылары аны соңгы саклаучылар булып баскан һәм барысы да һәлак булган. Бу хакта поляк хатыннары әле дә елый-елый сөйли...

Татарларга карата җылы мөнәсәбәт Белоруссиядә дә, Финляндиядә һәм Балтик буе илләрендә дә сиздереп тора.

Татар – сикәлтәле юллар аша үтә-үтә, тарихта чарланган халык. Ләкин Чаадаевның «время слепых влюбленностей прошло» дигән сүзләрен онытырга ярамый. Гел горурланып кына яшәү татарга файдага түгел. Аның тарих көзгесенә карап, үз-үзенә тәнкыйди күз белән карап яшәве зарурирак.

Тарих тәгәрмәче берәүләрне күтәрә, икенчеләрне төшерә. 1552 елда татарларның бөеклектән түбән тәгәрәгән чоры башланды. Шул елда башланган коллык аның фаҗигасенә, хәтта Габделбарый Баттал язганча, җәһәннәмгә әверелде. Ул биек кыядан төпсез упкынга очуны хәтерләтә. Нилектән ничәмә-ничә каһанлыклар тоткан татар бүген бер дәүләткә зар-интизар булып яши? Ул нилектән коллык упкынына төшкән?

Төп сәбәбе, Тукай сүзләре белән әйткәндә, татарларның бер-берсеннән көнләшеп, үзара ук атышып яшәве. Бу сүзләр бигрәк тә югары катламга, Камай морза, Шаһгали шикелле дошманга юл күрсәтүчеләргә, үзләренекенә каршы бәрелешләрдә дә катнашучыларга карата әйтелгән. Аларның иң хурлыклы гамәлләренең берсе – ханбикә Сөембикәне дошман кулына тапшыру. Ни кызганыч, атасы Ногай морзасы да аңа ярдәмен күрсәтмәгән.

Сөембикә Казанны, аның халкын җаны-тәне белән яраткан. Рус чыганаклары аның бу сыйфатын сокланып тасвирлый. Ул югары һәм урта катлам кешеләренә дә, кара халыкка да бер тигез ихтирам белән караган, алар турында кайгыртучанлык күрсәтә килгән. Аның шушы сыйфатын казанлылар ханбикә Казаннан киткәннән соң да сагынып сөйли торган булган.

Үткәне үткән инде, аны кайтарып булмый. Әмма бүгенге яшәештә бер-беребезгә ук атуны туктаттыкмы, бердәмлегебез җитәрлекме икән? Җитешсезлекләребез, хаталарыбыз һаман туа тора. Гаиләләрне, балаларыбызны милли рухта тәрбияләү, телебезне гамәлләштерү аксый, бик күп гаиләләрдә рус теле өстенлек итә.

Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге татар телен саклау комиссиясе зур эшләр башкара, төрле чаралар үткәрә. Мөфтиятебез, дин әһелләре бу изге эшкә үз өлешләрен кертә. Йөздән артык мәчетләребездә татар телен өйрәтү курслары эшләп килә. Ләкин гаиләә яшәешенә үтеп керү, балаларны телебезне камил рәвештә өйрәтеп, дөнья мәйданына чыгару гамәле җиңел түгел. Үрнәк алырдай татар телле гаиләләр бар һәм алар саны арта тора.

Тел яңа дөньяга килгән сабыйның канына сеңгән була. Бишектәге баланың теле ана җыры белән ачыла. Ә әби кеше аны әкиятләр дөньясына алып керә, аның телен чарлый, милли хисләрен хәрәкәткә китерә. Бала яшәү мәйданына туган теле һәм туган моңнары белән чыга. «Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән», дип язган Тукай. Тик гаиләнең вазыйфасы баланың теле ачылу белән генә тәмамланмый. Киресенчә, ул катлаулана төшә, чөнки ачылган тел бертуктаусыз баетылырга тиеш. Тукай әйткән әкиятләр баланың телен генә түгел, аның рухи дөньясын да баета, аңарда милли хисләр тәрбияли, аңа халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын сеңдерә. Яхшы белән яманны аерырга өйрәтә. Шундый аналар һәм әбиләр бүген дә күбрәк булсын иде. Халыкта: «Оясында ни күрсә, очканда шул булыр», – дип юкка гына әйтелмәгән. Гаиләдә ана махсус урын алып тора. Үземнән чыгып әйтәм. Анабыз Әминә Каюм кызы безнең өчен якты кояш булды. Телебезне дә ул ачты, туган халкыбызга карата мәхәббәт хисләрен дә ул уятты. Мәктәпкәчә үк укырга да ул өйрәтте, яшәү тәртипләрен дә аның аша белдек. Яхшылыкның яманлыктан өстен булырга тиешлеген дә безгә ул сеңдерде. Киләчәк буын аналар да шундый булсын иде.

Татарлар яши торган башка җирләрдә дә телебезне, гореф-гадәтләребезне гамәлләштерүдә уңышларга ирешкән урыннар бар. Чуашстанның, Удмуртиянең, Пенза, Ульян, Төмән өлкәләренең милли оешмалары бу вазыйфаны зур тырышлык белән һәм уңышларга ирешеп башкара. Акрынлап булса да зур шәһәрләрдә дә татар теле белән кызыксыну арта. Мәскәүдә Рөстәм Ямалеев җитәкчегендәге Татар штабы, Татар һәм төрки халыклар конгрессы бу өлкәдә зур эшләр башкара. Башкаладагы «Умарта корты» исемле татар теле курсларына руслар да йөри.

Мәскәү дигәч, анда элегрәк булган бер вакыйга искә төште. Мәркәзнең иң зур залларының берсендә татарлар оештырган концерт бара иде. Шул вакыт залда утыручы бер рус кешесе чараны алып баручыларга язу җибәрә. Анда: «Телегез искиткеч матур, аның киләчәге зур, мин телегезне өйрәнергә сүз бирәм», – дигән сүзләр бар иде. Югыйсә, бу кешегә татар теленең кирәге дә шул чама гынадыр, әмма аны телебезнең моңлылыгы, ягымлы яңгырашы үзенә гашыйк иткән...

Республикабыз татар гына түгел, башка милләт телләрен дә яшәтү һәм тормышка ашыруның үрнәге булып тора. Ул татар булмаган милләтләрнең киләчәкләрен, телләрен, гореф-гадәтләрен саклап калу өчен мөмкинлекләр тудыра. Халыклар йортында шуңа юнәлтелгән чаралар туктаусыз үткәрелә. Күп чараларда Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үзе дә катнаша.

Татар конгрессы да читтә тормый. Ул да дуслык җепләрен ныгытуга үз өлешен кертә, халыклар дуслыгы – яшәешебезнең нигезе икәнлегеннән чыгып эш итә. Ләкин безнең өчен иң беренче урында тирән тамырлы рус-татар мөнәсәбәтләре. Тарихыбызда үзара бәрелешләр дә, сугышлар да – барысы да булган. Шул ук вакытта халыкларыбызның дуслык һәм татулык тамырлары беренче урынга чыгып, өстенлек итә торган.

Бүген милләтебезнең күтәрелешен ныклы рәвештә булдыру өчен ниләр кылырга кирәк? Һичшиксез, санабызны һәм сыйфатыбызны, гореф-гадәтләребезне саклап, аларны буыннан-буынга тапшыра бару беренче урында булырга тиеш. Казанның үзендә, республикабызда һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә татарлык хисләрен сеңдерү эше балалар бакчасыннан ук башлана, мәктәпләрдә класстан тыш чаралар белән ныгытыла. Дөрес, бу әле хәзергә аерым мисаллар гына. Ләкин алар артыр.

Менә кайберләре. Яшел Үзән шәһәренең 3 нче рус гимназиясендә 2010 елдан бирле «Серле сандык» дигән оешма эшләп килә. Аның «Үз халкын данга күмгән татарлар» дигән музее бар. Шуның эшчәнлеге нәтиҗәсендә укучыларның яртысы туган тел итеп татар телен сайлаган. Араларында рус милләтеннән булган балалар да байтак.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Бердәнбер һәм мәңгелек тәртип

Россия Президенты В.Путин РФ-АКШ мөнәсәбәтләренең бүгенгесе хакында күптән түгел, бу ике илнең яңа дөньяви тәртипне формалаштыруга карашлары төрле булуы сәбәпле, алар хәзер тирән кризис кичерә, дип белдергән иде. РФ тышкы эшләр министры С.Лавров та «Россия1» каналына биргән интервьюсында бу уңайдан, Вашингтонның Украинаны сугыш кораллары белән тәэмин итүен күздә тотып, АКШ һәм Россия сугышның кайнар фазасында торалар, дип әйтте. Шул ук вакытта ул бу ике ил арасындагы бәйләнешләрне дәвам итү кирәклеген искәртте һәм, америкалыларның акылы уянып, диалогны алар яңартуына өмет итүен дә яшермәде. С.Лавров ул чакта, моны күтәргә инде озак калмады, дип тә өстәгән иде. Бу җәһәттән, Ак йортның стратегик багланышлар буенча киңәшчесе Джон Кирби фикере дә бик кызыклы. «Fox News» каналына интервьюсында ул, АКШ Россия белән низагка керми, Украинада исә эчке конфликт бара, дип сөйләгән. Югарыда әйтелгәннәрне уртак мантыйк чылбырына тезеп тә фикер йөртсәк, димәк, АКШ һәм Россия капма-каршы яктан эш итсәләр дә (чөнки карашлары төрле), максатлары уртак (яңа дөньяви тәртип урнаштыру) булып чыга. Мәгълүм булганча, геосәяси максатлы андый тәртипләр I һәм II Бөтендөнья сугышларыннан соң да урнаштырылган. Димәк, алар вакытлы гына була ала һәм бу яңа тәртипкә дә кагыла. Ә рухи кризис шартларында геосәяси максатлы андый тәртип кешелекне глобаль фаҗигагә дә китерергә мөмкин. Мондый хәл инде яңа дөньяви тәртипнең төп максатын да билгели: мөмкин кадәр тиз арада кешелекнең илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүен тәэмин итү.

Хәер, кешелек өчен бердәнбер һәм мәңгелек андый тәртип Илаһыбыз ихтыяры вә кодрәте белән әле яралтылышта ук бар ителгән һәм хәтта тәкъдир тактасына ук язылган. Ул абсолют кыйммәтләр системасында һәм илаһият кануннары буенча яшәүне күздә тота. Ә андый яшәү рәвешенең төп максаты – инсаниятнең рухи үсешен рәсүли аң югарылыгына күтәрү аша, Җирдә аның гармонияле яшәешенә ирешү. Тик кешелек дөньясы аны үтәргә әле дә әзер түгел. Юкса, фәлсәфи бәйлелек тә монда гади: кешелек аңы моңа никадәр иртәрәк ирешсә, аның Җирдәге яшәешне җайга салу мөмкинлеге дә шуның кадәр зуррак булачак. Гадәттә, кешелек тарихын аңлау һәм аңлатуда шарт фигыльләрне кулланмаска тырышалар. Әмма хакыйкатьне дөрес аңлауда кайчакта алар да файда итә ала. Монда да нәкъ шул очрак, күрәсең. Чөнки, хактан да шулай: әйтик, әгәр кешеләрнең рухи үсеш дәрәҗәсе әле XX йөзгә кадәр үк рәсүли аң югарылыгына күтәрелгән булса, I һәм II Бөтендөнья сугышлары, мөгаен, башланмаган да булыр иде. Әмма, ни кызганыч, Җирдә әлегәчә шайтани рух өстенлек итә.

Мәгълүм булганча, диннәр, җәмгыяви институт буларак, халыкларны илаһи канунлар кысаларында тоту ниятендә кертелгән. Шуның белән бергә, алар һәрчак сәяси ихтыяҗларга да хезмәт иткән. Кешенең рухи үсеше исә җәмгыяви тәрбия аркылы тәкъдирләнгән. Аллаһ аны яралтылышта бертөрлелекне күптөрлелеккә җибәрү (инволюция) һәм аңадан элеккеге халәнә (бертөрлелеккә) кайту (эволюция) шәкелендә ниятләгән. Мөшриклек диннәре исә Җир аңыннан Күкнекенә борылуны тәэмин итү өчен индерелгән. Ә кешелек дөньясы бүген инде үзенең эволюцион хәрәкәтендә, әлеге илаһи борылыш чорын тәмамлап, Аллаһка кайту юлының соңгы этабына күчеш кичерә. Әлбәттә, мондый җаваплы чорда төрле диннәрнең илаһият кануннары буенча (киң мәгънәдә) яшәүгә әзерлек дәрәҗәсен белү дә мөһим. Моны ачыклау өчен, кайбер конфессия башлыкларының бу хактагы фикерләренә дә игътибар итик. Рим Папасы Франциск Пасха уңаеннан үзенең традицион юлламасында, халыкларны үзара ышаныч урнаштырырга һәм тынычлыкка омтылырга чакырган. Ул шулай ук, кешеләр арасында аңлашу вә тынычлыкка ирешүне сорап һәм барлык сугышлар да глобаль дәрәҗәдә туктатылуын үтенеп, гыйбадәт кылган. Мәскәү һәм бөтен Россия патриархы Кирилл үзенең Пасха юлламасында хәтта Украинадагы низагны да искә төшергән. Илаһтан исә ул, кардәш халыкларның тән вә җан яраларын төзәтүен, кайгыларын басуын, шулай ук аларга ныклы һәм гадел тынычлык бүләк итүен дә сорап, гыйбадәт кылган. Тик аның карашлары, сәясәткә бәйле рәвештә, гел үзгәреп тора. Әйтик, элегрәк ул, Россияне Көнбатыш белән хәрби бәрелешкә уртак кыйммәтләрнең булмавы һәм Көнбатышта христиан кыйммәтләренең дә калмавы этәрде, дип әйткән иде.

Күренә ки, христианнарда әлегә сүз Җирдә барлык диннәр өчен дә уртак булган илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү турында бармый. Мөселманнарда да бу нәкъ шулай. Ислам руханиларының 7-10 декабрьдә Мәскәүдә үткән «Гаделлек вә уртачалык: дөньяви тәртипнең илаһи принциплары» дигән халыкара форумы нәтиҗәләре моны ачык күрсәтте. Димәк, илаһи яшәешкә күчүнең механизмнарын булдыру эше тәкъдир әмерен көтә.

Фоат УРАЗАЙ.

«Нәфисәбез иртәрәк китте...»

Халыклар дуслыгы йортында ТАССРның халык артисты, кабатланмас тавыш иясе Нәфисә Василованың (Анастасия Петровна Васильева) тууына 80 ел тулуга багышланган «Үз илемдә» дип исемләнгән искә алу кичәсе узды. Кичә өченче ел «Җырчы Җәкәү» йортында эшләп килүче «Якын дуслар җыелышкач» дигән проект кысаларында оештырыла.

Концертта Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле, керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле, Теләче районы Субаш авылыннан «Нардуган» фольклор ансамбле, Казаннан «Казансу» ансамбле чыгыш ясады.

Кичәгә җырчының хезмәттәшләре, иҗатташ дуслары һәм аның иҗатын хөрмәт итүчеләр чакырылган иде. Тамашачылар чын мәгънәсендә Нәфисә Василованың җанатарлары булды, чөнки алар аның репертуарындагы җырларны тыңлап кына утырмады, ә кушылып та җырлады.

Н.Василова 25 ел җыр һәм бию ансамблендә совет, татар композиторлары, халкыбызның озын җырларын башкарып, Татарстаныбызның төрле районнарында, авылларында, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә чыгыш ясаган.

«Мин бөхетле заманда эшләдем. Минем белән янәшәмдә яраткан, мин бик югары бәяләгән кешеләр бар иде. Мин талантлы шәхесләр үстерү өчен бөтен иҗатымны багышлый алган заман иде ул. Нәфисә Василова шундый шәхесләрнең берсе булды. Ул үзенчәлекле контральто (иң түбән хатын-кыз тавышы) тавышы белән бер үк вакытта бик халыкчан һәм бик югары академик башкару осталыгы белән таң калдыра иде», – диде Россиянең халык артисты Лима Кустабаева.

«Нәфисә ике генә әсәр – Хәсән Туфан һәм Марс Макаровның «Киек казлар» һәм Солтан Габәши белән Әхмәт Ерикәйнең «Кәккүк» җырларын башкарган гына булса да, ул Татарстан сәнгате тарихында бәяләп бетергесез тирән эз калдырган шәхес буларак искә алыныр иде. Аның өстәвенә репертуарында бик күп халык җырлары да бар. Безгә Нәфисәнең бик матур, бай иҗади мирасы калды, әмма хәзерге көндә аның аудио-видеоязмалары бик сирәк яңгырый, ә бит ул халкыбыз өчен чын байлык, кыйммәтле хәзинә», – дип өстәде ул.

«Мин бик күп еллар Нәчтүк белән кулга-кул тотынып эшләгән кеше. Ул иртәрәк китте. Халыкта бер сүз бар: «Сыерны савалар-савалар да, сөте беткәч, ит комбинатына тапшыралар». Аның әле эшләргә

мөмкинлеге бар иде, чөнки аныкы кебек тавыш Татарстанда гына түгел Россиядә дә бик сирәк иде. Нәфисәбез үзе эшләгән вакытка тиешле дәрәҗәсен алып бетерә алмады. Ул Татарстан күләмендә генә түгел, Россия күләмендәге халык артисты исемен алырга тиешле ханым иде», – дип үз фикерен белдерде җырчы, ТАССРның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов.

Искә алу кичәсендә Теләче районы халкы исеменнән районның башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илнар Гыйниятуллин да чыгыш ясады. «Без чын мәгънәсендә якташыбыз белән горурланабыз. Район үзәгендә Нәфисә Василова дигән урам булдырылды. Шулай ук Субаш авылы мәдәният йорты да аның исемен йөртә», – диде ул.

Камилә БИЛАЛОВА.

«Мәңгелеккә юл» башы

Габдулла Тукайның вафатына 110 ел тулган көнне «Тукай. Мәңгелеккә юл» дигән театральләштерелгән экскурсия узды. Анда катнашучыларга шагыйрь хастаханәдә вафат булган палата күрсәтелде.

Экскурсиягә килүчеләр, шагыйрьне соңгы юлга озатучылар маршруты буенча – Клячкин хастаханәсеннән Яңа Татар бистәсе зиратына кадәр юл тотты. Бу көнне шагыйрьнең каберенә чәчәкләр салынды, аның рухына багышлап Коръән укылды.

«Тукайның минем күңелдән чыкканы юк. Мин аны һәрвакыт искә төшерәм, китапларын кулга алам. Ләкин аның каберенә зиярат кылу ул барыбер икенче хисләр уята. Монда безнең галимнәребез, әдипләребез катнаша. Алар Тукайга әйтәсе килгән сүзләрен, фикерләрен белдерә. Тукай рухы карап торадыр дип уйлыйм һәм, минемчә, Тукайның бакыйлыкка күчкән көнен, туган көнен искә төшерү – фарыз эш», – диде Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла.

Экскурсияне Г.Тукай музее хезмәткәре Лена Тябина алып барды. Театральләштерелгән тамашаларны Камал театры артистлары Фәнис Җиһанша, Илдус Әхмәтҗанов, Фәннүр Мөхәммәтҗанов күрсәтте.

Экскурсия апрель буе дәвам итәчәк. Анда катнашу өчен Тукай музее сайтында алдан теркәлү сорала.

Милли тәрбия бакчадан башлана

Казандагы «Бала-Сити» балалар бакчасында «Туган тел фест – 2023» фестивале узды. Анда мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телендә белем бирүче тәрбиячеләр һәм укытучылар үз методикалары буенча остаханәләр үткәрде. Катнашучылар алдында Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов чыгыш ясады. «Мәктәп, балалар бакчасының эчке мохитен миллилек белән тутыра алсак, татар телендә чаралар үткәрсәк, киләчәгебезне өметле күрәбез. Телебезгә битараф булмаган, милләт җанлы тәрбияче, укытучылар бик күп. Сезнең эшнең катлаулы булуын беләм, чөнки әти-әниләр белән мөнәсәбәтләрдә искиткеч күп каршылыклар була. Аларның бу мәсьәләгә мөнәсәбәте безнеке кебек түгел, аларны инандырырга кирәк», – дип сөйләде Татарстан парламенты вице-спикеры.

«Бала-Сити» балалар бакчасы генераль директоры Альбина Насыйрова фикеренчә, балада татар теленә кызыксыну уятуда өстәл уеннары бик ярдәм итә. Алар Татарстан районнарындагы балалар бакчалары өчен 10 өстәл уены ясаган. «Һәр уен аша бала тел өйрәнү сәләтен үстерә. Татар телендәге уеннар күбрәк булса, балаларда кызыксыну тагын да артыр, дип уйлыйбыз, – дип сөйләде ул. – Биш ел дәвамында өстәл уеннарын үзебездә тикшердек. Бу уеннар махсус программа белән язылган».

1 нче биттә – «Казан нуры» мәчете.

Республикакүләм ифтар

Республикакүләм ифтар быел да «Казан Экспо» күргәзмә үзәгендә узды. Аны Татарстан мөфтияте, «Ак Барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы бергәләп оештырды. Унберенче тапкыр уздырылган Республикакүләм ифтар бу юлы Рамазан аеның соңгы ункөнлегенә – гыйбадәт кылуда аеруча зур тырышлык күрсәтү көннәренә туры китерелде.

Мәҗлескә республиканың төрле шәһәр-районнарыннан 10 мең 500 дән артык кеше килгән иде. Алар арасында төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, эшмәкәрләр, Россия төбәкләреннән һәм Татарстан шәһәр-районнарыннан килгән рәсми затлар һәм кунаклар бар. Ифтарга Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондыннан 200 мохтаҗ һәм азкеремле дә чакырулы иде.

Республикакүләм ифтарга килүчеләр арасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның булуы, дипломатлар килүе дә мәҗлесне ямьләндереп җибәрде. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре илчелегенең Россиядәге беренче сәркатибе, сәяси бүлек башлыгы Мөхәммәд Рәшид Әлмансури, Россиядә Катар илчесе урынбасары Абдулла Юсеф Әл-Сааи, Төркия, Төрекмәнстан, Казахстан, Үзбәкстанның Казандагы генераль консуллары Исмәт Эрикан, Гунч Гәрәев, Ерлан Исхаков, Фәриддин Насриев, Иранның Казандагы генераль консулы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Мосуд Моллаи – дәрәҗәле кунаклар иде.

Ифтарга килүчеләр мөселман кирәк-яраклары, кул эшләре, татлы ризыклар, балалар китаплары һ.б. тәкъдим ителгән ярминкә белән танышты. «Хозур» нәшрият йорты китаплары белән кызыксыну аеруча зур булуы игътибарны җәлеп итте. И.Шакиров исемендәге концерт залында Рамазан аена багышланган 3D-графикада видео программа тәкъдим ителде.

Республика ифтары тантанасы, кояш баерга бер сәгать кала башланып китте. Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов мәҗлескә килүчеләрне сәламләгәннән соң, Яшел Үзән имам-мөхтәсибе Габделхәмид хәзрәт Зиннәтуллин укуында Коръән сүрәләре яңгырады.

Намаз залында Татарстанның халык артисты, Буа татар дәүләт театрының сәнгать җитәкчесе Раил Садриев башкаруында «Дәрвиш» моноспектакле башланып китте. Ул XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән, Буа шәһәрендә имам булып эшләгән күренекле татар дин галиме Нургали хәзрәт Хәсәновның тормышы һәм эшчәнлегенә багышлап әзерләнгән иде. Мөселманнар, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга ияреп ахшам намазын укыгач, ифтар кылу залына күчте. Журналистлар белән аралашканда, мөфти ифтарның югары дәрәҗәдә узуын билгеләде. «Минем үземә ошады, барысы да әйбәт узды, зарланучылар да юк кебек», – диде ул.

Казанлылар өчен «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенә бару һәм кайту өчен шәһәр яны поездларының махсус бушлай рейсы оештырылган иде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Яратыйк илне, яратыйк туган телне!

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

2023 елда монда Мәгариф министрлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессының катнашында сигезенче тапкыр «Үз халкын данга күмгән татарлар» дигән бик уңышлы республикакүләм конференция үткәрелгән.

Районнарда да бу эш киң дәрәҗәдә алып барыла. Шундыйларның берсе Арча районы. Район күркәм кешеләре белән, аларның изге гамәлләре белән дан тота. Үрнәк гаиләләрнең гореф-гадәтләребезне дәвам итеп яшәүләре «Милли хәзинә» бәйгесе кысасында киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә. Яшь буынны туган телебезгә, милли йолаларга, гореф-гадәтләргә өйрәтү – бәйгедә төп максатның берсе. «Авылым һөнәрчесе» исемле үтемле чара бу бәйгедә аерым урын алган.

Авыл татар өчен аеруча әһәмиятле. Милли яшәеш, тел, гореф-гадәтләр авылларыбызда саклана. Шунлыктан бүгенге тормышыбызда авыл яшәеше, аның халәте заман үзгәрешләренә туры килердәй рәвештә җайга салына.

Татар Конгрессы 2023 елның 13-15 мартында татар авыл эшмәкәрләре җыелышын үткәрде. Анда 560 эшмәкәр катнашып, ул уңышлы рәвештә тәҗрибә уртаклашу семинары рәвешендә үтте. Аның барышында эшмәкәрләр Чуашстанның милли традицияләребезне ныклап саклый, аларны ныгыта баручы Шыгырдан, Урмай, Тукай авылларында булды. Тукай авылында мәктәп белән мәчет кулга-кул тотынып эшли. Анда балаларны беренче класска керү алдыннан мәдрәсә аркылы үткәреп, уку-язуга, дин кагыйдәләренә өйрәтәләр. Ә инде укуның шактый бер өлеше мәдрәсәнең компьютерлар белән җиһазланган классларында үтә.

Моңа охшаш авылларыбызны саклап калу чаралары Татарстанның Балтач, Саба, Кукмара районнарында да үткәрелеп тора. Лениногорск районындагы Керкәле, Кирлегәч авылларында да, Саба, Кукмара, Балтач районнарының кайбер авылларында да мәчет белән мәктәп арасында тугандаш мөнәсәбәтләр урнашкан. Ә бу исә авыл яшәсә, милләт яши, дигән сүз.

Яратыйк без Татарстаныбызны, татарлыгыбызны, телебезне яратыйк!

Опера студиясенең җыр бәйрәме

Казан консерваториясе төрле еллардагы Опера студиясе йолдызларын Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында җыйды. Туган тел көненә багышланган Татар музыкасы, шигърияте һәм театры фестивасенең «Татар музыка театры энҗеләре» дип аталган беренче концерты Опера студиясенең 30 еллыгына багышланган иде.

Казан консерваториясе хәбәр итүенчә, фестивальгә уку йорты ректоры, профессор Вадим Дулат-Алеев инициативасы белән нигез салынган, ул фестивальнең сәнгать җитәкчесе дә булып тора. Татар музыкасы, шигърияте һәм театры фестивале Казан консерваториясе тарафыннан беренче тапкыр Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында үткәрелә.

«Элек без аерым-аерым концертлар куя идек. Хәзер без милли проектларны бер фестивальгә берләштердек. Аның концепциясе – татар теленең нәфисլеген, моңлылыгын күрсәтү. Без бу фестивальне традицион булыр дип күзаллыйбыз», – диде Опера студиясенең сәнгать җитәкчесе, музыкаль театр кафедрасы мөдире, профессор Әлфия Җаббарова.

«Опера студиясе – Консерваториядә студентлар өчен зур платформа. Студия нигыта һәм зур профессиональ сәхнәгә әзерли. Бу фестиваль бер яктан музыкаль җәүһәрләребезне, икенче яктан саф татар телендә җырлый алган яшь иҗатчыларыбызны күрсәтә. Шулай ук, мирасыбызны тәшкил иткән шагыйрьләребезнең, композиторларыбызның кайчандыр яңгыраган әсәрләрен яңарта», – ди җырчы Илгиз Мөхетдинов.

«Консерваториядә укып чыккан һәр җырчының чишмә башы – Опера студиясе. Студент чагымнан хәтерлим – без анда нинди генә татар, рус һәм чит ил әсәрләрен башкармадык! Шушы башлангыч баскычлар буйлап әкренәкрен генә күтәрелеп, бүген зур сәхнәдә җырлыйбыз», – диде Филүс Каһиров.

«Хәзер мондый классик концертлар күп түгел. Ә тамашачы төрле: кайсысы – эстрада, кайсысы – классика, кайсысы фольклор тыңлый. Һәр төрле тамашачы өчен концертлар булып торырга тиеш. Классик әсәрләргә мөкиббән булган тамашачы өчен бу фестиваль бик кирәк», – диде җырчы концерт алдыннан.

Программага консерваториянең Опера студиясе тарафыннан төрле елларда куелган опералар, музыкаль комедияләр, ораторияләрдән күренешләр кергән: Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч», Салих Сәйдәшевнең «Наемщик», Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым», Эльмир Низамовның «Алтын Казан» һәм «Кара пулат» әсәрләреннән күренешләр тәкъдим ителде.

Опера студиясе төрле еллардагы солистлары: Рөстәм Асаев, Филүс Каһиров, Эльмира Кәлимуллина, Айрат Ганиев, Сөмбел Кыямова, Руслан Закиров, Алина Кәримова, Илгиз Мөхетдинов чыгыш ясады. Казан консерваториясенең композиция кафедрасы мөдире Эльмир Низамов аккомпаниатор булды.

Концертта тагын Рөстәм Рәхмәтуллин җитәкчелегендәге Казан консерваториясе халык уен кораллары оркестры, И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең Дмитрий Железнов җитәкчелегендәге симфоник оркестры, Гөлназ Әкбәрова җитәкчелегендәге Опера студиясе хоры, И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең Гүзәл Ахунова җитәкчелегендәге татар хоры, Д.Железновның малайлар һәм егетләр капелласы һәм башкалар катнашты.

Татар музыкасы, шигърияте һәм театры фестивасенең икенче концерты яшьләр вокаль-хор коллективлары катнашкан татар хор музыкасыннан төзелгән. Ул 25 апрельдә үтәчәк. Фестиваль Җәүдәт Фәйзинең легендар «Башмагым» музыкаль комедиясе белән 27 апрельдә тәгәлләнә.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

● Финанс министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елда россиялеләр 75 тонна инвестицион алтын коелмасы сатып алган. 2020-2021 елларда исә әлеге күрсәткеч 5 тоннадан артмаган. Ихтыяҗның мондый зур булуы сәбәпләре берничә: икътисади билгесезлек, геосәяси проблемалар, сумның зәгыйфьләнүеннән курку, дус булмаган илләр валюталарына ышаныч кимү. Моннан тыш, былтыр яз Россиядә банктан алтын коелмасы сатып алганда 20 процентлы өстәмә кыйммәт салымының гамәлдән чыгарылуы да куәтле этәргеч булып чыккан. Хәзер алтынның бәясе троя унциясе (31,103 грамм) өчен 1,9 мең доллардан арта. Быел аналитиклар бер унция алтын бәясе 2,1-2,2 мең долларга җитәр, дип фаразлый.

● Планетабыздагы тормыш сыйфаты турындагы глобаль Numbeo мәгълүмат базасы еллык Current Crime Index – «Шәһәрләр буенча җинаятьчелек индексы»н бастырган. Рейтингка кертелгән 416 шәһәргә криминаль куркынычлык дәрәҗәсенә карап 11 дән 83 кә кадәр балл бирелгән. Яшәү өчен иң куркыныч калалар дип Каракас (83,5 балл) (Венесуэла), Претория (81,9 балл), Дурбан (81 балл) һәм Йоханнесбург (80,8 балл) (КАР), Сан-Педро-Сула (80,7 балл) (Гондурас), Порт-Морсби (80,4 балл) (Папуа-Яңа Гвинея), Кабул (80,1 балл) (Әфганстан), Рио-де-Жанейро (77,6 балл) һәм Форталеза (77,1 балл) (Бразилия), шулай ук Элис Спрингс (77,3 балл) (Австралия) табылган.

● Кызлары – Гөлнар һәм Алсу Арслановалар.

Татарның затлы тавышы

ТАССР Һәм РСФСРның халык артисты, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены иясе, нәфис сүз остасы Айрат Гәрәй улы Арслановка бу көннәрдә, исән булса, 95 яшь тулган булыр иде.

Арабыздан киткәненә дистә елдан артык вакыт узса да, татар җәмәгатьчелеге аны сагына, юксына. Шушы көннәрдә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештыруында Айрат ага Арслановның Яңа бистәдәге Татар зиратындагы каберен зиярәт кылу вакытында бу аеруча нык сизелде. Искә алу мәрасимен Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов алып барды.

Башкортстанның Бүздәк районы Ахун авылында туып-үсеп, буй җиткезгән егет башта Татар дәүләт театр училищесының актерлык бүлегендә укып белем ала, 1948 елдан «Татарстан» радиосында диктор булып эшли. Ул затлы тавышы, сүз сәнгатен югары дәрәҗәдә халыкка җиткерә белүе белән тамашачының мәхәббәтен бик тиз яулап ала. Алга таба Айрат Арсланов Мәскәүдә бик күпләрнең хыялы булган А.Луначарский исемендәге театр сәнгате институтының актерлык факультетын тәмамлый. Татар академия театрында эшләгәндә дә, халкыбызның күңелен яулаган рольләр иҗат итә. Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә – Булат, Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасында – Мирвәли, Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» драмасында – Алиш, Мостай Кәримнең «Кыз урлау» комедиясендә – Мөхәммәтша, Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры»нда – Басыйр, Эмиль Золяның «Рабурден токымы» әсәре буенча куелган спектаклендә – Доминик, Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә»сендә Таһир рольләрен башкара. Айрат ага 1961–1965 елларда Казан телевидение студиясендә актер һәм диктор, 1965 елдан Татарстан филармониясе эстрада артисты һәм 1985 елдан режиссеры булып халкыбызга хезмәт итә.

Искә алу мәрасиме Казанның Галиев мәчете имам-хатыйбы Рамил хәзрәт Миңгәрәевнең Айрат һәм Мәрьям Арслановлар рухларына Коръән сурәләре укып, дога кылуы белән башланып китте. Аннары искә алу чарасын филармония директоры Кадим Нуруллин чыгышы дәвам итте. «Тирән белемле, татар һәм рус телләрендә иркен, акцентсыз аралашуы безнең буын өчен ул бүген дә өлге булып тора, чөнки аның кебек телне камил белгән кеше буларак та, төс-буй, фикер сөреше ягыннан да һәрвакыт безнең татар шушындый дип күрсәтерлек шәхесебез иде», -– диде К.Нуруллин.

Айрат аганың күп еллар дәвамында Мәскәү, Ленинград кебек шәһәрләрнең концерт мәйданнарында татар әдәбияты әсәрләрен яңгыраткан мәлләрендә, Финляндия, Польша, Венгрия, Чехословакия, Германия, Финляндия илләрендә гастрольләре вакытында аңа нәкъ менә шулай сокланып караганнардыр.

Профессор, әдәбият галиме Фоат Галимуллин А. Арслановны, хезмәттәше буларак, аны сүз сәнгатенең иң камил, талантлы, күренекле вәкиле иде дип атады. Галим аның үз тирә-юнендәгеләрне киң күңеллелеге белән дә җәлеп итүе, остаз буларак та яшьләрне үстерүгә зур өлеш кертүе турында сөйләде. «Татарстан» радиосында күп еллар хатыны Мәрьям апа белән бергә эшләргә туры килде. Шул вакытта Айрат абыйның ярдәмен күп тойдым. Тыңлый да, шундук шалтырата, үз бәясен, киңәшен бирә иде», – диде ул.

Фоат ага искәртеп үткәнчә, хезмәттәше һәм остазы аны әсәрләрне яттан белүе белән генә түгел, шигырьнең бөтен нечкәлекләренең үзәгенә үтеп, тыңлаучыларның күңеленә сеңдерә алуы белән дә сокландырган. Айрат Гәрәй улы, Г.Тукай, М.Җәлил, С.Хәким, Х.Туфан әсәрләреннән зур программалар эшләп, аларның шигъриятен халкыбыз күңеленә сеңдерү өчен зур эш башкарган, татар шигърияте офыкларын киң мәйданга чыгарган. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал да А.Арслановның нәкъ менә татар әдәбиятын халыкка җиткерүдә әһәмиятле эш башкаруына игътибарны юнәтте. «Безнең буын, беренчедән, китап укырга яратып, икенчедән, Айрат Арслановны тыңлап үсте. Шигырьне төрлечә укып була. Ул халыкның күңеленә үтәрлек итеп укый иде. Язучылар арасында Айрат абыйны тыңлап, әдәбиятка килүчеләр дә күп. А.Арсланов халкыбызга телебезнең тәмен җиткерә белде», – диде ул.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев үз чыгышын истәлекләрдән башлады. Ул Мәскәүдә укыган елларында радио тыңларга яраткан. Мәскәү дикторлары «Татарстан» радиосы сөйләвен игълан иткән. Шуннан җанны нурландырып, Айрат абыйның йомшак, колакны иркәли торган тавышы яңгырый. «Безнеке иң әйбәте, дип рәхәтләнеп киттек. Ул эстраданың күрке иде. Аның авызыннан чыккан сүз, ул яңгыраткан тавыш һәрвакытта затлы булды. Үз урынында аның тиңе юк», – дип искә алды ул.

А.Арсланов күп кенә дәүләткүләм зур концертларны алып барган. Фердинанд Сәлаховка шуларның берсендә катнашырга туры килгән. Бу Тукай көннәрендә Мәскәүнең Кремль сараенда уза торган дәрәҗәле концерт була. Сценарийда, Бөек Тукай, дигән сүз очрый. Айрат ага генераль репетиция вакытында, әлбәттә, бу сүзне яңгырата. Тиешле органнар моны тәрҗемә иткәннәр Һәм «бөек» дигән сүзне алып ташларга, дип килеп әйткәннәр булса кирәк. Пушкин – бөек , әмма Тукай – юк. Ыгы-зыгы башлана. Концертны алып баручыларның берсе Айрат Арслановка да бу хакта килеп әйтә. Ул кәгазьдә нәрсәдер төзәтеп куя. «Шунда ул заман өчен бер батырлык, дип уйлыйм, ул чыкты да, ике телдә дә камил сөйләшә иде. «Великий Тукай» дип басым ясап, кычкырып әйтте. Беркем дә, бер сүз дә әйтмәде. Айрат абый эшне үзе үк җайлады бугай инде. Чөнки бар кеше дә аның янына килергә батырчылык итми иде. «Карап торырга шәп кыяфәт, аны дөньяның теләсә кайсы почмагына чыгарып бастырсаң, аңа татар артисты дип горурланып карап торырга, тыңларга була иде. Аның Аллаһ биргән тавыш тембрлары драматик һәм шул ук вакытта мәгълүмати текстларны һәр тыңлаучыга барып җитәрлек итеп укырга мөмкинлек бирә иде», – диде Ф.Сәләхов.

К.Нуруллин үз чыгышында Айрат Арслановның кызлары – Гөлнар һәм Алсу Арслановаларның тыйнак кына, татар хатын-кызларына хас буларак, әтиләренең истәлеген мәңгеләштерүдә зур эш башкаруларын телгә алды. Әйтик, Казанның яңа микрорайоннары урамнарының берсенә артистның исеме бирелү, ул яшәгән йорт диварына мемориаль такта куелу, истәлек кичәләре узу, «Мәрҗани» мәчетендә рухына Коръән уку мәҗлесе оештырылу аларның җаваплылыгында узган. «Бу эшләрне бөтен шәһәр күреп торды, рәхмәт сезгә», – диде К.Нуруллин.

Мәрьям һәм Айрат Арслановларның кабере – бер чардуган эчендә. Алар икесе дә апрель аенда туып, шул айда бакыйлыкка күчкән. Кызлары Алсу һәм Гөлнар, әти-әниләрен искә алып, алар рухына дога кылып, каберләрен чистартып тора. Алсу ханым әти-әнисен искә алырга килгән кешеләргә дә олы рәхмәтен белдерде.

Айрат аганың кабер ташына Г.Тукайның «Милләткә» дигән шигыреннән: «Әгәр милләт мине илтифат итеп искә алса – Шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем», – дигән юллар язылган. Айрат ага, шөкер, бу теләкләренә иреште.

Искә алу мәрасимендә филармония хезмәткәрләре, Татарстанның халык артисты, баянчы Кирам Сатиев, нәфис сүз остасы Гүзәл Мостафина, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе җырчысы Зөфәр Сафин һ.б. катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

«МИН КОЯШ БУЛМАК ТЕЛИМ»

Әле бала чагында ук Тукаебызның сөекле әнисе Бибимәмдүнә аны күкләргә – һаваларга чөеп: «Җан Габдуллам, җан якутым, җан гәүһәрем!» – дип күкрәгенә кысып сөя торган булган. Күрәсең, шул изге мизгелләр вакытында булачак бөек шагыйрь кояш җылылыгын, энергиясен тоеп, хозурланып, дәртләнеп, нурланып киткәндер… Һәм бу сихри нәзакәткә иярләнеп, тоеп, аны мәңге хәтерендә саклап, үсеп балигъ булгачта, шул мохитне сагынып, аны кайтарырга омтылган булырга кирәк.

Үзенең «Китап» дигән шигырендә, бөек шәрык шигъриятеннән наз тапкан атаклы рус шагыйрьләре Пушкин, Лермонтов иҗатыннан азыкланган шагыйрь, А.Пушкинның «Яшәсен кояш, бетсен



караңгылык!» – дигән сүзләренә теләктәшлек белдереп: «Килеп чыкты хәзер фикрем кояшы золмәт артыннан... Яшә туры караш, тәпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!» – дип тәкрарлый («Иһтида», 1911 ел). Хәлбуки, караңгылыктан яктылык патшалыгына ашкыну – Тукайның рухи һәм иҗади дөньясын сугарган, аңа таудай яктылык биргән, ялкынлы хисләрнең иң көчлеседер ул.

Шушы идеаллар белән рухланган шагыйрь иҗатының иң дәртле, гейзер кебек кайнап торган чорында үзенең иң тирән фәлсәфәсен, дөньяга карашын, максатын игълан иткән «Ваксынмыйм» дигән шигырен яза (1912 ел):

«Ашкынам мин әбәд
Бетмәс урынга мәңгегә,
Мәңгелеккә мәңге рухлы,
мәңге нурлы ямьлегә!
Анда мин мәңге көләч, һәм
Мәңге яшь булмак телим,
Бу кояш сүнсен, җиренә
Мин кояш булмак телим.»

Аның иҗаты киңәеп, тармакланып киткән чорда бу кояш рефлексиясе, хәтта аның үз фоторәсеменә дә иңә сыман. Хаҗитарханда яшәгән мөхәррир язучыларның берсе, әдип һәм журналист Гайфи Шәһид, аның бу чоргы сурәте хакында «Габдулла әфәнде үзенең кинлеге һәм җылылыгы, хыялы хисабына бөтен тирә якны яктырта, дөньяга нур иңдерә», – ди.

Ни өчен Тукай шулай тиз арада даһилык – «кояшлык» дәрәҗәсенә күтәрелә алган? Сабый чакта ятим калган, кулдан-кулга йөреп «җиде гаилә» аша үткән, рәхимсез тормыш тарафыннан «чарланган» Тукай, тиз вакыт эчендә нәкъ алмаз кебек эшкәртелгән, асыл якут ташына әверелгән, риваятьләрдәге Йосыф пәйгамбәр кебек алтын бәясеннән дә югарырак торган, материал эквиваленты булмаган шагыйрь – бөек

● Г.Тукайның фарсы телендә чыккан китабындагы иллюстрацияләр.

бәһасез шәхескә әйләнгән, аның «базары» бүгенге көндә – нәкъ үзе бербөтен галәм!

Күк, галәм, кояш энергиясен, масштаблылыгын, флюидларын туплаган шагыйрь, ниһаять, шул күләмлегендә җир белән тоташып, үз заманы – чорына килеп керә... Аның бу җирләктә самими, нечкә зәвыклы, милли иҗаты ташкын кебек җәелә бара... Татар мәдәниятендә «Тукай чоры – Тукай планетасы» туып чыга...

Монда тау-тау шигърият, шедеврлар, искиткеч могҗизаи поэмалар, Данте, Гёте, Хәйям, Хафиз, Сәгъди, Гомерларны искә төшерерлек дәрәҗәдә, мәһабәт (гигант) – «Шүрәле», «Су анасы», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмалары туа, һәм ул тиз вакыт эчендә дөньякүләм атаклы «шигърият кояшына» әверелә.

Бүгенге көндә егермәдән артык Шәрык һәм Көнбатыш телләренә тәрҗемә ителгән, Урта Азия, төрек дөньясы күләмендә танылган шагыйребез, фарсы шигърияте тәсбихында да дөньяның иң бөек шагыйрьләренең берсе – дип игълан ителгән.

Тукайның калебендә туган, «күктән төшкән» – кешеләрнең күңелен җәлеп итү, берләштерү кодрәте, ниһаять, татар дөньясына да үтеп керде. Шагыйребез иҗаты аша безне, дөньяга сибелгән милләттәшләребез белән дә тоташтырды.

Ул арада аның шигъри кодрәтенә тугры калган «җирле мохит», «изге улына» мәхәббәт йөзеннән, яңарып, җанланып китте, татар яшәгән иңлектә, әйтерсең, «Тукай йолдызы» кабынды: ул туган Кушлавычта «Тукай чишмәсе», Кырлайда аның «Ак каены», Урманче койган җылы мәгърур һәйкәле, хуш исле агач бүрәнәләрдән төзелгән олуг музее – «Акрополе» барлыкка килде. Башкалабыз үзгәндә бөтен шәһәребезне төйнәп торган мәһабәт сыны калкып чыкты (Садри Ахун эше), аның исемен йөрткән парк-мәйданнар, тормышына кагылышлы «Болгар», «Амурлар», «Көфер почмагы», «Печән базары», «Таһир мунчасы», «Шәрык клубы», «Клячкиннар», мәктәп-музейлар кайный башлады... Болар барысы да Тукай чоры, аның шигъри аһәңе, үлмәс моңы булып яңгырыйлар, аның иҗади импульслары – нурлары итеп кабул ителәләр.

...Бөек Тукайның «мөкатдәс моңлы сазы» XX гасыр башы милли культура тарихында якты сәхифәләр язып калдырды. Дөнья әдәбиятында сирәк талантка ия булган әдип татар сынлы сәнгатен – гасыр башында әле бөреләнә генә башлаган сәнгатьне тудыруга да бәяләп бетергесез өлеш кертте. Гомумән, Г.Тукайның һәм шулай ук аның күренекле замандашлары Ф.Әмирхан, Г.Ибрахимов, Г.Камалның милли «сурәтчелекне» яклап көрәшүләре, күптармаклы культурабызны бербөтен итеп үстерүдә гаять әһәмиятле роль уйнады.

...«Коеп куйган шагыйрь» генә булмаган Г.Тукай, сынлы сәнгатьнең идея-эстетик бурычларын, турыдан-туры милли үзаңны үстерү, дөньяга карашны киңәйтүгә юнәлдерелгән көрәш белән бәйле... Беренче рәсемле сатирик журналлардан – «Яшен», «Ялт-йолт» битләрендә чыккан публицистик үткен мәкаләләре, кыйссалары шуның турында сөйли. Әле 1906 елда ук беренче рус революциясе идеяләре белән канатланган Тукай «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» мәкаләсендә шундый дәртле чакыру ташлый: «...милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын...»

Милли мәдәниятне тудыруда һәм сәнгать төрләрен тигез үстерүдә («безнең милләтнең дә башка милләтләрнең тәррәкыятьчеләре кебек... чын мөхәррирләргә, рәссамнарга» мохтаҗлыгы) Г.Тукайның «Хиссияте миллия» мәкаләсендә аеруча ассызыклап әйтелә... Тырышлык эзсез югалмый. Акрынлап дөньяга чыккан рәсемнәрдә халык үз сурәтен, үз дөньясын күрә башлый... Шагыйрьнең «Юаныч», «Алтын әтәч», «Күңелле сәхифәләр» кебек татарның беренче рәсемле китаплары басылу да үзеннән-үзе генә барлыкка килгән очраклы күренеш түгелдер.

Балалар өчен чыгарылган әлеге җыентыклар татар китабы тарихында текстны сәнгатьчә иллюстрацияләүнең беренче үрнәкләре булып санала.

Г.Тукай китапларын бизәү Бөек Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда сыйфат ягыннан бөтенләй яңа баскычка күтәрелә. Ышанып әйтергә мөмкин: шагыйрь әсәрләрен иллюстрацияләү өлкәсендәге уңышлар татар графика сәнгатенең гомуми үсешенә зур стимул бирә. Бернича буын рәссамнар: И.Плещинский, Б.Урманче, Б.Альменев, Т.Хаҗиәхмәтов, Э.Зарипов, И.Колмогорцева, В.Аршинов, Н.Әлмиев һ.б. тарафыннан Г.Тукайның шигъри дөньясы рухына тәңгәл килгән образлар хәзинәсе туып чыга.

Татарстан сынлы сәнгате чәчәк аткан дәвердә Тукай тематикасын ачуга яңачарак килү күзәтелә башлады. С. Сүнчәләй шигыреннән шагыйребезне иҗат девизына әйләнгән «Сөй халыкны, сөй сәнгатьне, сөй халыкның дөньясын…», – дигән үгет-нәсихәтле юлларны рәссамнарыбыз үзләренең әсәрләрендә тагын да куәтләрәк, калкурак итеп гәүдәләндерергә омтылды, шушы юнәлештәге эзләнүләрен тирәнәйтте.

Шунысы игътибарга лаек: алтмышынчы елларга кадәр Тукай тематикасы нигездә графика өлкәсендә гәүдәләндерелсә, хәзер ул сынлы сәнгатьнең барлык төрләрен дә колачлый. Шагыйрь иҗатының эстетик һәм гармоник гүзәллеген күрсәтүдә сәрәтләү чараларына аеруча бай булган нәкыш сәнгатенең зуррак мөмкинлекләргә ия икәнлеге дә күренде. Кабатланмас шигъри байлыкларны тулырак ачарга омтылу, үз чиратында, сынлы сәнгатьнең кайбер төрләрен синтезлау зарурлыгын да китереп чыгарды (сынчылык – һәйкәлтараш, нәкыш, корымчылык – архитектура объектлары бергә тупланган – монументаль комплекслар, аллегорияләр барлыкка килде – «Кырлай манзарасы», Казанда – «Тукай мәйданы» һ.б.)

Күптармаклы сынлы сәнгать өлкәсендә Тукай тематикасының гаять киң колачлы булып яңгыравы, шагыйрь иҗатының халык йөрәге белән бермә-бер тоташуы белән аңлатылады. Татар халкының рухи тормышындагы яңа зур күтәрелешләр, социаль һәм милли үзаңның уянуы, чыннан да, иҗаты аша, чын мәгънәсендә «халык җанына» әверелгән Тукай исеменә дә турыдан-туры бәйләнгән. Менә шуңа күрә дә, Тукай иҗатының сынлы сәнгатьтәге чагылышы, дөнья мәдәнияте өлкәсендәге кабатланмас, уникаль күренеш буларак кабул ителә. Әдәби иҗат шәхесе тирәсендә шулкадәр күпсанлы сәнгать әсәрләренең тупланануы, дөресен әйткәндә, мәдәният өлкәсендә бик сирәк очрый торган факт.

Татар мәдәниятенең төрле өлкәсендә: музыка, театр, корымчылык өлкәсе булсын, аеруча әдәбиятебез, «кул һөнәре» һәм сынлы сәнгате даирәләрендә шагыйребезнең тормыш юлын, мәһабәт гүзәл иҗатын, фаҗигале язмышын вә «заман алмас, чор алмас» изге рухын – шәүләсен күз алдына китереп бастырган әсәрләр саны иксез-чиксез. Бередә милли мирас, XX гасыр сәнгать җәүһәрләре, шагыйребезнең йөз-сыны, сурәте (портреты), шигъри аһәңнәре, аңа багышланган иҗат назымнары яңгырый вә яшәп күңелләрне яктырта, җанландыра.

Р.ШАҺИЕВА,
сәнгать белгече.

ТУКАЙ ЯЗЫ

Замананың әрсез суыгыннан
Чатнаганда хәтта иманнар,
Әче җилдән посып иелә-бөгелә,
Ышык җирдән күпләр килгәннәр.

Зәһәр кышлар, ажгыр буран ярып
Апрель җиткәч, язгы бер көндә
Тәүге батыр чәчкә сын турайта –
Иң авыры менә шул гөлгә!

Тукай да бит шулай замананың
Иң караңгы, җаһил чорында
Үз кавемен яктылыкка дәшкән,
Дан җырлаган халкым турында.

Һәм шул апрель җылы кулы белән
Сыйпап алгач бозлы таңнарны,
Сүнгән күңелләргә өмет тулган,
Җырлы иткән безнең җаннарны.

Халисә МӨДӘРРИСОВА

Берчә җырлап, берчә әрнеп елап,
Бу дөньялар бездән узып бара...

Күпләр килгән, мин дә бу дөньяга
Сөрән салып тудым апрельдә.
Килдем дә бит, әмма Тукай булып
Туа алмас инде беркем дә!

Үз телендә вакыт мизгел саный,
Ләйсән ява, аннан кар каплый.
Мизгел генәме соң, бу дөньяда
Тарихларны тарих кабатлый.

Заман салкын әле, көрт астында
Җылы көтә гөлләр, тугайлар...
Халкым исән булсын, киләчәккә
Яз китерә торган Тукай бар!

АВЫР ТӨШ

Авыр төшме, саташумы,
Төштекме көрчеккә,
Әверелдекме арсланнан
Комагай көчеккә?

Туйдырмый да, үтерми дә
Бу хәйләкәр өлеш,
Чыгымла – муенчак буа
Чылбыр кыска килеш.

Аракы туфаны илдә –
Ярлар да күренми.
Сәрхушны алдавы ансат:
Сүз ирке бирелми –

Ул бит уйлый белми.
Кемнеңдер өлеше – элмәк,
Кем астында – «Бентли»,
Өстән аска төкерә ул,
Аңа халык – гыйбди.

Анасын җәберләп качкан –
Фәхеш кармагында,
Бүлтерек ил сатып туйлый
Океан аръягында.

Мәҗбүр булып калдырырга
Туган илен, телен,
Сорыкортка ир бил бөгә,
Кисеп Себер җилен.

Чүплектә җан бирә картлар,
Сабый, кызлар, уллар...
Тиен өчен нәҗес юа
Яргаланган куллар.

Трибуна вәгъдәгә күмә,
Вак ташлама табып;
Кирәк чакта – халык «бөек»,
Ә аннары – сарык.

Урыннарын алыштылар
Яхшы һәм яманлык,
Оятсызлар арасында
Намус – бер ямаулык.

Кайчан үтәр бу саташу,
Уяныр ил уе?
Дөнья – гафләт йокысында,
Җирдә – Иблис туе,
Кайчан булыр чиге?!

ОСТАЗГА

Кемне сөйләсәң – шул киткән,
Кемне уйласаң – шул юк.
Нажар ага Нәҗми белән
сөйләшүдән.

Кемне уйласаң – шул киткән,
Кемне сөйләсәң – шул юк.
Гомерләр төштән авышкан –
Кояш баеган кебек.

Кояш баеган кебек тә,
Бәхет саеккан кебек,
Давыллы дөнья-дәрьяда
Язмыш – каекта кебек.

Каек кебек гомерләрне
Бөтерде зилзиләләр.
Өрлек кебек остазлар юк,
Иңен куярлар кемнәр?

Кемнәр генә иң куйса да,
Ул инде сезләр түгел.
Җиде ятка сер сөйләргә,
Без егет, кызлар түгел.

Җырлы-моңлы йөрәгегез
Давыл кисеп тынмады.
Берәм-берәм егыласыз,
Ятим итеп дөньяны.

Җитми хуплау, җитми «тукмау»
Һәм дә акыл тукучы;
Сез остазлар бар чагында,
Без дә идек укучы.

Без дә идек иркә генә,
Ваемсыз һәм тискәре.
Төшә хәзер иңебезгә
Остаз булу йөкләре.

Остаз булу авырлыгы –
Остаз хәтле булалмау.
Тик бәхет ул, үзеңнән соң
Әйтсәләр әгәр: «Абау,

Кемне сөйләсәң – шул киткән,
Кемне уйласаң – шул юк.
Остазлар китә, остазлар,
Дөньяда шундый тынлык,
Әче бушлык, авырлык!»

* * *

«Их, аның кебек булырга!..» –
Көнләшеп чибәрлеккә,
Үртәлеп яшь түгә кызый,
Капланып чирәмлеккә.

«Их, алар кебек булырга,
Яшәргә сарайларда!..» –
Язмаган андый нигъмәтләр
Гап-гади малайларга.

«Их, шулар кебек, яшьлекне
Барларга ватыклардан,
Чибәрлек, байлык кирәкми,
Дәва юк картлыклардан».

«Картайсам да, их, тимерләр
Кебекләр идем әле,
Сәламәт булсам, дөньяда
Терекләр идем әле...»

Каберләрнең ташларына
Вакыт җавабын уйган:
«Сез минем кебек булырсыз,
Мин сезнең кебек булмам!»

* * *

Пустых небес прозрачное
стекло...
А.Ахматова

Буш күкләрдә – тонык, нокыс нурлар,
Ак бүректән ойый соры өйләр,
Берчә улый, берчә әрнеп елый,
Берчә җырлый тышта сәрхуш җилләр.

Кышлар керә, хисләр инде айнык,
Борчылу юк, җырла, елап кара...
Безгә инде язлар кагылмастыр,
Көзләрнең дә төсе уңып бара.

Берчә җырлап, берчә әрнеп елап,
Бу дөньялар бездән узып бара.

АСЫЛЫ – ШУЛ

Рәдиф Гаташка

Юмарт көзләр бакчасыннан
Гүя яз карап куя.
Яңа бөре бүртсен өчен,
Агач та яфрак коя.

Чыккан күпер күмер түгел,
Әйтмә: «Вакыт үтелгән...»
Юккамыни нечкә җаның
Сандалларда чүкелгән?

Чүкелгән һәм юнгаланган,
Кагылган һәм өтелгән;
Күпме кулдан даруы да,
Агуы да эчелгән!

Яфрак койгач – яфрак ярыр,
Бу дөнья назга туяр.
Ничә мыскал энҗе-калфак
Җаныңа әле сыяр!

Мөлдерәмә уй-касәңә
Яңа язлар гамь өрер.
Яшәешнең һәр фасылы –
Мең үзгәреш бер гомер!

«Гаташ» дисәң, асылы шул –
Илһамы югалмаган,
Затлы чагы, заман чагы –
Атларын тугармаган.

Сөйгән, сөя һәм сөячәк –
Яратып туялмаган,
Шигърият дигән бәйгедә
Толпарын тыялмаган...

«Гаташ» дисәң,
Асылы – шул!

КЫЙБЛА

Күләгәләр элмә күңелемә,
Үткәннәрдә кояш янганга,
Мәхәббәтем кайнар ком чүлендә
Яшел утрау булып калганга.

Киртә корма, көчең җитә алмас
Сахраларда сәмум җиленә.
Яз булса да синең дәрьяларда,
Дулкын какмый күңелем күленә.

Син кагылма минем күңелемә,
Сәҗдә кылсам, кыйблам чүлдәдер.
Ялгышларым бары үземнеке,
Хөкем итү язык кемгәдер.

Син кагылма минем үткәннәргә,
Үткәнемдә – Кояш, Җидеган...
Тын үзәннән күпме бәндә үткән,
Тик бик азлар күккә үрелгән.

Оҗмахларың миңа кирәк түгел,
Үз гөнаһым үземә җитәрлек.
Үз кыйбламда һаман сөю яна,
Пәйгамбәрләр тәкбир итәрлек.

РЕДАКЦИЯДӘН. Башкорстанда яшәп иҗат итүче танылган шагыйрә һәм прозаик, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Һ.Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Халисә Мөдәррисова шушы көннәрдә күркәм гомер бәйрәмен билгеләп үтә. Без каләмдәшебезне юбилее белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

ТАТАР ЗИРАТЫ КАДЕРСЕЗЛЕКТӘ ЯТМАСЫН

Татарстан һәм алман галимнәре Германиянең Вюнсдорф шәһәрендәге Беренче бөтендөнья сугышы әсирләренең мөселман татар зиратын тулысынча реконструкцияләргә җыена. Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары, педагогика фәннәре кандидаты Марат Гыйбатдинов шул хакта сөйләде.

● Марат Гыйбатдинов Германиядәге коллегалары белән.

Көнчыгыш Германиядә – Берлинның көньягындагы Вюнсдорф шәһәре янында – Беренче бөтендөнья сугышы әсирләре җирләнгән мөселман зираты бар. Анда 1000 нән артык кабер исәпләнә. Вюнсдорф лагере янында зират 1915 елның апрелендә барлыкка килә. Беренче җирләнгән кешеләр – Әхмәтлатыйф Әхмәтҗанов, Хәбибулла Фәйзуллин. Иң соңгы җирләнгәне (1920 елның 19 декабре) – Хәлиулла Сәйфуллин. 600 лап кабер – Антанта ягында сугышкан гарәпләр, индуслар, башка мөселман халыкларныкы, 400 кабер Россия империясендәге мөселманнар – башлыча татарлар.

Германия хөкүмәте әсирләргә гомумән алганда хәерхаһлы мөнәсәбәттә була, әмма әсирлеккә эләгүчеләр арасында яралылар, авырулар да очрый, билгеле, шулай ук әсирлек – курорт түгел. 1000 нән артык әсир шушында җир куенына иңдерелә. Сугыш тәмамлангач, Британия империясе зиратны тәртипкә китерә, Икенче бөтендөнья сугышына кадәр зиратны Берлин мәхәлләсе мөселманнары тәртиптә тота. Сугыштан соң шәһәр совет идарәсендәге ГДРда кала һәм зиратны инде беркем дә карамый.

Тарих фәннәре кандидаты Лилия Габдрафикова бер хезмәтендә, ике бөтендөнья сугышында ярты миллионнан артык татар һәлак булган, дигән саннарны китерә.

2000 нче елларда Татарстан галимнәре – Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре – чит илләрдәге татар каберлекләрен тикшерүгә керешә. Каберлек шул елларда өлешчә ремонтлана, әмма кайсы кабердә кем җирләнгәнен ачыклау ул чорда мөмкин булмый – чыганаклар җитми.

2022 елның сентябрь аенда боз кузгалган, дияргә була. Татарстан галимнәренең Германия галимнәре белән уртак эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 409 кабердә кем җирләнгәне төгәл ачыклана. Тарих институты директоры урынбасары Марат Гыйбатдинов хәзер шушы каберлекне торгызу турында хыяллана.

М.Гыйбатдинов Германиянең Вюнсдорф шәһәрендәге Беренче бөтендөнья сугышы әсирләре зиратында булганда кыенсыну хисләре кичергәнен әйтте. Инде искәртеп кителгәнчә, мөселман зираты ике өлештән тора. Педант немецлар мөселманнарны җирләүне төгәллек белән башкарган. Англия гаскәрендә хезмәт иткән Һиндстан, Африка мөселманнарын һәм татарларны аерым өлешләргә җирләгәннәр.

– Берничә ел элек беренче мәртәбә ул зиратка килгәч үк, анда контрастның зур икәнен күрдем. Һиндстан ягы бик яхшы каралган, таштан һәрбер кешегә һәйкәлләр куйганнар, һәрберсенең кабере бар, чәчәктә утыра. Бөекбритания үз гаскәрендә хезмәт иткән кешеләрне хөрмәтләгән. Гәрчә алар бит әле инглиз дә түгел, индуслар, африкалылар, ләкин алар Англия дәүләтендә хезмәт иткән, һәлак булган – аларны хөрмәт итеп, зиратны шулай төзекләндергәннәр. Анда мәгълүматлар язылган китап бар: Англия гаскәренә эләккәндә кем булган, кайдан, ничек... Империя бит инде – үз халыкларының зиратын бик пөхтә итеп, рәсемдәге кебек матур итеп тота.

Ә безнекеләр... Икенче ягында, безнең татар өлешендә – кыр! Бер кабер дә күренми, зур «татар ташы» гына тора. Ул бер каберенеке түгел, гомуми таш, татар әсирләре акчасына урнаштырылган. Каберләргә агач «ташлар» куелган булган, алар юк инде.

Дөресен әйткәндә, хурландым мин, безнекеләр дә шундый ук солдатлар, шундый ук әсирләр, үз дәүләтенә хезмәт иткән кешеләр. Ни өчен алар беркемгә дә кирәкми? Иң соңгы тапкыр барганда күрдек: кешеләр, ул өлешкә кереп, пикник ясый башлаганнар. Дөрес, ул коймa белән тотылган, әмма анда кабер ташлары юк бит, кешеләр аңламый да зират икәнен... – ди М.Гыйбатдинов.

● Вюнсдорфтагы зиратның «Британия» өлеше – каралган каберләр, һәркемнең исеме язылган таш.

«Татар өлешендә» җирләнгән индуслар да булган. Бөекбритания 1934 елда үз өлешенә реставрация ясаганда, шушы индусларга тиешенчә таш куйганнар. Татарлар торып калган... Бу инде – СССР заманы, патша армиясе өчен һәлак булган солдатларга ул чорда нинди игътибар була алсын?

– Инглизләр үз өлешен тәртипкә китергәндә, бөтен зиратны караганнар, үлчәгәннәр, санаганнар. Әмма үзләренекен генә төзекләндергәннәр. Без аларга нәрсәгә кирәк инде? Ә советларга кирәкме ул патша армиясе чорында булган әсирләр? Бигрәк тә – татарлар! – ди М. Гыйбатдинов.

Галимнең әйтүенчә, 2000 елда, зиратта реставрация өчен, Татарстан Президенты фәрманы белән акча бирелгән булган. Гомуми таш та куелган, әмма инде ул таш та хәзер таушала башлаган.

Татарстан галимнәре, чит илдәге коллегалары белән бергә, Англиядә, Алманиядә булган материалларны җыеп, зиратны «тарихи рәвешенә» кайтарырга, зиратта җирләнгән әсирләрнең каберләрен ачыклауга ирешкән. 2000 елда алманнар: «Картаны ясап булмый, чөнки карталар, документлар юк», – дигән иде. Ләкин хәзер, цифрлаштырудан соң материалларны чагыштырып карый алгач, без зиратның тулы картинасын булдырдык. Һәрбер кабернең төгәл урынын, анда кем җирләнүен ул материаллар сакланган фотолар белән чагыштырдык. Менә ул зират, элек менә шундый булган, менә – кешенең агачтан ясалган кабер ташы. Реконструкция ясап, сакланган фотолар белән чагыштырып, безнең фаразларыбызның дөрес булуын расладык – бөтен исем-фамилияләр туры килә. Шундагы исемнәре дә фотолар белән туры килә. Хәзер без бу зиратны элекке кыяфәтенә кайтарырга тәкъдим итәбез: кыр гына булмасын – һәр кешенең каберенә үз исеме белән таш куелсын.

– Монысы бит – архив эше, аңа артык күп акча кирәкми. Ә менә зиратны яңадан торгызу өчен шактый чыгымнар таләп ителә. Без хәзер Германиядә хәрби

● Кабергә исемнәрне шушы рәвештәге агачларга язган булганнар.

Тарихи фото. 20нче гасыр башында зират шушындый хәлдә була.

зиратларны карый торган комиссиягә хат яздык. Алар хәзер бу зиратны ничек элекке хәленә кайтарырга икәнен уйлый, – диде Марат Гыйбатдинов.

М.Гыйбатдинов, зиратны өйрәнгәндә, немецларның бик тәртип ярата торган халык икәннәренә тагын бер тапкыр инанганын әйтте. Нәкъ менә шушы тәртип булуы каберләрнең төгәл урынын ачыклауда ярдәм иткән дә инде.

– Алар әсирләрне теләсә ничек җирләмәгән. Башлаганнар бер рәт белән, монда җир беткәч, икенче рәткә күчәләр. Тегендә-монда күмү юк анда, тәртип. Бигрәк тә хәрби зират, хәрби ведомствода булгач, анда тәртип аеруча яхшы булган. Зиратка 1-2 христиан да эләккән булган. Соңыннан аларны аннан икенче җиргә күчергәннәр.

Хәзерге сәяси вәзгыять катлаулы булуга карамастан, Марат Гыйбатдинов, зиратны төзекләндереп булыр, дип ышана.

– Без башта алманнардан рөхсәт сорыйбыз, чөнки акча булган очракта да, зиратка болай гына кереп булмый. Беренчедән, хәрби зиратлар белән эшли торган комиссиядән, аннары – һәйкәлләр белән шөгыльләнә торган инстанциядән рөхсәт алырга кирәк. Шунна соң гына акча мәсьәләсе, башка бөтен практик гамәлләр. Иң башта рөхсәт кирәк. Без хат яздык, алардан җавап көтәбез. Ләкин хәзерге сәясәт белән, белмим, ниләр булып бетәр?! Шулай да, ниндидер нәтиҗә булырга тиеш, дип уйлыйм. Чөнки ике ил арасында килешү бар, Россиядәге әсирләр җирләнгән каберләр һәм Алман илендәге совет һәм Россия әсирләре бертигез каралырга тиеш. Алманнар зиратны төзекләндерергә күпмедер акча бирәләр икән, безгә дә үзебезнең яктан сорарга кирәк була инде.

– Димәк, Германия үзе дә бу эшне финансларга мөмкин?



Мортаза Мөхәмәтдинов кабере.

– Мөмкин, алар үзләре эшли дә. Без бит бик күп зиратларны карап йөрдек, аларның төзекләндерү буенча планнары бар. Аларның меңләгән каберлекләре, аеруча Икенче бөтендөнья сугышыныкы бик күп.

– Бу кайчан эшләнергә мөмкин?

– План буенча карыйлар, тик безнекен планга кертү кайчан була әле. Тизләтү өчен, безнең яктан, Татарстаннан кызыксыну кирәк, билгеле. Без Германиягә институт исеменнән бер хат яздык, бәлки, югарырак даирәләрдән яздырырга кирәктер, әйтик, конгресстан, Рәистән...

Татарстанда шундый кызыксыну булса, ул зиратны үз хәленә кайтарыр идек. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Без хәзер тарихи яктан дәлилләдек, бу инде теләсә ничек кенә түгел, конкрет: фәлән атлы кеше монда җирләнгән, ул кем – кайда туган, кайда хезмәт иткән, кайчан әсирлеккә эләккән, кайчан үлгән, хәтта ни сәбәп белән үлгәнлегенә кадәр язылган.

Икенче этапта исә интерактив карта ясарга уйлыйбыз – һәркем бу зиратны карый алсын.

– «Бу эш татар өчен нигә кирәк» дигән сорауга да җавап бирегез инде.

– Беренчедән, без бабаларыбыз яткан урынны белергә тиеш. Икенчедән, алар Алман иленә үз теләкләре белән китмәгән, дәүләт, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, хәрби хезмәткә алган һәм алар дәүләтнең вәкилләре буларак киткән.

Аннары без татарларның Россия гаскәрендә Россия мәнфәгатьләрен кайгыртуда үз өлешләрен кертүләнлеген күрсәтә алабыз. Без аны онытырга тиеш түгел. Менә мин һаман шуны әйтәм: Финляндиянең Россия белән «Кышкы сугыш»ында 7 татар кешесе һәлак булган. Ел саен Финляндия дәүләте татар зиратына почетлы каравыл җибәрә, татар каберләренә чәчәкләр куела. Бу дәүләт үз иле мәнфәгатьләрен яклап һәлак булган 7 татарны шулай хөрмәт итә. Яһүдләргә дә, башка халыкларга да шулай ук игътибар күрсәтелә. Бу – дәүләтнең үз халкына карата хөрмәт күрсәтүе. Без дә бит бабаларыбызны онытмаска тиеш. Ә бу очракта контраст ап-ачык ярылып ята. Цивилизацияле дәүләт үз үлгәннәрен ничек хөрмәт итә – башка милләттән, башка диннән булуына карамастан... Һәм без – үзебезнең татар мөселманнарын (сугышта һәлак булгач, шәһитләр бит инде алар) – ничек хөрмәт күрсәтәбез. Бик зур контраст...

Рәмис ЛАТЫЙПОВ
intertat.tatar

Нәфисә түгел, Әнисә!

Бервакыт, Мими дип аталган чуаш авылына барып чыккач, шундагы мәктәптә эшләүче өлкән яшьтәге әдәбият укытучысы белән таныштым. Ул, минем татар икәнемне белгәч, мондый сорау биреп куйды:

– Сездә Әнисәне укыйлармы, Бәшириненкен? Аны студент чагымда ук укыганым бар иде, һаман истә тора – әйбәт язучы ул сезнең...

Бәшири дигәч, ул ялгышып Гомәр Бәширне һәм «Намус» романының баш герое – Нәфисәне күз уңында тотмыймы икән, дип уйлап алдым. Шуңа күрә:

– Бәширнең Нәфисәсен, ягъни «Намус» романын әйтүегезме? – дип сорадым.

– Юк, Юк! Бәширинең «Чуаш кызы Әнисә» дигән әсәре! Революциягә хәтле үк иҗат иткән ул аны! – дип ачыклады әңгәмәдәшем. Һәм чуашча өстәп куйды: – Нафиса мар, Аниса.

Мин берничек тә җавап бирә алмадым. Чөнки Бәшири исемле язучыны да белмим һәм аның чуаш авылы укытучысы әйткән әсәрен дә укыганым юк иде. Турысын әйтим, оятка калдым мин шул чакта Мими авылында.

Зариф Бәшири – ул ачылмаган утрау икән лә. Үзем йөргән китапханәләрдә һәм китап кибетләрендә мин аның китапларын эзләп-эзләп карадым, әмма бер басмасын да таба алмадым. Нәшрият яисә институт архивларына кереп эзләнгәнем булмады. Шуңа күрә чуаш мөгаллиме әйткән әлеге әсәрне 2014 елда гына укый алдым. Ниһаять, ул елны Зариф Бәширинең сайланма әсәрләре Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Язучының иҗатын ачыш кебек кабул иттем дип әйтәсем килә. Һәм, әлбәттә, аның язмышы белән кызыксынуым да көчле булды. 1888 елда туган Зарифның шигырьләре узган гасыр башында ук күренә башлаган. Совет чоры төрмә-лагерьларында озак еллар иза чиккән әдипнең истәлекләре дә гаять кызыклы һәм әһәмиятле. Кемнәр белән генә эшләргә һәм танышырга-аралашырга насыйп булмый аңа! Тукай, Гафури, Дәрдемәнд, Рәми, Бабич, Г.Ибраһимов... Мондый атаклы шәхесләр белән күрешеп яшәүне язмыш бүләге дип тә әйтергә ярыйдыр, минемчә.

Китапны төзүче Ркаил Зәйдулла болай ди:

«... Ул күп язган. Арада, билгеле, бүген дә рәхәтләнеп укырлык шигырьләр бар. Үз заманында исә Тукай, Дәрдемәнд, Рәми, Бабичларны санаганнан соң, Гафурилар, Укмасыйлар, Думавилар, Бәширилар, Сүнчәләйләр исемлеге башланган. Бүген дә бу исемлекнең тәртибе үзгәрмәде...»

Бүгенге татар укучысы белә микән соң Зариф Бәширине, минем кебек кыен хәлдә калмас микән? Бу сорауны минем китапханәләргә яисә мәктәпләргә кергәч, шунда эшләүчеләргә турыдан-туры биргәнем бар. Командировкаларда районнарда йөргәндә андагы мәктәпләрдә, китапханәләрдә эшләүчеләрдән Зариф Бәшири турында кызыксынмый калмыйм. Ни кызганыч, белүче кешене очратканым булмады. Берсендә, өлкәнрәк яшьтәге бер укытучы: «Тыелган язучы дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар», – дип кенә әйтә алды. Ә инде яшьрәкләр татар язучысының шушы бер китабы чыгуын гына әйтә алдылар, шул гына. Аны да, әлбәттә, җәһәт кенә интернетта эзләп табып «исләренә төшерделәр». Компьютер ярдәме белән хәтер яңарткач, аларга китапның эчтәлегенә кагылышлы сорау бирүдә мәгънә бармы соң? Юк әлбәттә.

Зариф Бәширине совет чоры агитация машинасы онытгырырга тырышкан һәм аның авыр йогынтысы бүген дә юкка чыкмаган, ахры. Ә ул гаҗәп тә үзенчәлекле шәхес һәм аның менә шушы бер китапка кергән сайланма әсәрләре генә дә ни тора! Безнең интернет-компьютер белән баш әйләнгән заманда да күңелне тансык яңалык белән сөендергән иҗат җимеше ул.

Тагын Ркаил Зәйдулла сүзләрен искә төшерим:

«... Без бу юлы чәчмә әсәрләрне генә сайладык, Зариф Бәширинең шигырьләрен туплап чыгару – киләчәк эше. Әдәби мирасыбыз онытылырга тиеш түгел... Аның иҗатын җентекләбрәк өйрәнергә вакыттыр, мөгаен. Ул чакта татар әдәбиятының тарихы да яңа яклары белән ачылып китәр иде...»

Без көтәбез инде. 2014 елдан бирле көтәбез. Әмма әдәбият сөючеләрне куандырырлык яңалык күренми әле.

Без генәме соң? Әнә күршеләребез дә кызыксына икән Зариф Бәшири исемле татар язучысы белән!

Ильяс САЛИХҖАН.

Зариф Бәшири (уртада) уйгыр яшьләре белән Сәмәркандта. 1926 ел.

Ибраһим НУРУЛЛИН

Башкала белән саубуллашканда

Габдулла куркынычлы төш дәһшәтеннән һәм күкрәгенең чәнчүеннән уянып китте. Үзен тыныч номерда күргәч, иркен сулап куйды һәм күргән төше турында уйлана башлады.

Ул кое кебек тирән баз төбендә, имеш. Югарыда, базның кырыенда бозау чаклы кара мәче утыра. Ул Тукай өстенә сикерергә чамалый, имеш. Габдулла күзен чытырдатып йомды да көтә башлады. Ник сикерми инде? Габдулла, акрын гына күзен ачып, өскә карады.

Мәче түгел икән ич, аны Казанда караган доктор! Үзе доктор, үзе шул ук вакытта Галләметдин бай да икән. Кызык! Бервакыт доктор Галләметдин тавышы белән түбәнгә карап кычкыра башлады:

– Борауларга кирәк, Габдулла әфәнде, борауларга кирәк.

Габдулла «нәрсәне борауларга куша?» дип уйларга өлгермәде, доктор базга сикерде. Ләкин дөпелдәп төшмәде, җай гына килеп басты. «Күзгә күренми торган канатлары бар» дигән уй чагылып китте.

Доктор чынаяк төбедәй күзләрен акайтып, тешләрен ыржайтып Габдуллага карады да:

– Йә әйт, мин кем? – дип сорады.

– Доктор…

– Ха-ха-ха!.. Күрмәдеңмени, ничек очып төштем? Мин газраил! Үзең чакырдың ич.

– Кайчан?

– Монда күчкәнче.

– Чакырганда киләсең калган. Хәзер кирәкмисең инде.

– Күп сөйләнеп торма. Менә договор. Кул куй да, күкрәгеңне бораулый башлыйбыз.

– Ник аны борауларга?

– Син белмисеңмени? Мөселман кешене теге дөньяга ансыз кабул итмиләр, – диде дә газраил, әллә кайдан борау табып, тишәргә керешә. Габдулла, авыртуга түзә алмыйча, бәргәләнә, суккалана башлады һәм… уянып китте.

– Күкрәк һаман чәнчеп-чәнчеп ала иде.

– Тукта әле, чакырдымыни соң ул газраилне? Кайчан булды ул? Ә, әйе, теге ученый богослов кабинетында ябылып ятканда шундый хәл булды бугай.

Габдулла Казаннан ук авыр тойгылар белән чыгып киткән иде. Ник дисәң, кыш буе бизгәк белән җәфаланды, өшеде, калтыранды. Яз кергәч, Казанның кабих һавасы шулкадәр начарланды ки, тын алырга бирми буа башлады. Хәер, ни ул тән газабы! Аңа Тукай күптән күнеккән инде. Җан газабы ачырак.

Бакуда эшли торган кордашы Сибгатьтән хат алгач, аның күңелендә өмет чаткысы кабынган иде. Тиздән барлык рабочийлар «җитте!» дип әйтерләр дә, аждаһа-машиналарын туктатып, урамга чыгарлар. Крестьян, алпавыт басуына иелгән сынын турайтып, урагын күтәреп бәрер дә чалгыга, күсәккә үрелер. Бишенче елдагы кебек ялкын күтәрелеп, реакция төнен куып җибәрер.

Әмма кара төн каплап ята бирде. Таң йә бик ерак, яисә бөтенләй атмас кебек иде…

Моңа Петербургның суыгы, өзми-куймый ява торган яңгыры өстәлде. Дөньядан хәбәрсез булып ябылып яту, дус-ишләр һәм фикердәшләрнең, аны бар дип тә белмичә, кайдадыр кәеф-сафа сөрүләре Габдулланың җанын кыйный иде.

Ниһаять, алар килделәр. Габдулла шатланды, билгеле. Ләкин күңел почмагында үртәлү һәм үпкә хисе тибеп тора иде.

– Ничек соң, Петербург ошадымы? – дигән сорауларына каршы ул хәтере калган бала тавышы белән болай диде:

– Петербургка Казан булырга ярамый инде. Карасаң, бүрегең төшә торган биек йортлар, һәйкәлләр, челтәрле күперләр. Урамында трамвай, лихач, автомобиль – бихисап. Урам түгел, дию! Көн дә әллә ничә кешене кабып йота икән. Күбесе рабочий була ди. Байлар урамы шул, шомалар урамы…

– Ха-ха-ха!.. Мактап башлады, хурлап бетерде.

– Сезгә көлке. Ничә көн инде менә читлектәге кош кебек утырам. Кичә Таврический садка чыккан идем. Садлыгы корсын! Яшел булмагач, ул нинди сад?! Урам себеркеләре кадап куйганнар диярсең. Шул себеркеләрне куак дип белеп, егет белән кыз в любви объясняться итеп утыралар. Менә хәзер дворник килер дә себеркене алып китәр төсле.

Тагын көлделәр.

Бераз утыргач, Тукай калтырана башлады.

– «Кунак» килде, егетләр. Аспирин батырдан арт сабагын укытып алыйк.

Габдулла дерелдәгән кулы белән бер кашык аспирин капты да су ялгап җибәрде. Бераздан калтыравы бетте, кансыз йөзенә зәгыйфь алсулык йөгерде. Бер байда приказчик булып эшләү белән бергә, газетада язышa торган Кәрим:

– Докторга күренергә кирәк сезгә, Габдулла әфәнде, – дип куйды.

Студент-юрист Шакир эләктереп алды:

– Безнең университетта үлгәнне терелтә торган доктор бар. Чакырыйк үзен.

– Терене үтерәләр дисәңче! Казанда берсенә күренгән идем. Чахотка ди! Ахмак түгел диң. Бусы холера табар.

Казанда чакта ук Тукай белән аралашкан кеше буларак, Хәбир шагыйрьнең гадәтен яхшы белә иде. Икенче яктан килеп карарга уйлады ул:

– Тап-таза кешеләр дә врачка күренгәләп торалар, Габдулла.

– Әнә ваше благородиеләр күренсен. Мин врачсыз да теге дөньяга юл табармын.

– Сез нәрсә, Габдулла әфәнде! Пессимизм? – диде Шакир.

– Кояш-аемны югалттым мин, дуслар. Тирә-ягым дөм караңгы. Авыруыма түгел, аның җиңел булуына, әҗәл алып килмәвенә ачынам. Кояш-айсыз яшәүгә караганда, үлем мең өлеш артык!

Газраилне чакыруы әнә ничек булган иде.

– Күзегезне зуррак ачып карагыз, Габдулла әфәнде! – диде кайсыдыр.

…«Таш капчык»тан котылгач, Тукай күзен киң ачып караган иде – шаккатты: Петербург гөжли, Петербург кайный! Лена эшчеләрен атуга протест авазлары яңгырый. Стачка, митинг, демонстрацияләр. Моңарчы туганына да әйтергә шикләнгән сүзләрне яшьләр кычкырып әйтәләр. Татар егетләре дә руслардан калышмыйча, көрәшкә җиң сызганалар. Мулланур Вахитов дигәнен татарлар гына түгел, руслар да сокланып телгә ала икән.

Бер демонстрациянең итәге Габдуллага да кагылып узды. Исаакий мәйданына «Бакыр җайдак»ны карарга барганнар иде. Мәйдан шактый аулак. Кешеләр берән-сәрән генә үткәләп торалар. Бервакыт Невский ягыннан халык гөжләгән тавыш ишетелә башлады. «Смело, товарищи, в ногу», «Бәхилләшү маршы» көйләре колакка керде. Ул да булмады, мылтык аткан тавыш ишетелде.

Невский ягын сагаеп күзәтә башладылар. Дүрт-биш минут үтмәгәндер, бер төркем кеше мәйданга килеп керде дә Габдуллалар басып торган якка таба ташланды. Берсенең кулында кызыл байрак.

Килеп җиттеләр. Кыска козыреклы фуражка кигән яшь кенә егет байракка үрелде.

– Алексей Степаныч, бирегез миңа!

– Тайпыл, Вася!

Алексей Степаныч дигәненең янәшәсендә йөгереп килгән картрак эшче байрак сабын учлады да:

– Бир, Степаныч, – диде. Тегесе кулын ычкындырды. Егет байракны эләктерде дә, иптәшләрен алга үткәреп җибәреп, берничә егет белән бергә ашыкмыйча гына юлын дәвам итте. Атка атланган өч жандарм чаптырып килеп җитте. Берсе камчы белән селтәнде:

– Бросай!

Байрак чайкалып куйды да яңадан турайды. Жандарм, киерелеп, Васяның башына камчы белән сукты. Икенче жандарм байракны тартып алды да җиргә ташлады. Егетләрне, атлар уртасына алып, төрмәгә озата киттеләр.

Шушы вакыйгадан соң Габдулла ике көн буе эчмичә исереп йөрде. Тора да үзен шелтәли, тора да шелтәли иде: «Ни йөзең белән газраил чакырдың син? Ахмак! Саламторхан!»

Кичә күкрәккә тыгызланып тулган тойгылар, ниһаять, тышка бәреп чыкты. Көнне төнгә, төнне көнгә ялгап, Габдулла әллә ничаклы шигырь язып ташлады. Әнә, өстәлдә өелеп яталар. Ни чыккандыр инде… Төзәтәсе бардыр, билгеле.

Ишек шакыдылар да, җавап көтеп тормый, бүлмәгә керделәр.

– Сәгать унбер, ул урыныннан тормаган! – диде Хәбир. – Аристократлаштың, Габдулла.

– Кәрим, бар кофе китер, – дип эләктереп алды Шакир.

– Утыңны да сүндермәгәнсең ич.

Хәбир включательне борды да, өстәлдәге кәгазьләрне күреп, Тукайга таба борылды:

– Башыңда акылың бармы, юкмы? Саулыгыңа малайларча карыйсың.

– Акушерка булганың юк ахры, мелла Хәбир?

– Акушерканың ни катнашы бар?

– Туа башлаган баланы туктатып кара син! Йә ярар, мин юынып килим. Бер-берегезне юата торыгыз.

Габдулла чыгып киткәч, Кәрим акрынрак тавыш белән:

– Тукайны әзерләү кем өстенә төшә? – дип сорады.

– Хәбир инде, – диде Шакир. – Әшнәләр ич.

– Кыен, шайтан алгыры… Доктор дисәң, хәзер керпе кебек, чәнечкеләрен торгыза башлый. Алдан әйтмичә генә, докторны өстенә китереп кертсәк?

– Ярамый, – диде Шакир. – Куып чыгарса, мин ни хәлдә калам? Тукайның кем икәнен сөйләп аңлаткач кына ризалык бирде.

– Мине тыгасыз икән инде арслан авызына, хәерле булсын, – диде Хәбир, елмаеп.

Шат чырай белән Тукай килеп керде.

– «Кунак» бүген дә килмәде! Алдан кычкырган күкенең башы авыртмагае, – диде Хәбир.

(Дәвамы киләсе санда).

Камил Мотыйгыйны искә алганда

БЕР ХАТИРӘ

XX башы татар мәдәниятенең үсешенә зур өлеш керткән Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллинның (Мотыйгыйның) тууына быел 140 ел тулды. Хәзерге буыннар әлеге күренекле милләттәшебез турында күпмедер мәгълүматлы дип аңларга кирәк. Шулай да аның тормышын һәм эшчәлеген өйрәнүдә замандашлары бәян иткәннәр бик кыйммәтле.

К. Мотыйгыйның сеңлесе Галия Кайбицкая шундый хатирәләрне дә кадерләп саклаган. Шуларның берсе – заманында «Кызыл Шәрекъ» газетасында эшләгән журналист Сәгыйть Уламаев сөйләгәннәр. Галия апа аларны үз кулы белән калын дәфтәренә язып куйган (беraз кыскартылып һәм стиле җиңеләйтелеп бирелә).

«Мин иң беренче мәртәбә Камил Мотыйгыйны 1909 елда Уфада күрдем. Ул "Дворяннар җыены" сараеның зур залында җырлады. Зал халык белән тулган иде. Тамашачылар – каланың байлары һәм аларның чуар киенгән хатыннары, приказчиклар. Без, ятимнәр йортында тәрбияләнүче малайлар, билет алырга акча булмагач, Хәмит дигән иптәшем белән качып-посып кына залга үтеп керә алдык, бер почмакка сыенып, аның җырлаганын тыңладык. Аның үз-үзен тотышына, җырлавына ис китте. Тавышы бөтен залга яңгырап тора.Өстендә биек ак якалы матур күлмәк, кара сюртук. Башында кырынрак салып кигән биек кара хәтфә түбәтәй. Сәхнәгә чыгып күренүе белән тамашачыларның дикъкатен җәлеп итә торган кыяфәт. Озын буе, киң итеп елмаюы, кулын күкрәгенә куеп баш июе нәзәкәтлелек бирә, аны үз итеп кабул итүгә китерә. Салкын кыш көне булса да, кич буе җыр яңгыраган залда җылы, рәхәт иде.

Аның каруы үзебез укый торган «Госмания» мәдрәсәсе янындагы ятимханәгә кайткач, «җылы» гына түгел, «эссе» дә булды. Карый Габдулла абзый безнең концертка киткәнне ничектер белгән икән. Кайтышыбызга озын чыбыклар әзерләткән. Безне шул чыбыклар белән пешекләде:

– Менә сезгә, менә, икенче тапкыр концертларга йөрмәссез, – дип кычкыра-кычкыра, чыбыкларны аркабызда чыжылдатты. Чыбыклары сынып беткәч кенә кыйнаудан туктады. Тән буена сызланып чыктык. Иртә белән аркаларыбызны караштык. Тал чыбыкларының эзләре кып-кызыл булып бүртеп тора иде. Шулай итеп, Камил абыйның җырлавын беренче тапкыр тыңлавыбыз гомергә истә калырлык булды.

Дүрт елдан соң, ягъни 1913 елда мәдрәсәдә шәкертләр күтәрелеше булды. Хәмит белән мин дә шулар арасында идек. Җитмешләп егет укуны ташлап чыгып киттек. Яңадан кайтып, заманча, фән дәресләре кертүгә ирештек. Күп еллар буена, балаларның гомерләрен әрәм иткән, төрле хорафатлардан башканы белмәгән хәлфәләрдән үзебезне азат иттек. Мәдрәсәне төрле фәннәрдән мәгълүматлы мөгаллимнәр кулына тапшырдык.

1918 елның июль аенда мин Уфадан делегат булып Советларның 5 нче съезды эшендә катнаштым. Делегатларга Зур театрда концерт та күрсәттеләр. Иң беренче булып Федор Шаляпин чыкты. Зур гәүдәле, матур йөзле. Ул, җырлар алдыннан болай диде:

– Бирегә илебезнең күп халыклары вәкилләре утыра. Мин милләтем буенча рус кешесе. Шуңа күрә чыгышымны рус халык җыры белән башлыйм. Миңа кушылып җырларга да мөмкин.

Ул «Дубинушка» җырын башлады. Кая ул аңа кушылу, өч меңләп кеше, тын да алмыйча, аны тыңладык. Зал аңа көчле кул чабып рәхмәт әйтте. Аннан соң Казанда туган бу бөек җырчы, инглиз, алман, француз, итальян телләрендә җырлап, бөтен кичәне бервүзе алып барды. Аның көчле, матур тавышын тыңлап, илебезнең төрле урыннарыннан җыелган халыкның исе китте.

Мин, Шаляпинны тыңлаганда, Камил ага Мотыйгыйны күргән кебек булдым. Алар янәшә торсалар, Камил абый да оттырмас иде кебек тоелды. Буйга да, тәскә дә бер-беренә торышырлык. Тавышлары да охшаш кебек тоела. Икесе дә ниндидер сыйфатлары белән үзләренә җәлеп итәләр, бирелеп тыңлаганыңны сизми дә каласың. Аларны якынлаштырган нәрсә, минемчә, халыкчан җырлауларында.

Камил аганы мин 1919 елда, Җаек шәһәре азат ителгәч, 4 нче армия политотделында очраттым. Ул – 1917 елдан бирле революция ягында сугышларда катнашкан, патша яклыларга каршы көрәшен дәвам иттергән шәхес. Г.Тукайга да аның йогынтысы булмый калмаган. Камил ага ленинчы көрәшче булган. Ул безнең газетага да мәкаләләр китерә иде. Аның яшьләрне революция рухында тәрбияләргә чакырган мәкаләләрен бик теләп баса идек.

Шулай да Камил ага күңелемдә барыннан да элек җырчы булып саклана. Күрсәң, үсмер вакытта аның җырлавыннан алган тәэсирләр гомер буена сакланып калган.

1963 ел

АБЫЙСЫНЫҢ НАМУСЛЫ ИСЕМЕН ЯКЛАУЧЫ

Билгеле булганча, әле илленче-алтмышынчы елларда да Камил Мотыйгый һәм Габдулла Тукай турында сүз алып баргында, әдәбият тарихчылары халкыбызның бу ике күренекле шәхесен бер-берсенә каршы куеп язалар иде. Янәсе берсе изүче, икенчесе – изелүче. Бу хәтта әдәби әсәрләрдә дә шулай сурәтләнде. Шуңа борчылып, 1975 елда Татарстанның халык артисты, күренекле опера җырчысы Галия Кайбицкая Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы Мидхәт Мөхәррәмовка хат яза. Ул фән оешмасы җитәкчесе алдына кистереп мондый сорау куя: «Матбугатта Тукай белән Мотыйгыйны каршы куюларга чик булырмы?».

Профессор М.Мөхәррәмов болай дип җавап бирә:

«Дөрес, моңа кадәр әдәбиятчыларның кайбер тикшеренүләрендә К.Мотыйгыйны Тукайга каршы кую, алар арасындагы каршылыкларны күпертеп күрсәтү очраклары булды. Әмма соңгы вакытларда бу хәл төзәтелә бара.

Киләсе елда булачак Тукайның 90 еллык юбилее уңае белән институт дүрттомлыкның яңа басмасын чыгарырга әзерли. Бу басмада әдипнең әсәрләренә искәрмәләр өр-яңадан эшләнә. Аны башкаручы иптәшләр Тукай әсәрләрендә очраган тарихи фактларга элек бирелгән бәяләрдәге төгәлсезлекләрне төзәтергә тырышалар. Шул уңайдан К. Мотыйгыйга карата урынсыз яки төгәлсез әйтелгән сүзләргә дә игътибар ителәчәк. Аларның җитешсезлекләре, каршылыклары билгеле бер тарихи чор, заман каршылыклары. Тукай томнары өстендә эшләүче иптәшләр, шуны истә тотып, һәр тарихи фактны объектив бәяләргә омтылалар».

Һәм, чыннан да, Рашат Гайнанов тарафыннан төзелеп, искәрмәләр әзерләнеп бастырылган әлеге дүрттомлыкта бу җәһәттән күп нәрсәләр төзәтелде. Бу очракта фәнни редактор Гали Халитнең, нәшрият редакторы Рәис Даутовның хезмәтләрен дә искә алырга кирәк. Әйтик, Г. Тукайның «Авыл җырлары (икенче көлтә)» шигырендә мондый строфа бар:

Аягында итегең, сахтияндыр читегең;
Мотыйгыйдан сорашыгыз мөхәррирлек читенен.

Монда искә алынган «Мотыйгый»га бирелгән искәрмәдә инде моңа кадәр бу шәхескә карата кулланыла торган «буржуа», «хуҗа», «эш бирүче» кебек сүзләр юк, гадәти генә бәян итү күзәтелә: «Уральск шәһәрендә 1905-1908 елларда «Фикер», "Уралец" һәм «Уральский дневник» газеталарын, «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» журналларын чыгарган нәшир һәм редактор Камил Мотыгый күздә тотыла. Ул, газета һәм журналларда демократик карашлы материаллар баскан өчен, патша властьлары тарафыннан эзәрлекләнә, татар реакционерларыннан күп кыенлыклар күрә. Монда шуңа ишарә». Күрәбез, җир белән күк арасы кебек аерма. К. Мотыйгый «демократик карашлы материаллар» басучы мөхәррир буларак тәкъдим ителә. Дөреслек торгызыла. Г. Кайбицкая да, бу хәлне күреп, ихлас кинәнү кичерә. Ни генә дисәң дә, мондый үзгәрештә аның да өлеше бар бит.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН,
КФУ профессоры.

Оператив саташтыру чаралары

Соңгы атналарда мәгълүмат чараларында иң кайнар темаларның берсе булып, мөгаен, АКШ разведка даирәләреннән ни рәвешледер читкә чыккан йөзләрчә яшерен документның, социаль челтәрләр аша, киң җәмәгатьчелеккә таралуы булгандыр. Андагы мәгълүмат төрле илләргә, шул исәптән, Украинадагы кайбер четерекле вакыйгаларга да кагыла. CNN каналы хәбәрләренә караганда, хәрби сер ачылуы сәбәпле, Киев контрһөҗүм планына кайбер үзгәрешләр кертергә дә мәҗбүр булган. Игътибарны, әлбәттә, бу вакыйгага Россиянең хәрби экспертлары биргән бәя дә җәлеп итә. Әйтик, РФ Генштабында хезмәт иткән полковник М.Ходаренок аны, алда торган язгы контрһөҗүм алдыннан, каршы торучы якларны саташтыру ниятендә кылынган оператив маскировка чараларының бер элементы итеп кенә бәяли.

Әлбәттә, оператив саташтыру чаралары моның белән генә чикләнми. Әйтик, АКШ журналисты Сеймур Херш (аның «Төньяк агымнары»н АКШ шартлатуы турында февральдә чыккан язмасы дөньяда зур шау-шу тудырды) үзенең блогында, АКШның хәрби җитәкчелеге, Россия Украинада җиңелгән очракта, анда конфликтны туктату буенча килешү проекты әзерләве, шулай ук четерекле кайбер башка хәлләр турында да язып чыккан. Ә The Washington Post газетасы узган атнада, һава торышы белән бәйле рәвештә һәм сугыш кирәк-яраклары акрын куелуы сәбәпле, Киевнең язгы һөҗүмне кичектерүе турында язган иде. Имеш-мимешләргә үз өлешен Украинаның саклану һәм дәүләт иминлеге шурасы секретаре А.Данилов та өстәгән. Ул контрһөҗүмнең башлану вакыты турындагы карар иң соңгы мизгелдә кабул ителәчәк, дип әйткән. Кыскасы, оператив саташтыру уены дәвам итә.

Сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. КХР рәисе Кытай кораллы көчләренә сугышка әзерлекне көчәйтү буенча күрсәтмә биргән. АКШ һәм Канада Россиягә каршы яңа санкцияләр керткән. БМО КШ Судандагы низагта катнашучы якларны, кичекмәстән атышны туктатып, сөйләшүләрне яңартырга чакырган. Норвегия Россия илчелегендәге 15 хезмәткәрне «нон-грата персоналар» дип игълан иткән. Россия Президенты В.Путин Тын океан флотында сугышчан әзерлекне тикшерү нәтиҗәләрен югары бәяләгән.

Фоат УРАЗАЙ.

● Татарстан Премьер-министры А.Песошин белән.

● Сарман районы Иске Әлмәт авылының «Морад Рәмзи» мәчете.



● Әгерҗе районы Кырынды авылының «Тердәле» мәчете.

«Нурлы ислам»

Казан дәүләт милли тикшеренү техник университеты аспиранты Ринат Исламов – бүгенге талантлы яшьләребезнең бер вәкиле. Ринат Таһир улы берничә күркәм проектка алынган җәмәгать эшлеклесе дә әле, гомумән, булдыклы, күп саваплы гамәлләр кылучы ихлас мөселман!

– Ринат, сез балачактан ук шулай кыю һәм активмы?

– Әйе. 1993 елның 2 октябрендә Мөслим районының Иске Карамалы авылында туганмын. Әнием Илүсә яшь чагында Әндереш авылы клубын җитәкләгән булган, мәдәният белән кызыксынуым нәселдән килә. Әтием Таһир да баянда оста уйный иде. Үзем дә 5 яшемдә үк сәхнәгә чыктым. Шигырьләр сөйләдем, җырлар җырладым. Рәсем ясау сәләтемне дә эти ачты, 4-5 яшемдә балалар бакчасында, башка сабыйлар кулларында каләм бөтереп утырганда, нинди дә булса җәнлек яисә бөҗәк сурәтен бик тиз арада ясап та куйганмын, диләр. Рәсем сәнгатен хәзер дә үз итәм! 6 яшемнән бию түгәрәгенә дә теләп йөрдем. 13 яшемнән алып 18 яшемә кадәр театр түгәрәгендә дә шөгыльләндем. Республика конкурсында «Беренче театр»ны куйганда, Вәли кияү ролен башкардым...

– Сез мәдәният юнәлешен дә сайлап ала алгансыз, ә ни өчендер техника белән бәйле югары уку йортына юнәлгәнсез...

– Әтием дә, бабам да алтын куллы иде, самавыр да ямыйлар, тәрәзә кысаларын да ясап куялар иде. Әтием техниканы шулкадәр дәрәҗәдә яратты, хәтта эштән кайтуга тракторын ялт итеп юып куя иде. Ремонт эшләрен тулысынча белде, җиренә җиткереп төзәтте, аның вафатыннан соң (кызганыч, мин укырга кергәч, ике атнадан әтием үлеп китте) ул рәтләп калдырган техника чаралары озак еллар буе ватылмыйча эшләде. Мин гел әтием янәшәсендә булып, барсына да төшенеп үстем. Ул мине шәп итеп шашка-шахмат уйнарга да өйрәтте әле! Гаиләдә без ике бала, апам – шәфкать туташы һөнәренә укыды. Ә менә Актаныш районы Чуракай авылыннан туганнан туган Радик абый Казан дәүләт энергетика университетында укыды, 6 нчы классны тәмамлаганда ул миңа: «Бәлкем, син дә шушы уку йортына керерсең?» – диде. КДЭУны аның үрнәгендә сайладым. «Сәнәгать предприятиеләрен электр белән тәэмин итү» белгечлегенә укыдым, сессияләрне еш кына экстерн рәвештә бирдем, чөнки тизрәк авылга кайтып, андагы эшләрне карашасым, әниемә булышасым килә иде. Волейбол, бадминтон, йөгерү буенча район ярышларында катнашып, җиңүләр яулый идек. Техникага да күңелем ята. Студент чакта Мөслим районында уза торган «Кулибин» бәйгесендә катнаштык, орлык чәчү җайланмасы белән II урынны яуладык.

– Студент тормышы бик күңелле була, хәзер алар өчен нинди генә бәйгеләр оештырылмый...

– Әйе. 2012 елда, университетның I курсында укыганда ук, «Татарстан Республикасының 50 инновация идеясе» конкурсының «У.М.Н.И.К» номинациясендә җиңдем. Бу бәйге инновация эшчәнлегенә аша үз-үзләрен табарга омтылучы яшь галимнәрне барлау һәм аларга ярдәм итү программасы белән дә бәйле иде. Университет җитәкчелеге шаккатты дисәм дә була, чөнки орлык чәчү җайланмасы бу уку йорты юнәлеше белән бәйле дә түгел бит.

Туган ягыма еш кайтып йөргәч, район эшмәкәрләре белән дә танышып, дуслашып киттем. Төрле мәсьәләләрне җиңелрәк чишү алымнарын эзләргә дә яратам, башкаларга булышлык итәсем килү теләге дә зур иде. Шулай итеп, 21 яшемдә Иске Карамалы авылы депутаты булып сайландым, эшкә керештем.

Мөслимдә «Мин Тукайны яратам» дигән бәйге оештырдык. Бәйге шартлары буенча, мәктәп балалары шигырь сөйләп, җыр җырлап, видеоязма юлларга яки рәсем ясарга тиеш иделәр, ике атналык конкурста 400 бала катнашты. Йомгаклау тантанасына 100 кеше җыелды, 30 бала шул чарада ук рәсем ясап күрсәтте!

– Ринат, сезгә актив җәмәгать эшчәнлеге ошап киткән.

– 2015 елда, 22 яшем тулганда, «Кадровый резерв» конкурсында катнашып, 150 кеше арасында җиңүчеләр исемлегенә кердем. 2017 елда «Вверх» республика бәйгесендә җиңү яуладым. 2017-2018 елларда – Татарстан Республикасының Яшьләр хөкүмәте аппаратын җитәкләдем. 2019 елдан алып – Татарстан Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзасы. 2020 елдан – Мөслим районы депутаты һәм Федерация Советы каршындагы Яшь закон чыгаручылар палатасында Татарстан вәкиле. Бүген мин тораклар төзү, электромонтаж эшләрен башкара торган, башка төр төзелеш-монтаж эшләрен алып барган «Күз» ширкәте җитәкчесе дә.

Кара диңгез Хәрби-диңгез флотында хезмәт иттем, буш вакыт табып Кырым шәһәрләренең мәчетләрендәге җомга намазларына да җитешә идек. Мәктәптә укыган елларда ук, әти-әниемнән рөхсәт сорап, мәчеттә дин белемнә төшендем, намаз укырга, догалар кылырга өйрәндем. Ул елларда мәчетебездә 30-40 лап бала гыйлем җыйды.

– Аннары нинди зур яңа проектка алындыгыз?

– 2013 елда «Яшьләр инновация идеясе» республика бәйгесендә җиңдем. 2018 елда «Республика яшьләре форумы»нда катнашып, «Актаныш гармуннары» – Бөтенроссия татар гармуны фестивале проектын тәкъдим иттек, II урынны яуладык. Беренче зур хезмәтебез шушы булды. Фестиваль Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан оештырылды, уңышлы узды. Һөнәри һәм һәвәскәр гармунчыларны бергә туплап, аларның бергәләп чыгышлар ясауларын максат итеп куйдык. Әтиемнең баянда яхшы уйнаганын да гел истә тота идем. Аның баянда уйнаганы яздырылган видеоны социаль челтәрдә тәкъдим иттем һәм язманы 180 мең тапкыр карадылар.

Гармунчылар белән бәйле чараны оештырыр алдыннан, Татарстанның халык артисты, баянчы Кирам Сатиев белән дә киңәшләшеп тордык. Фестиваль төрле яшьтәге 300 гармунчыны берләштерде, Актаныш әлеге фестивальгә бәйле һәйкәл дә куелды әле.

– Сез әле Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасында да хезмәт куясыз. Бу юнәлештә нинди уңышлы эшләр башкарырга җитештегез?

● Әгерҗе районы Кичкетаң авылы мәчете.



● Әтнә районы Күңгәр авылы мәчете.

● Зөлфәт белән.

● Яшьләр парламетында чыгыш.

мәчетләрне балкыта

– 2019 елдан Казан илкүләм тикшеренү техник университеты аспирантурасында укый башладым. Алачак белемем техник процесслар белән идарә итүне автоматлаштыру белән бәйле. 2020 елда, локдаун башлангач, республика, район җитәкчелеге һәм район эшмәкәрләре арасындагы киңәшмәләребезне читтән торып, онлайн форматта уздырдык. Әлеге чарада 36 район катнашты һәм без 3000 нән артык эшмәкәрне туплый алдык. Киләсе адымыбыз районнарны «Сәүдә-сәнәгать палатасы»нда иганәчеләр белән таныштыру булды. Һәр чарада да читтән торып 100 кеше катнашса, палата бинасында 150 кеше җыя идек. Район белән килешү төзегәннән соң эшмәкәрләр белән чит төбәкләрне өйрәнергә юл тоттык.

– Ринат, татар яшьләрен берләштерүгә дә өлеш кертәсез. Бу хакта да тулырак бәян итегез әле.

– Ул проектка дүртенче ел. 2019 елда татар теле укытучысы Эльвина Нәҗипова белән берлектә татар яшьләрен үзара таныштыру-күрештерү проектын башлап җибәрдек. Без юлда идек һәм «Һава» мәчетебездә җомга намазы кылырга тукталдык. Бу – Лаеш районы Олы Кабан авылы мәчете. Шулчак аның имам-хатыйбы хөрмәтле Рәшид хәзрәт Вилданов белән әңгәмә кордык, ә ул татар яшьләрен бергә җыеп, берәр мәдәни чара оештырып җибәрә алмассызмы икән, диде. Безгә шул җитә калды, юлыбызны дәвам итүгә үк, татар мөселман яшьләрен бер-берсе белән очраштыру-таныштыру кичәләрен үткәреп карарга кирәк дигән карарга килдек. Янәшәмдә буйдак егетләр бар, Эльвинаның танышлары арасында да әлегәчә гаилә кормаган кызлар җитәрлек иде. Бу саваплы проект булыр дип уйладык. «Хава» мәчетендәге беренче кичәгә унбиш студент килде. Рәшид хәзрәт тә безгә булышлык күрсәтте, кичә күңелле узды. Шулай итеп, кичәләр айга бер мәртәбә, бушлай үткәрелә башлады. Рәшид хәзрәт яшьләрне концерт, спектакльләргә билетлар бүләк итеп сөендерде. Шулай итеп алдагы айларда кафе, ресторанда, бозлавыкларда очрашулар оештырдык. Аннары шеф-ашчы булып эшләүче бер егетебез безне үзе хезмәт куйган ресторанга чакырды, анда безгә төрле салатлар ясап, ят ризыклар пешереп күрсәттеләр. Әмма күңелләребезгә милли ризыкларыбыз якын булуын аңладык, бары тик татар көйләре, мөнәҗәтләр яңгыраган, бары милли ризыкларыбызны гына пешереп карарлык урынны эзли башладык. Нәтиҗәдә, өченче оештыручыбыз Алинә Габдуллина белән «Туган авылым» комплексы җитәкчесе Радик Абдрахманова мөрәҗәгать иттек, ул үтенечебезне кире какмады. Шәһәр үзәгендәге комплексны сайлавыбыз «Хава» мәчетенең шәһәрдән ерактарак булуы белән дә бәйле иде. Әмма милли чарабызның башлангычы мәчет белән бәйле булуын без һәрчак истә тотабыз. Әлеге таныштыру кичәләрен «Татар яшьләре кичәләре» дип атадык. Бу проектка уңай бәяләмәләр башка шәһәрдә яшәүче татар егет һәм кызлары колагына да барып ирешә, аларга инде Татарстанның берничә районыннан, калаларыннан, Мәскәү, Уфадан килүчеләр дә булды. Татар кызлары белән дуслашырга, кавышырга теләп, хәтта Дубай татарлары да шалтыратты. Кичәләрдә милли уеннар уйналды, курай моңнары яңгырады, милли ризыклар пешерү буенча, мөселманнарча итеп яулык ябу буенча һ.б. осталык дәресләре узды... Моннан кала танылган сәхнә һәм эстрада артистлары чыгышларын да кызыксынып тыңладык. Чарабызда психологлар Зөлфәт Зарипов һәм Альбина Габдуллина да теләп катнашты. Дөрес, без мондый кичәләрне узган елның май аеннан соң үткәрми торабыз әле. Дөньялардагы авыр вәзгыять барыбызга да тәэсир итте дияр идем һәм хәзерге чорда күңел ачып йөрүне дөрес шөгыль дип тапмыйбыз.

– Ринат, Татарстан районнарында урнашкан мәчетләребезне ут белән бизәү, аларны тышкы яктырту корылмалары белән җиһазландыру проектыгыз кайчаннан тормышка ашырыла һәм бу эшчәнлегегездә кемнәр булышлык итә?

– Без бу эшкә шулай ук 2019 елда алындык. Дустым, Казанның танылган психологы Зөлфәт Зарипов белән 2022 елда чираттагы мәчетне яктырткач, бу эшне «Нурлы ислам» проекты исеме белән дәвам итергә булдык. Шул нисбәттән без Бөтендөнья татар конгрессының Татар эшмәкәрләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе, җәмәгать эшлеклесе Фәрит Уразаев белән дә хезмәттәшлектә. Эшебезне мөфтиебез Камил хәзрәт Сәмигуллин белән фикерләшеп, киң җәмәгатьчелеккә дә җиткердек.

Мәчетләрне гади ысуллар белән, ләкин заманча яктырту теләгебезне тормышка ашырабыз. Бүген без, машаллаһ, 16 мәчетне ямьләдек. Болар: Лаеш районының Олы Кабан авылындагы «Хава» мәчете; Әтнә районы Күңгәр авылы; Мөслим районы Яңа Карамалы авылы, Иске Карамалы авылы, Ташлыяр авылы; Сарман районы Иске Әлмәт авылы; Теләче районы Балыклы авылы; Арча районы Яңа Кенәр авылы; Әгерҗе районы Кырынды авылы, Иж-Бубый авылы, Кичкетаң авылы мәчетләре һ.б. Проект мәхәллә халкы, иганәчеләр һәм командабыз белән берлектә тормышка аша бара. Бу ниятебезне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов 2022 елда узган «KazanSummit»нда хуплады, үз фатихасын бирде.

Мәчетләребезне ут белән яктыртулардан рухи ләззәт алабыз! Эшебезне җиренә җиткереп тәмамлап, арып, кайтыр юлга чыккач, хәтта туктап биеп алган чакларыбыз да була. Шәһәр мәчетләре төнлә яктыртылып торганда, нишләп әле авыл мәчетләре караңгыда булырга тиеш, ди... Моны аңлаучылар, фикердәш дусларым күп, шуларның берсе Арча районы Яңа Кенәр авылы мәчетен ут белән яктыртуда иганәче дә булды. Аның әбисе мәчет янәшәсендә гомер итә, оныгы аны шулай шатландырды, ул әбисенә: «Мин төнлә торып та, мәчетебезгә карыйм бит» дигән сүзләрен истә тоткан иде. Республикада 1500 дән артык мәчет эшли, машаллаһ. Максатыбыз: буш вакыт табып, проектны алга таба үстерү.

– Ринат, мондый яктырту җайланмалары кыйммәтме?

– Бер көнне Мәскәүгә баргач, андагы «Яуза» паркы җитәкчесеннән сораган идек, ул: «Мондый эшне тулысынча башкарып чыгу бер миллион сумга төшә ала», – диде. Чыннан, кайбер оешмалар шундый бәягә дә эшләргә мөмкин. Әмма безнең очракта алай түгел. Чөнки бу хезмәтне тулысынча башкару илле меңнән дә артмаска мөмкин. Ә манараны яктырту җайланмасы җыелмасының бәясен без 15 меңлек итеп тә туплый алабыз. Чөнки бу эшкә кирәкле махсус кронштейннарны туган ягымда, безнең Иске Карамалы авылында да ясыйлар!

– Якын киләчәккә планнарыгыз нинди? Тиктормас Ринат нинди чаралар үткәрергә әзерләнә?

– Шушы көннәрдә без мәктәп балалары арасында мәчетләрнең төнге күренешләре сурәтләрен ясау белән бәйле «Нурлы ислам» рәсем конкурсын башладык. Җинүче мәчеткә манара яктырту җыелмасын бүләк итәчәкбез, балаларны да бүләксез калдырмабыз. Балаларның күңелләре кечкенә чактан ук иман нуры белән тулса, җәмгыятебез дә яхшыра гына барыр, иншаллаһ!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.


● Мөслим районы Иске Карамалы авылының «Борһан» мәчете.

● Лаеш районы Олы Кабан авылының «Хава» мәчете.

Хата күрдеңме – битараф калма

Татарстан халкы 1 нче апрельдән 1 нче ноябрьгә кадәр татар телендә язылган мәгълүмати табличкалар, топографик билгеләр, юл күрсәткечләре һәм торак йортларның аншлагларындагы исемнәрдә һәм язуларда хаталарны ачыклау буенча конкурста катнаша ала.

Фотоларны Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә мөмкин. Моның өчен iOS яки Android операцион системалары белән эшләүче телефонга мобиль кушымта урнаштырырга, аннары авторизацияләнергә һәм «Исемнәрдә һәм язуларда хаталар» категориясен сайларга кирәк.

Конкурста катнашу өчен элмә такта тулысы белән күрсәтелгән фотоматериаллар белән (аның нинди оешмага караганы күренергә тиеш) хәбәр җибәрергә кирәк, публикациядә төгәл адресны күрсәтү мәҗбүри.

Конкурска мөрәҗәгатьне конкурсны оештыручыга – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә язма рәвештә Konkurs.TatOmbudsman@tatar.ru электрон адресына яки 420015, Казан, Карл Маркс урамы, 61, 3 нче кат адресы буенча, яисә конкурс модераторына – ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтына түбәндәге электрон адреска: iyali.anrt@mail.ru яки түбәндәге адрес буенча: 420111, Казан, Карл Маркс ур., 12 җибәрергә мөмкин.

Конкурс җиңүчеләре берничә номинациядә билгеләнәчәк, бүләкләү тантанасы 2023 елның IV кварталында узачак.

Конкурс Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның милли мәдәнияте элементларын кулланыну популярлаштыруга юнәлдерелгән.



Бүгенге Башкортстан мәйданындагы йөзәрләгән татар авылларында яшәгән крестьяннарның XVII гасырдан башлап XIX гасыр азагына чаклы «Башкорт катламы»на күчәргә омтылып яшәве хакында без күп яздык инде. Сәбәбен дә аңлаттык: «башкорт» булып теркәлүгә ирешкән «бәхетле» татар ирләренә 40 тан алып 60 дисәтинәгә кадәр имана җире бүлеп бирелгән. Алар «башкорт» гаскәренә беркетелгәч, салым түләүдә, хәрби дәрәҗәләргә ирешүдә өстенлекләрдән файдаланырга мөмкин булган. Элек заманда Бәләбәй өязендә исәпләнгән, бүген исә Бакалы районына кергән Катай, Ногыш, Туктагол, Бикмәт авылларының ирләре дә әнә шул өстенлекләргә ирешү һәм аеруча 40-60 ар дисәтинә имана җире эләктерү өчен үзләрен «башкорт» катламына күчерү турында күп мәртәбә власть иясләренә мөрәҗәгать иткән. Нәтиҗәсез дә түгел, 1795 елда үткәрелгән 5 нче җанисәп барышында байтак гаиләләрне «башкорт» дип яздыруга ирешкәннәр дә бит.

БАКАЛЫДА БАШКОРТЛАШТЫРЫЛГАН АВЫЛЛАР

Уфа галиме Ә.Әсфәндияров үзе төзегән «История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий» атлы китабында Ногыш һәм Туктагул авылларының тугандаш булуы хакында менә ничек яза: «Ногыш – ул Туктагол авылыннан аерылып чыккан. 1795 елда андагы 12 хуҗалыкта 54 ир-ат һәм 48 хатын-кыз гомер иткән. Бөтенесе дә – башкорт. 1816 елда андагы 11 хуҗалыкта – 105, 1834 елда – 142 (икенче мәгълүматта 50 хуҗалыкта 479 башкорт - ???), 1859 елда – 189, ә 1870 елда инде 35 хуҗалыкта 197 башкорт гомер иткән».

Менә шушы хилаф мәгълүматлар, хәрефен-хәрефкә күчереп, «История башкирских родов. Канглы. Том 5» китабына да кучкән (96 бит).

Ләкин әлеге «махсус ялгышлар»га төзәтмә кертү һич тә читен түгел, 1762 елда үткәрелгән 3 нче ревизия мәгълүматларына гына мөрәҗәгать итик. Алар исә Ногыш авылында бу вакытта 26 татар ир-аты гомер итүе турында хәбәр итә. Өлкәннәре Мәсәгуть Чүриев – 78 яшьтә. Аның Гайсар, Монасыйп, Габдулла исемле өч улы бар. Алардан тыш Ишәле Сөлеков, Нияз Биккенин, Бакый Нәдеров, Ишембай Якупов, Мөкъсин һ.б. үз уллары белән гомер итә. 1773 елда башланган Пугачев явында Нокыш авылы ирләре старшина Юлдаш Ишбулдин һәм Илкилде Илмурзин отрядларында яу йөри.

Туктагол авылында ул вакытта 40 ир-ат яши һәм алар старшина Исмәгыйль Уразмәтовка буйсына. 1773 елда ирләр саны 46 га җитә.

Ногыш авылында 1784 елда уздырылган ревизия 43 ир-ат һәм 44 хатын-кызны исәпкә ала. Аларның һәммәсен документларда «типтәр» дип беркетеп куялар. 1795 елдагы ревизия вакытында Ногыш авылы документларда «Туктагулово тож» дигән исем белән дә теркәлә. Әмма бу юлы инде, казна палатасы фәрманы буенча, Ногышның элекке исемлектәге 8 ир-аты, алардан тыш тагын бертуган Зәбир һәм Гадбелҗәмил

Яркәевлар, Зәбирнең улы Галикәй һәм Исмәгыйл Мәүликәев (димәк, аларның гаиләләре дә) «башкорт» катламына күчерелә. Әмма, ни гаҗәп, шул ук кешеләр Туктагол авылында тупланган исемлектә «типтәр» буларак та исәпкә алына...

1816 елда Ногыш-Туктагол авылындагы 13 хуҗалыкта 51 ир-ат һәм 27 хатын-кыз «башкорт» булып теркәлә. 1834 елда алар саны 73 ир-ат һәм 69 хатын-кызга җитә. 1959 елда 96 ир-ат һәм 93 хатын-кыз булып теркәләләр. Гаилә башлыклары – Мөхәммәтсәлим Сәфәров, Габдулла Гайсаров, Моратша Мансуров, Сөләйман Исхаков, Тимербай Кашаев, Гобәйдулла Карчагулов, Котлызаман Кияляров, Мөхәммәтхәким Йосыпов, Миңлебай Габдрәшитов, Мөхәммәтҗан Мозаффаров һәм Корбангали Салихов. Фамилияләренә караган чагында ук, әлеге ирләрнең 1762 елда исәпкә алынган татар крестьяннарының уллары һәм оныклары булуы аермачык күренә. Ә менә Ә.Әсфәндияров хәзерләгән китапта 1795-1859 ел мәгълүматлары архив кәгазьләре белән тәңгәл килми.

Совет чорындагы беренче җанисәп кәгазьләрендә Ногыш авылы аерым күрсәтелми, андагы халыкның Бәләбәй кантоны Бүздәк волостендагы Туктагол авылы мәгълүматларына кушылып куелган булуы мөмкин. Аның буенча 1920 елда Туктаголда – 370, 1925 елда 220 хуҗалык исәпкә кергән.

Югарыда әйтелгән мәгълүматлардан аңлашылганча, Ногыш кына түгел, Туктагол авылының да күп кенә типтәре «башкорт» катламына күчерелгән булган. «Башкорт ырулары тарихы» китабында бу хакта сыңар сүз белән дә искә алынмый. Ә.Әсфәндияров исә үзе: «Туктагол авылы башкорт һәм типтәрләр тарафыннан нигезләнгән, 1752 елда тәүге тапкыр документларда телгә алынган. Үзләренең килеп утыруын алар 1755 елда Кангылы волосте вотчинниклары белән рәсмиләштергән. 1762 елдагы 3 нче ревизия вакытында 40 ир-ат типтәр яшәгән, башкортлар исәпкә алынмаган. 1762 елда типтәрләрнең гомуми саны – 87 гә, 1795 елда 225 кә җиткән. 1834 елгы җанисәп вакытында 297 «башкорт» һәм 663 типтәр исәпкә алынган. 1920 елда аларның гомумсаны 1834 булган, ләкин аларның барысын да «башкорт» дип теркәп куйганнар. Ләкин 1762 елда алар фәкать типтәр булып кына теркәлгән, асылда ясаклы татарлар булган бит», – дип язып куюдан да тайчынмаган.

Туктагол һәм Бикмәт авылларының тарихына тирәнрәк чумсак, алар 12 хуҗалык булып, 1738 елның 24 июлендә вотчинниклар белән үзара язма килешү төзү нәтиҗәсендә килеп төпләнгән. Салым һәм оброкларны башкортлар белән үзара тигез бүлешеп түләргә сүз беркеткәннәр. Кәгазьгә язып килешүне 1755, 1760, 1780 елларда кабат яңартканнар, ләкин килешүләрне рәсми оешмаларга илтеп һәм раслатып йөрмәгәннәр.

1834 елда Туктагол авылында 160 ир-ат һәм 177 хатын-кыз, шул исәптә 1795 елда «башкорт»ка әверелгән Галикәй Зәбиров гомер иткән. Алар 12 нче «башкорт» кантонының 17 нче Йорт старшинасы Дәүләтша Әсәнов командасына буйсынган. Авылда 112 ир-ат белән 113 хатын-кыз (26 хуҗалык) типтәр булып саналган. Ни гаҗәп, 1795 елда «башкорт»ка әверелгән Галикәйнең энесе Ибраһим типтәр булып калган. Туктагол авылы типтәрләре – старшина Гали Сәфәров, күрше авыл типтәрләре – Әхтәри Бикмөхәммәтов, «башкорт» булып язылганнары 12 нче кантондагы 10 нчы Йорт старшинасы Габделгаффар Әҗмәтев командасында исәпләнә. 1834 елда Туктаголдагы Әмир Габдуллин һәм Гобәйдулла Әмиров гаиләләре (14 җан) Елан-Чишмә волостена күчеп, анда да Туктагол авылын нигезли.

1859 елда Бакалы районындагы Туктагол авылында 449 ир-ат һәм 401 хатын-кыз исәпләнә. 19 хуҗалыкта гомер итүче халык – «башкорт», 25 хуҗалык типтәр булып языла. Авылның 49 яшьлек ирен көчләп чукындырып һәм Петр Капитонов исемен тагып, казак катламына күчерәләр, ул салым түләүдән дә азат ителә. Ә башбирмәс икенче типтәрне 1857 елда Себергә сөрәләр. Бакалы районындагы икенче Туктагол авылындагы 40 хуҗалыкта 1859 елда – «башкорт», 4 йортта – мишәр һәм 13 хуҗалыкта типтәрләр – җәмгысы 805 җан гомер итә.

Ә.Әсфәндияров әзерләгән китапларда татар авылларына кагылышлы мәгълүматларның яртысын бутап, катламнарны милләткә әверелдереп, халкын «башкортлаштырып» тезгән язмалардагы күрәләтә ялган һәм хәрәмләшү үзәкләрне өзә. Шул ук ялганы «Башкорт ырулары тарихы»нда күчермә рәвешендә куллану да фәкать татар халкын «башкортлаштыру» сәясәте өчен корылган.

Таһир КӘРИМОВ,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турысыннан узганда туктыйм да, күңелемнән аның диварларында беркайчан да эленмәгән истәлек тактасын укыйм: «Бу бинада 1917 елның 20-27 апрель көннәрендә Бөтенроссия мөселман укытучыларының I съезды уздырылды». Капкасыннан үзләренең талантларын, илаһи куәтләрен мәгарифкә багышлаган шәхесләребез – Галимҗан Баруди, Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин, Исхак Рәхмәтуллин, Нургали Надиев, Габдулла Ибраһимов (Шнаси), Әхмәтҗан Мостафин һәм энҗеле калфакларын чәчләренә кадаган мөгаллимәләребез Гыйльминур Нугай, Фатима Дәүләткилдеева, Мәрьям Мөштәри, Мәрьям Морадымова, Абруй Сәйфиләр килеп чыгар кебек...

Мөселман укытучыларының I съезды

● **Сөргенгә җибәрелгән татар муллалары (сулдан-уңга): Габдулла Апанаев, Салихҗан Галиев, Галимҗан Галиев-Баруди һәм Казан сәүдәгәре Габделхәмид Казаков.**

Патша хөкүмәте бәреп төшерелгәч, «иркенлекләр килде» дип ышанган саф күңелле, мәгарифне иман эше дип караган изге затларыбызның кайберләре генә әле алар. Ә күңелем капкасыннан үтеп, хәтердән китмәгәннәре күпме?..

1917 елның февралендә Вакытлы хөкүмәт урнашып, җыелышлар, сүз, матбугат иреге игълан ителү белән татар мөгаллимнәре уку-укыту тәртипләре, программалар хакында җыелып сөйләшергә була. «Казан мөгаллимнәр җәмгыяте» тиз арада корылтай уздыру эшенә керешә.

Дөрес, 1917 елга кадәр дә мондый хәрәкәтләр башланган була инде. 1905–1906 елларда Казан, Уфа, Оренбург, Троицк, Әстерхан, Орск, Самара кебек шәһәрләрдә генә түгел, хәтта зуррак авылларда да мөгаллимнәрнең төрле җәмгыятьләре оеша. Максатлары уртак: татар мөгаллимнәренең тормышын, эш шартларын яхшырту, мәдрәсәләрдә уку-укытуга үзгәрешләр кертү, барлык уку йортлары өчен бердәм программалар, ә һәрбер сыйныф өчен аерым дәреслекләр әзерләү, балаларны һөнәрле итү өчен һөнәр мәктәпләре ачу һәм телебезгә кергән чит сүзләрдән котылып, телебезне, әдәбиятыбызны камилләштерү, татар телендә дарелмөгаллимат ачу.

Казанда оешкан «Нәшре мәгариф» җәмгыятенең мөгаллимнәрне бергә җыярга, бердәм хәрәкәт итәргә төрлечә тырышып караганы да мәгълүм. Шул тырышлыкның нәтиҗәсе буларак, 1906 елның 13-16 август көннәрендә Казанга Россиянең татарлар яшәгән төрле почмакларыннан йөздән артык мөгаллим җыела. Әмма бу җыенны уздырырга рәсми органнар рөхсәт бирмәгәнлектән, алар утырышларын яшерен рәвештә «Болгар», «Сарай» кунакханәләрендә үткәрергә мәҗбүр була.

Икенче шундый зур киңәшмә 1907 елның 15 маенда Яңа бистәдәге Салихҗан Галиев мәдрәсәсендә ачыла. Бергә җыелган 59 укытучының да максатлары изге – мөгаллимнәр хәзерләү өчен курслар ачып җибәрү хакында сөйләшергә тели алар. Әмма 21 май көнне мәдрәсәне городовойлар, полицейскийлар чолгап ала. Мөгаллимнәрнең күбесе кулга алына, мәдрәсәдә тентү үткәрелә, уку әсбаплары тар-мар ителә. Озак та үтми, 1908 елның мартында, Салихҗан хәзрәт үзе дә кулга алына һәм бертуган абыйсы Галимҗан хәзрәт Баруди, Габдулла хәзрәт Апанаев һәм мәгариф эшенә якыннан булышып йөргән сәүдәгәр Габделхәмид Казаков белән бергә ике елга Вологдага сөргенгә озатыла. Татар мәгарифенә һөҗүм һаман да көчәя, киңәя генә. 1911 елда иң алдынгылардан саналган Иж-Буби мәдрәсәсе тар-мар ителә, җитәкчеләре һәм укытучылары кулга алына. Казан өязе Акъегет авылындагы (хәзерге Яшел Үзән районы) кызлар мәктәбе мөгаллимәләре Маһибирүзә һәм Мәнбәгыйль Адыловалар бары тик Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаганга күрә генә дә «хөкүмәт өчен куркыныч кешеләр» дип саналып төрмәгә ябыла. Бу җәберләүләр диңгездән бер тамчы гына әле.

Сагыш һәм горурлык белән искә алынырга тиешле зыялылар безнең мөгаллимнәребез. Нинди генә кысуларга, җәберләргә карамастан, халык мәгарифе өчен борчылып, аның киләчәге турында уйлап, иҗади югарылыкка ирешүенә өметләнгәннәр бит. Күбесе хезмәт хакын да вакытында ала алмаган, хәтта булган акчасын фәкыйрь балалар белән бүлешеп яшәгән фидакарь җаннар алар.

Съездга чиксез дулкынланып, хыяллары, ниһаять, тормышка аша дип ышанып килә татар мөгаллимнәре. Беренче тапкыр, кулга алынудан, төрмәгә утыртудан, мәсхәрәләүдән курыкмыйча җыелулары бит. Залда – йөзгә якын делегат һәм күпсанлы газета-журнал хәбәрчеләре. «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Ягъкуб Хәлили бик матур күренешкә игътибар итеп яза: «Корылтай барышында, – ди ул, – кара көчләр тарафыннан изелеп, шул изелүләргә риза булмыйча баш калкытып мәйданга чыккан, яртымызны тәшкил иткән ханым вә туташ мөгаллимәләргә залда аерым урыннар хәзерләнгән иде. Мөгаллимнәр аларны зур хөрмәт күрсәтеп, шул урыннарга озатып куйды». (Хәзер мәгарифтә эшләүчеләрнең 80 процентка якыны хатын-кызлар. XX гасыр башындагы мондый хөрмәткә инде өметләнеп тә булмый. Әллә тигез хокуклылыкның да гаебе бар микән?!)

Корылтайны Казан мөгаллимнәре исеменнән күренекле педагог Әхмәтҗан Мостафин ачып җибәрә һәм шунда ук корылтайның рәисе итеп тә сайлана. Корылтайның башка утырышларында Габдулла Шәнаси (Шнаси) рәислек итә. Катнашучылар теләге белән алга таба корылтай «Бөтенроссия укытучылар съезды» дип атала башлый. Олуг әдибебез Гаяз Исхакыйга (исеме чыгу белән зал көчле алкышларга күмелә), укытучыларны сугышка алынудан коткарган Дәүләт Думасы депутаты Гайсә Еникеевка (ул Дәүләт Думасы депутаты буларак, укытучыларны сугышка җибәрмәүне таләп итеп чыга һәм Дума аның хаклы таләбе белән килешергә мәҗбүр була), илдән сөрелгән мөгаллим Габдулла Бубига һәм мәгариф министры Керенскийга тәбрик телеграммалары җибәрелә. Илдә барган вакыйгалар, сугышка карата мөнәсәбәт хакында докладлар тыңлана. Казаннан Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин, Оренбургтан Нургали Надиев, Уфаның «Госмания» мәдрәсәсеннән Габдулла Шнаси, Шәһит Әхмәдиевләр чыгыш ясый. Бөтенроссия татар укытучыларының Мәркәз бюросы оеша һәм аның рәисе итеп Газиз Гобәйдуллин сайлана. Г.Гобәйдуллин хезмәттәшләренә үзенә күрсәтелгән хөрмәт өчен рәхмәт әйтә һәм болай ди: «Без әле сугыштан кайтмадык. Сез бу җыелышыбызны беренче мобилизация дип белегез. Мин идея һәм иманым белән сезне тугры вә хак юлдан алып барачакмын. Без хокукларыбызны алу өчен каһарманнарча көрәшербез».

Съезд эшендә укытучыларның дөньяга, илдә барган вакыйгаларга мөнәсәбәтендә – бер-берсеннән шактый ерак торган ике юнәлеш билгеләнә. Беренче юнәлеш әле генә идарә итә башлаган Вакытлы хөкүмәткә теләктәшлек белдерү, яклау ягында торса, икенче юнәлеш (алар арасында Исхак Рәхмәтуллин, Кәрим Тинчурин, Шәһит Әхмәдиевләр бар) Вакытлы хөкүмәт дәвам иткән сугышка протест белдерү, туктатуны таләп итү, тулы азатлык өчен көрәштә эшчеләр һәм солдатлар белән бергә хәрәкәт итү кирәклеген яклап чыга. Шунысы мөһим, съезд укытучыларның эшчеләр белән бергә забастовкалар кебек массакүләм чараларга катнашу тәкъдимен бердәм рәвештә кире кага.

Съездның соңгы кичендә татар халкының күркәм гадәте буенча Әхмәтҗан Сәйдәшевләр йортында (Яңа бистәдә) Аш мәҗлесе үткәрелә. Аштан соң укучы балалар хор белән «Уян, татар», «Ком бураны» җырларын, ә Абруй Сәйфи халкыбызның «Мәдинәкәй», «Уел» кебек көйләрен җырлап, хөрриятләр болай да тулган күңелләрне тагын да нечкәртеп җибәрә.

Съезд 27 апрельдә ябыла. Анда кабул ителгән әһәмиятле карарларны санаганда, мөгаллимнәрнең үзәк һәм җирле идарә органнарын сайлауны, мәгариф эшен кичекмәстән җанландыруга өндәүне, сугышка каршы чыгу һәм туктатуны таләп итүне, укытучыларның сәяси платформасын билгеләүне күрсәтергә кирәк. 1 Майда Мәскәүдә узачак гомуми мөселманнар съездына делегатлар сайлау да шушы съезд барышында үтә.

«Сүз әйттеңме, эшлә», – ди халык мәкале. Съездан соң ук карарларны үтәү йөзеннән, мөгаллим-мөгаллимәләр хәзерләү өчен җәйге курслар ачыла. Шулардай «Касыймия» мәдрәсәсе һәм Салихҗан хәзрәт Баруди кызы Әминә Галиева-Шәрәф тарафыннан Казанда, атаклы мөгаллимә Маһруй Мозаффария тарафыннан Тәтештә, Чистайда – Мәрьям Мөштәри, Мәрвәрит Туктарова, Мозаффар Таҗетдиновлар һәм Оренбург өлкәсе Кабан авылында Фатих Кәрими, Багбостан Мәәминовалар ачкан курсларның оешканлык белән эшләвен искә алып китәм. Шул чорларда чыккан көндәлек матбугат бу курсларга үз балалары белән хәтта ата-аналар да килгәнен сокланып яза.

Үкенечләр һаман әрнетә. Татар тамырына балта чапкан октябрь үтү белән, өметләр дә юкка чыга бара, мөгаллимнәрнең тормышлары да чәлпәрәмә килә. Әзерләнүләргә чыдый алмыйча (бу юлы үз милләттәше Галимҗан Ибраһимов «тырышлыгы» белән), Мәркәз бюро рәисе Газиз Гобәйдуллин 1925 елда ук Татарстаннан китәргә мәҗбүр була. Ачлыктан котылырга теләп, чит-ят җирләргә юл алган мөгаллимнәребезнең саны исә бүгенгәчә билгесез. Репрессия елларында корбан булган талантлы педагогларның да исәбе алынмаган...

Халкыбыз кебек үк таланган, йолкынган икән мәгарифебез. Үз туган телебездә югары уку йорты, ягъни дарелмөгаллимат ачу хыялы да тормышка ашмады. Үз югары уку йортын, үз мәгариф челтәрен, ягъни системасын булдыру шулай итеп татарның хыялында гына калыр микәнни? Хәзер авыллар беткән, татар мәктәпләре көн саен ябыла торган заманда бу хакта сүз сөйләү дә ят яңгырый кебек. Анда укытырлык галимнәребез дә, кереп белем алырга теләүчеләребез дә җитәрлек, югыйсә!

Тәминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

ХУШЛАШЫРГА АШЫКМА
яки Халыкчанлыкка кайту

К.Тинчурин театры башка труппалардан элек-электән халыкчанлыгы белән аерылып тора иде. Әмма соңгы елларда аның кыйбласы бераз какшый төште кебек, замана шаукымына бирелеп, ул да тәҗрибәләр мәйданына әйләнде һәм тинчуринлылар спектакльләрен яратып йөргән элеккеге тамашачы бераз аптырап калды. Яңа гына театрны элеккеге юлына кайтарган матур спектакль иҗат ителде. Карлыгач табигатьнең җанлануын билгеләгән кебек, Ләйсән Әминова әсәре буенча Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Зөфәр Харисов куйган «Яратам! Бетте-китте!» тамашасы да традициянең яңаруы булып театр сөючеләргә барып иреште һәм беренче көннәрдән үк уңышка тиенде. «Яратам!»ны яратмыйча мөмкин түгел.

Беренчедән, шул кадәр матур тел белән язылган әсәрне ничек яратмыйсың?! Аны Актаныштан татар теле укытучысы Ләйсән Әминова язган, театрының актрисасы Гүзәл Гарәпшина әсәрне күренекле артистыбыз Зөфәр Харисовка ирештергән. Ләйсән ханымның моңа кадәр дә драматургия өлкәсендә көчен сынап караганы була, мәсәлән, Әлмәт театрында аның әсәре буенча куелган бер спектакль зур уңыш белән бара.

Штатта М.Җәлил исемендәге республика премиясе иясе музыкант, дирижер Ильяс Камал була торып, егетнең талантын файдаланмасалар, гаҗәп һәм кичермәслек хәл булыр иде. Яңа спектакль музыкаль комедия жанрында куелган. Биредә ретро җырлар күп яңгырый: «Күзләремә бер каравың җитә...», «Җәмилә», «Рәзинәкәй», «Йөрәгеңнән үбәр идем...», «Алып кил миңа язның...» һ.б. Әмма матур җырларның берәр куплетын гына башкарып, артистлар тамашачыны котыртып кына калдыра сыман. Бүген бик сирәк яңгыраган бу җырларны рәхәтләнеп бер тыңлатасы урынга, анда өзек, монда өзек башкарулары аркасында, тулаем спектакльнең музыкаль сурәте кисәкләрдән җыелган корама юрганга охшап кала. Дөрес, спектакльнең вакыты бөтен җырларны да тулаем тыңлатырга мөмкинлек бирми. Шулай икән, бөтенесен бер тамашага тутыру кирәк тә булмагандыр, бәлки. Иң башта артистларның алдан чамаларга мөмкин. Ни өчендер бик сагындырган шушы гадилек. Заманалар авыр булып, күңел бушану, юану эзләгәнгәдер, мөгаен.

Көлке, уенга, җыр-биюгә корылса да, спектакльдә җитди проблемалар да күтәрелә. Вакыйгалар, мәсәлән, ике генә өе калган Җиләкле алан авылында бара. Авыллар белән бергә борынгы матур гадәт йолаларыбыз да юкка чыга. Бүген аларны елга бер тапкыр Сабантуйларда, чит илдән килгән кунакларга гына күрсәтәләр. Хәзер яздырылган язмага кушылып җырлаулары да кәефне җибәрде. Бии-бии җырлау һәр артистка да җиңел түгел, әлбәттә. Шулай да җырны алдан яздырып кую спектакльнең җанын үтерә ләбаса. Хәер, тора-бара артистларыбыз бу кимчелекне матур җырлаулары белән бөтенләй онытырды. Шундый матур тавышлы яшьләр бар икән театрыбызда!

Соңгы елларда сәхнәләребездә шартлы сурәтләү алымнары өстенлек алып, тамашачы дөнья мәшәкатеннән ял итәсе урынга, математика фәненнән мәсьәлә чишкән кебек, киеренке халәттә утырырга мәҗбүр иде. Яңа тамашада исә барысы да бик гади. Авыл, табигать турындагы спектакльдә сәхнә зурлыгындагы зур арткы пәрдәдә җәйге пейзаж күрәбез. Мәхәббәт турында сүз барасын өстәге пар күгәрчен сурәте искәртә. Вакыйгаларның гадәт-йола тирәсендә әйләнәчәген сәхнәдә ике яклап сурәтләнгән кызыл очлы сөлгеләрдән дә милли йолаларның үтәлешен читлектәге хайваннарны караган сыман карарга калды. Ике кешелек кенә булса да, Җиләкле алан элекке көчен, матурлыгын саклаган авыл булып чыга. Дөрес, биредә дә Сабан туенда чит илдән килгән милләттәшләребезгә килен төшерү йоласын күрсәтәләр. Әмма кунаклар алдында уйнаудан башланган тамашада ахыр чиктә бер-берсен чын-чынлап сөйгән геройлар, чын хисләр катнаша. Шулай итеп милли йола читлекне җимереп, тормыш-чынбарлыкка ургып чыга. Әйтерсең, беркайчан онытылып тормаган...

Яшьләрне кавыштыручы Фаил бабай Җиләкле алан авылында мәктәптә тарих укыткан, укучылар өчен музей булдырган. Хатыны Мәйсәрә клуб мөдире булып эшләгән, гомер буе ирен хөрмәтләп, авыр чакларда сабыр итеп яшәгән. Бу үзәк геройларның матур сурәтләнеше аша тамашачыга матур гаилә традицияләре ирештерелә. Спектакльдә төп вазыйфа Фаил картка йөкләнгән. Шәһәрдә никахсыз-туйсыз кавышкан, этле-мәчеле яшәгән яшь парны хәйлә белән дуслаштыручы ул. Фаил картта яраткан Әлмәндәребез халкы ярылып ята, Туфан Миңнуллинның герое кебек ул да хәйләкәрлеге, тормышны шашып яратуы, бервакытта да төшенкелеккә бирелмәве белән һәркемгә үрнәк булырлык.

Җиңел генә тоелса да, спектакльдә шәһәр-авыл каршылыгын яхшы тоясың. Шәһәрдә эт урынына ырылдап талашкан, Алласын-мулласын белмәгән яшьләр килен төшерү йоласын башкарырдай булып үзгәрә. Баксаң, шәһәрдән кайткан кәттә егеткәйнең исеме дә үзебезчә, татарча икән бит! Рома түгел Рамазан лабаса ул! «Йөрәгеңнән үбәр идем...» дип, рэп җырлый башлаган иде, ахырын моңлы итеп җырлап бетерде. Рамазан элегрәк сөйгәненең йөрәген купшы, кыйммәтле чәчкәләр белән яуларга теләсә, Җиләкле аланда гап-гади кыр чәчәкләренең матурлыгын күрергә өйрәнә. Саф хисләрнең байлык, купшылык белән түгел, эчкерсезлек, гадилек белән үлчәнгәнен аңлый башлый.

Спектакльдә язмыш Фаил бабайның планыннан да кызыграк булып чыга. Биредәге һәрбер геройның тормышын бөтереп алып, яшьлектәге хаталарга һәм иң мөһиме мәхәббәткә алып кереп китә. Әмма болары сер булып калсын...

Ни аяныч, бүген татарның үткәне музейларда экспонат булып саклана һәм авылларда сандыкка бикләнгән. Туган телебез, гореф-гадәтләр, татар тарихы көндәлек тормышыбыздан китә бара. Тик мәхәббәтне сандыкка салырга ярамый. Хәзер яратырга, сәбәбен эзләмичә, артык катлауландырмыйча, чын күңелдән яратырга кирәк, дияргә теләгән сыман автор һәм режиссер.

Милли байлыкларыбыз җиде кат йозак артында, сандыкларда ятса да, «Яратам! Бетте-китте!» кебек халык җанын саклаган спектакльләр белән алар кабат тормышыбызга кайткан кебек була. Спектакль куелгач, «Син бит минем бергенәм» әсәрен үзе язган, үзе сәхнәгә куйган һәм тагын шундый гадилеге белән матур онытылмас тамашалар бүләк иткән халыкчан рухлы артистыбыз Исламия Мәхмүтованың рухы әйләнеп кайткандай булды. Исламия ханымның спектакльләре кебек «Яратам! Бетте-китте!»нең дә озын гомерле булачагына һичбер шик юк. Шуны алдан чамалагандай, режиссер ике состав артистлар белән иҗат иткән. Берсендә Р.Шәмсетдинов, Л.Мәхмүтова, Л.Галләмова, А.Мөсәлләмова, Л.Камалиева, А.Фәтрахманов, Э.Никитин, С.Хәбибуллин, Р.Төхфәтуллина, И.Хәсәнов, Л.Ибәтуллина булса, икенчесендә Зөфәр Харисов үзе, Г.Гарәпшина, С.Минханова, Г.Галиуллина, В.Низамова, И.Хафизов, Б.Зиннәтуллин, З.Хәкимҗанова, Р.Минханов, А.Сираева. Май чүлмәге тышыннан билгеле булган кебек, Тинчурин театрының талантлы бу артистлары үзләре үк тамашаны озын гомерле итәчәге бәхәссез. Яшерен-батырын түгел, бериш театрларыбызда урта һәм өлкән буын артистлар сәхнә тутырып уйныйсы урынга, рольсез тилмерә. Актер, режиссер З.Харисов бу мәсьәләне ике состав билгеләп бик уңай хәл иткән. Кешелеклелекне җуймаганда, әнә шулай да була икән! Бүтән театрлар өчен дә гыйбрәт булсын. Гомумән, соңгы елларда театрларыбызда килмешәк сәнгать ияләренең күплеге күңелгә тия башлаган иде, «Яратам! Бетте-китте!» тамашасында исә бер читтән килгән иҗатчы катнашмаган. Рәссам Әлфия Вәлиева да, хореограф Ләйсән Вәлиәхмәтова да, хормейстер Алия Хәмзина да, ут көйләүче рәссам Илдар Шакиров та театрның үзенеке.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ХӘЗРӘТИ ГОЗӘЕР галәйһис-сәлам

Һарун галәйһис-сәлам нәселеннән чыккан пәйгамбәр санала. Тәүратны ятлаган сирәк затларның берсе. Яһүдиләрдә «Әзра» исеме белән билгеле.

Хәзрәти Гозәернең пәйгамбәрме түгелме икәнлеге турында Коръәни-Кәримдә анык мәгълүмат юк. Шулай ук Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Гозәернең пәйгамбәр булганмы-юкмы икәнен белә алмыйм!..» – дигән.

Коръәни-Кәримдә Аллаһ Тәгалә тарафыннан җаны алынып, йөз елдан соң кабат терелтелгәнлеге генә әйтелә.

Хәзрәти Гозәер яшәгән чорда, азгынлыклары, бозыклыклары арткан Исраил угылларының башына бәла итеп, Аллаһ Тәгалә Бухтүннасрны хөкемдар итә. Бухтүннаср Димәшкъ һәм Иордан төбәкләрен яулап ала. «Әл-Әкъса» мәчетен җимерә, бакча-кырларны юк итә. Яклаучысыз калган кешеләрне ерткычларча үтереп, яшь һәм эшкә ярарлык дип күренгән кешеләрне әсир төшереп, үз янына алып китә. Хәзрәти Гозәер дә шулар арасында була.

Риваятькә күрә, Гозәер галәйһис-сәлам илле яшендә чакта әсирлектән качып котыла. Бер ишәк белән Иерусалимгә таба юл тота. Иерусалимгә якынайгач, шәһәрнең җимерек биналарын, юк ителгән бакча-кырларын күреп кайгыга чума. Карыны шактый ачыкканга күрә, ишәген бер агачка бәйләп, шунда берникадәр инҗир җыеп ашый. Йөзем сыгып, шуның суын эчә. Аннары бер агач астына килеп утыра. Җимерелгән, тар-мар ителгән калага, череп яткан гәүдәләргә, өеп куелган сөякләргә гыйбрәт белән карап тора. Хак Тәгаләнең кодрәте турында фикерләп, һәрнәрсәнең яңадан ничек терелтелүчәгенен уйлый-уйлый йокыга тала.

Аллаһ Тәгалә әйтә: «Яки нигезенә кадәр җимерелеп беткән авылдан үткән кеше турында (уйла). Ул: «Үлгәненнән соң Аллаһ моны ничек терелтер икән?» – дигән иде. Аллаһ йөз елга аның җанын алды, шуннан терелткән иде. Ул: «Күпме тордың?» – дигәч, ул исә: «Бер көн яки көннең бер өлеше тордым», – дигән иде. Ул: «Түгел, син йөз ел тордың. Ашамлык һәм эчемлекләреңә кара, үзгәрмәгәннәр (бозылмаганнар). Инде ишәгеңә кара. Сине кешеләр өчен бер билге (гыйбрәт) итәргә дип (йөз ел үле килеш тоттык, аннары кабат терелттек). Сөякләрне ничек җыйганыбызны, шуннан соң аларга ит кундырганыбызны кара», – дигән иде. (Итләре черегән, сөякләре кисәк-кисәк аерылган ишәк Аллаһның әмере белән кабат терелә.) Аңа күрсәтелгәч (хәлне аңлагач), Ул (Гозәер): «Һичшиксез, Аллаһның һәрнәрсәгә кодрәтле булганын беләм», – диде» («Әл-Бәкара», 259).

Гозәер галәйһис-сәлам йоклаган чакта таң аткан вакыт, ә уянганда әле кояш батмаган була. Ләкин шул арада йөз ел узып китә. Бу вакытта инде Бухтүннаср үлгән, бөтен әсирләр ирек алып, Иерусалимгә кайталар. «Әл-Әкъса» мәчете төзекләндерелгән һәм бөтен кала кабат торгызылган.

Үзе шаһит булып кичергән шушы гаҗәеп күренешләрдән соң, Гозәер галәйһис-сәлам ишәгенә атланып, Иерусалим шәһәренә килеп кергәч, бөтен нәрсәнең үзгәргәнен күрә. Кешеләр дә таныш түгел, биналары да ят. Фаразлап булса да, Гозәер галәйһис-сәлам үз мәхәлләсе булырга тиеш урынны эзли. Бер өй каршына туктап, аның ишек төбендә очраткан сукыр һәм гарип хатыннан: «Гозәернең өе кайсы?» – дип сорый.

Теге хатын, хәсрәтләнеп: «Гозәернең өе шушы, тик үзе йөз ел элек югалды. Мин исә аның җариясе булам!» – ди.

Хәзрәти Гозәер: «Мин Гозәер инде!» – дип, үзен таныта да башыннан кичкәннәрне сөйли. Җариясе бик сөенеп, әүвәлге хәленә кайту өчен, дога кылуын сорый. Гозәер галәйһис-сәлам, аңа Җәнабел-Хак биргән нигъмәтләргә шөкер әйтеп, дога кыла. Җария хатынның элекке саулыгы һәм килеш-кыяфәте кайта.

Йокыга талган чакта, Хәзрәти Гозәернең 18 яшьлек улы кала. Хәзер инде ул 118 яшьлек ак сакаллы карт була. Бу картның атасы – Гозәер галәйһис-сәлам исә 50 яшьлек зат кыяфәтендә. Улы атасын таный алмый: «Атамның аркасында ай рәвешендә кара миңе бар иде!» – ди ул. Гозәер галәйһис-сәламнең аркасын ачып карагач, ай рәвешендәге кара миңне күрәләр. Инде һичкемдә бу кешенең Хәзрәти Гозәер икәнлегенә шик калмый.

Ибне Габбастан тапшырылган риваятькә күрә, Аллаһ Тәгалә Исраил угылларның Тәүратны читкә тибәреп, үз теләк-омтылышларына ияргәнен күргәч, Тәүрат салынган сандыкны алардан тартып ала, изге китапның эчтәлеген дә оныттыра. Исраил угыллары моңа бик кайгыра. Аеруча Гозәер галәйһис-сәлам Аллаһка күп гыйбадәт кыла, Аңа ялварып дога укый. Аллаһтан иңгән бер нур аның йөрәгенә үтеп керә, шуннан соң Тәүрат Гозәер галәйһис-сәламнең исенә төшә һәм ул китапны яңадан Исраил угылларына өйрәтә. Соңрак эчендә Тәүрат сакланган сандык та табыла. Исраил угыллары Гозәер галәйһис-сәлам өйрәткән Тәүратның асыл нөсхәгә туры килгәнен күрә һәм аларның Гозәер галәйһис-сәламгә карата мәхәббәте-хөрмәте тагын да нығый.

Мондый искиткеч илаһи күренешләр каршында Бәни Исраил кавеме, соңга таба ялган гакыйдәгә ияреп, Гозәер галәйһис-сәламне илаһилаштыра башлыйлар, хәтта аны «Аллаһның улы» дип атауга кадәр барып җитәләр.

Аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр ителә: «Яһүдиләр: «Гозәер – Аллаһның улы», – диде. Насаралар исә: «Мәсих (Гайсә) – Аллаһның улы», – диде. Аларның бу авызлары белән сөйләгәннәре элекке кяфер булган кешеләрнең сүзенә охшый. Аллаһ аларны һәлак итсен! Алар никадәр (хактан батыйльгә) тайпылганнар» («әт-Тәүбә», 30).

Бүгенге яһүдиләр Хәзрәти Гозәерне «Аллаһның улы» дип атауны кабул итмәсәләр дә, ул чордагы бер төркем яһүди Гозәер галәйһис-сәламгә карата бик зур кадер-хөрмәтте була һәм аларның кайберләре аны әнә шул кушамат белән искә ала.

Зәбур һәм аның эчтәлеге

«Зәбур» атамасы белән бергә Коръәни-Кәримдә бу сүзнең күплек саны булган «зүбур» варианты да очрый. «Зәбур» – китап, «зүбур» китаплар дигәнне белдерә. «Зәбур» сүзе Коръәни-Кәримдә өч урында очрый һәм алар барысы да Хәзрәти Давыт белән бәйле. Аяти кәримәдә: «…Давытка исә Зәбурны бирдек», – дип әйтелә («ән-Ниса», 163).

«Зүбур» сүзе исә Хәзрәти Давытка мөнәсәбәтле рәвештә генә түгел, гомумән бөтен пәйгамбәрләргә иңдерелгән китаплар белән бәйле буларак телгә алына.

Коръәни-Кәримдә болай диелә: «Һичшиксез, ул әүвәлгеләрнең китапларында иде!» («әш-Шугара», 196).

Бу аяти кәримә бер үк вакытта Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең туачагы турында әүвәлге илаһи китапларда да сөенечле хәбәр ирештерелгәнлегенә ишарә ителә.

Хәзрәти Давытка бирелгән Зәбур турында Коръәни-Кәримдә мондый мәгълүмат бар: «Зикердән (Тәүраттан) соң Зәбурда да яздык инде, ул җиргә Минем изге колларым мирасчы булачак» («әл-Әнбия», 105).

Коръәни-Кәримдә Зәбур белән бәйле шуннан артык мәгълүмат очрамый. Ислами чыганаклар Хәзрәти Давытка Зәбур иңдерелүне аның өстен сыйфатларының берсе буларак искә ала.

Ислам галимнәре Зәбурда ниндидер хөкемгә кагылышлы мәсьәләләрнең урын алмавын, аның бары тик Җәнабел-Хакка ялварудан, Аны мактау-данлау мөнәҗәтләреннән гыйбарәт икәнлеген белдерә.

Хәзрәти Муса галәйһис-сәламнән соң килгән Хәзрәти Давыт галәйһис-сәлам төрле хөкемнәр мәсьәләсендә Тәүрат белән гамәл кыла. Зәбур исә кешеләрдә Аллаһка карата сөю-мәхәббәтне, Җәнабел-Хакка ялвару-үтенүне камилрәк рәвештә башкаруны күздә тоткан илаһи нәзымнар тупланмасыннан гыйбарәт тулысынча шигъри китап була. Әлеге Изге китапта «Мәзмурлар» дип аталган бер бүлем бар, бу сүз көйләп укыла торган шигъри кисәкләр, әсәрләр дигәнне белдерә. Аларның саны 150 гә җитә. Боларның 70ләбе Хәзрәти Давытка нисбәтләп карала, калганнары исә башкаларныкы дип санала. Шул сәбәпле бүгенге Зәбур – Коръәни-Кәримдә Хәзрәти Давытка бирелгәнлеге белдерелгән Зәбур түгел. Чөнки Изге китапның барлык бүлекләре дә иң башта иңдерелгән шәкелдә сакланып, теркәп куелмаган, хәзерге заманга кадәр аңа күп тапкыр кеше кулы кергән. Әлеге тарихи чынбарлык Зәбурның асыл, оригинал формада сакланып калу ихтималын юкка чыгара.

Бүгенге Зәбур Хәзрәти Давытның вафатыннан биш йөз ел соңрак языла башлый. Шулай ук Зәбурга Давыт галәйһис-сәламнең тормышы, дәгъват эшчәнлеге турында мәгълүматлар белән беррәттән чыганагы ачыкланмаган, 100 гә якын билгесез шагыйрьнең шигырьләре дә өстәлгәнлеге риваять кылына.

Хәзерге замандагы Зәбурның кем тарафыннан язылганлыгы, вәхи юлы беләнме әллә илһам нәтиҗәсендәме кәгазьгә төшерелгәнлеге тулысынча ачыкланмаган. Шәрык белгече Һорн: ««Зәбур»ның Давыт пәйгамбәр тарафыннан язылганлыгын алга сөрүчеләрнең дәлилләре бик зәгыйфь, мәгънәсез; бу фикернең ялгышлыгы ап-ачык», – дип әйтә.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

22 апрель (шимбә). ***Шәүвәл аеның 2нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 5.52 сәгатьтә калка, 23.24 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.39 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп киту ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Йөрәк еш типсә

Йөрәк артык еш тибә башласа:1) тынычланырга, сулыш алуны җайлаштыру өчен изүләрне чишәргә; 2) валерьян, сукыр кычыткан яки дүләнә тәнәтмәсе, яисә 20-40 тамчы корвалол яки валокордин эчәргә; 3) утырып тормаска, ятарга; 4) бер 30-40 секунд тын алмый торырга; 5) күзне йомып, бармак белән күз алмаларына баскаларга; 6) салкынча су эчәргә; 7) салкын су белән юынырга; 8) учка 10-12 тамчы ак чыршы мае тамызып, йөрәк турысын 1-2 минут ышкырга кирәк.

23 апрель (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 3нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 6.11 сәгатьтә калка, 0.45 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.43 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Үзебездән тора

Дөрес тукланмау гомерне 6-10 елга кыскарта. Организмда 4-5 килограмм артык май туплану матдәләр алмашын боза һәм төрле чирләр китереп чыгара. Атеросклероз, диабет, подагра, бөер һәм бавыр авырулары симез кешеләрдә ябыкларга караганда 2 тапкыр ешрак очрый. Иң әйбәте – көненә 4-5 тапкыр әз-әзләп ашау. Иртәнге якта ашалган ризык тулысынча эшкәртелеп бетә.

24 апрель (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 4нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 6.40 сәгатьтә калка, 1.51 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.47 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь

25 апрель (сишәмбе). ***Шәүвәл аеның 5нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 7.22 сәгатьтә калка, 2.41 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.52 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче бирә. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Елау файдалымы?

А витамины җитешмәгәндә, күз зәңгәр һәм сары төсне начар аера башлый. Күз елына ярты литр яшь бүлеп чыгара. Китереп чыгарган сәбәпләренә бәйле рәвештә, күз яшенең

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

составы төрле була. Стресс мизгелләрендә барлыкка килгән куркыныч токсиннары организмнан чыгарып зур файда китергәнгә, күз яшен тыярга кирәкми. Кәбестә, шпинат, брокколи, яшел борчак ашау күз авырулары килеп чыгу ихтималын күпкә киметә. Тәмәке тартучыларда глаукома тартмаучылардан 2-3 тапкырга ешрак күзәтелә, әлеге чир исә сукырайтырга да мөмкин.

26 апрель (чәршәмбе). ***Шәүвәл аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 8.21 сәгатьтә калка. 1нче фаза. Көн озынлыгы 14.56 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Сарымсак мае

1 баш сарымсакны чистартып, кырып, согын сыгып алалар, шуңа 1 стакан чистартылмаган көнбагыш мае кушып, 1 тәүлеккә суыткычның аскы киштәсенә куялар. 1 чәй кашыгы сарымсак маена 1 чәй кашыгы лимон согы кушып, көненә 3 тапкыр ашарга 30 минут кала эчәләр. Дәва курсы 1-3 ай. Сарымсак мае баш миендәге тамырларны кысылудан саклый, тын кысуны бетерә.

27 апрель (пәнҗешәмбе). ***Шәүвәл аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 9.31 сәгатьтә калка,3.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.00 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Йокысызлыктан дәва

Йокларга ятар алдыннан 1 стакан кайнар сөт эчү, хөрмә ашау, яисә 1,5 чәй кашыгы балга ярты чәй кашыгы лимон согы кушып кабу файдалы. Кипкән мәтрүшкә, бөтнек, мелисса, валерьян үләннәрен кечкенә мендәргә тутырып баш очына куеп яту да тынычлап йокыга китәргә булыша. Урыннан торып, бераз туңганчы йөрергә, аннары җылы юрган астына чумарга була. Сарык яки фил санау да булыша, тик моның өчен аларның һәркайсын аерым-аерым күз алдына китерергә кирәк. Кара төстәге урынҗирдә йокыга китү җиңелрәк.

28 апрель (җомга). ***Шәүвәл аеның 8нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 10.48 сәгатьтә калка, 3.33 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.05 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

«Ялкау» дучмак

Ярты килограмм клиндер (баранка), 1стакан сөт, 250 г эремчек, 1 йомырка, 1әр аш кашыгы шикәр һәм он кирәк. Клиндерләрне сөттә җебетәләр. Майланган, он сибелгән табага тезеп, урталарына эремчек салалар. Йомырканы калган сөттә туглап, шикәр кушалар һәм шаңгәләрне шуның белән майлыйлар. Газ мичендә 5-7 минут – өсләре кызарганчы пешереп алалар.

●Директор Марат Фәттиев.

Мәктәптә киләчәк кешесе тәрбияләнә

Күптән түгел Казанда Alta School дигән халыкара мәктәптә булырга туры килде. Уку йорты белән аның директоры Марат Миңтаһир улы Фәттиев таныштырды. Иң әүвәл мәктәптәге үзенчәлекле җиһаз җәлеп итте. Сыйныф бүлмәләренең һәркайсында бер бала гына утырырдай үзенчәлекле формадагы парталар, зур форматта интернетка тоташтырылган интерактив телевизор, һәр балага китаплар кую өчен аерым шкаф... Телевизор исә такта функциясен дә үти. Аңа бармак белән язарга, мәсьәләләр эшләргә була. Балалар буш вакытларында хәрәкәтләнсеннәр өчен, махсус эшләнгән ачык алан бар. Агач тактачыклардан эшләгән шарларның өстенә үрмәләргә, эченә кереп утырырга мөмкин.

Бу – Казанда әлегә Values-based Education (кыйммәтләргә нигезләнгән белем бирү) халыкара сертификатын алган бердәнбер шәхси башлангыч уку йорты. ALTA SCHOOL халыкара статуска ия булса да, анда Көнбатыш кыйммәтләре бирелми. «Без үз халкыбызның гореф-гадәтләренә, әхлагына таянып эшлибез, милли, мәдәниятебезне, йола, гореф-гадәтләребезне саклап, баланың шәхесен үстерү, аларда гомумкешелек сыйфатларын, үз-үзен камилләштерү күнекмәләрен тәрбияләүне максат итәбез. Мәхәббәткә, үзара ихтирамга, түземлек һәм сабырлыкка нигезләнгән белем заман балаларына уңышларга юл ача, аларны бәхетле итә», – ди Марат Фәттиев. Моны Values-based Education экспертлары да югары бәяләгән.

Мәктәпкә баланы кабул иткәндә, тәҗрибәле нейропсихолог тестлар һәм күнегүләр ярдәмендә аның укуга һәм социальләшүгә әзерлек дәрәҗәсен, мөмкинлекләрен, көчле һәм йомшаграк якларын тикшерә, ата-аналар, укытучылар өчен тәкъдимнәр әзерли. Моннан тыш укучылар атнага ике тапкыр нейропсихолог белән уздырыла торган күнегүләргә йөри.

Бүгенге көндә балалар тормышыбызга гаджетлар күпләп килеп керүе һәм әти-әниләрнең артык кайгыртучанлыгы сәбәпле хәрәкәтсез кала. Аларның эре һәм вак моторикасы үсеш кичерми. Ә нейрон бәйләнешләрнең физик хәрәкәт вакытында гына формалашуы мәгълүм. Мәктәптә шуңа да баланың хәрәкәтләнүен һәм аңа белем бирүне бергә бәйләп алып баралар. Мәктәп коридорындагы ачык аланга шарлар шушы ниятне күздә тотып куелган. Балалар аңа ябышып өскә менә, эченә кереп уйный.

Мәктәптә уку елы триместрларга бүленә: биш атна укыйлар, бер атна ял итәләр. Һәр триместр аерым бер кыйммәткә багышлана. Уку йортында җаваплылык хисен һәр җирдә – иртәнге һәм кичке остазлык сәгатьләрендә, ассамблеяларда, «Ата-аналар академиясе» клубы кысаларында әти-әниләр белән үтә торган тренингларда, мәктәп күләмендә уздырыла торган чараларда, хәтта сыйныф бүлмәләрен бизәүдә дә тоемларга мөмкин. Балалар җаваплылыкның ниндидер абстракт төшенчә булмавын, аның белән тормышта дуслары янәшәсендә, гаиләләрендәге мөнәсәбәтләрдә, кешеләр, туганнары белән аралашуларда очрашып торуларын аңлыйлар. Бу уңай кыйммәтләр укучыларның холкын формалаштыра. «Әгәр баланы мәктәптәме, башка урындамы, кагыйдәләрне үтәүне мәҗбүр итсәң, ул тыелмаган һәр нәрсәне эшләргә ярый, дип уйлый башлый. Ә инде укучы күңеленә дин, психология, педагогика нигезендә яткан гомум этика принципларын, өлкәннәргә хөрмәт белән карау, тәртипле булу, көчсезләрне кыерсытмау һ.б. әхлак нигезләрен салсаң, ул теләсә нинди хәлдә дә намусы кушканча эшләячәк», – дип аңлата бу уңайдан директор.

Һәр сыйныфта, күп дигәндә, 16 бала укый. Алар көнгә 4 тапкыр хәләл ризык белән туклана. Балалар белән иртәдән кичкә кадәр укытучы һәм тьютор шөгыльләнә. Мәктәптә белем көннең беренче яртысында рус телендә (атнага ике тапкыр татар теле дәресләре керә) бирелсә, икенче өлешендә тел мохите башлана. Тьютор балалар белән инглиз яисә татар телендә генә сөйләшергә тиеш. Көннең икенче яртысында шулай ук эшчәнлек проекты нигезендә балалар үзләренең төрле юнәлештәге фикерләрен эшкә ашыралар, ул рәсемгә төшерергә, хәтта робот та ясарга мөмкин. Моннан тыш ял көне төркемнәре дә бар. Укучылар өчен шулай ук логопед, нейропсихолог белән шөгыльләнү, инглиз теле, джиу-джитсу, арт-терапея дәресләрендә катнашу мөмкинлеге тудырылган. Моннан тыш баланың саф һавада оештырылган уеннарда катнашуы да күз уңында тотыла.

●Укучыларның иҗади эшләренең берсе.

●Мәктәптә укучыларга буш вакытларында уйнар өчен менә шундый җиһазлар куелган.

Мәктәпкә баланы китергәндә «Без рус телен генә сайларга телибез», – дип килүчеләр бар икән. Биредә аларга «Алай укырга теләгәннәр башка мәктәпкә бара», – дип җавап бирәләр.

Мәктәптә бирелә торган тәрбия һәм белем нигезендә исә, һәр укучыга уникаль һәм талантлы шәхес итеп карап, аңа индивидуаль якын килеп төзелгән план нигезендә, ата-ана һәм мәктәп белән бәйләнештә торып эшләү ята. Alta School да укучы балалар шәһәр һәм республикакүләм олимпиадаларда актив катнаша, җиңүләр яулый. Моннан тыш Alta School балалары робототехника, программалаштыру, электротехника, кул эшләре һ.б белән бик иртә шөгыльләнә башлый. Алар өчен мәктәптә барлык шартлар тудырылган: иҗади остаханә, конструклаштыру һәм дизайн зонасы, биоинженерия лабораториясе, гимнастика залы, музыка һәм театраль студия кабинетлары һ.б. – балалар карамагында. Җәй көне исә мәктәп базасында телләр өйрәнүгә, спорт белән шөгыльләнүгә игътибар бирелә торган IT лагерьлар эшли.

Диварларга куелган рәсемнәр күргәзмәсе дә хәйран итте. Бу – Хәтта аның башлангыч сыйныф укучыларының иҗади эшләре булуына ышанасы да килмәде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

ЯКТЫ ИСТӘЛЕК

Легендар җырчыбыз Рәшит Ваһапов турында хатирәләремне яңартып, газета укучылар белән уртаклашырга булдым.

Ялгышмасам, бөек якташыбыз үзенең концерт бригадасы белән безнең авылга 1956-1957 елларда килде. Ул чакта мин педучилище тәмамлап, берничә ел инде авыл китапханәсендә эшли идем.

Яз көне. Мәркәзебез Казаннан Татарстан филармониясе артистлары Рәшит Ваһапов, Җәваһирә Сәлахова, гармунчы, шулай ук якташыбыз Гани Вәлиев килеп төште. Тагын кемнәр булса бар идеме, юкмы – анысын төгәл хәтерләмим, чөнки бу вакыйгадан соң җиде дистәгә якын ел үтте, мин дә күптәннән тугызынчы дистәне вакладым инде.

Артистлар килүен килде, әмма клубта концерт үткәрү мөмкинлеге юк, чөнки идәнендә каяндыр китереп бер машина кукуруз чәкәннәре салганнар (әлләүинде орлык киптерергә башка урын булмаган?!). Нишләргә? Артистларны кире кайтарып җибәреп булмый бит, концертлар болай да бик сирәк килә иде. Уйлаштык та, концертны бер буш колхоз сараенда уздырырга булдык. Ир-атлар шунда агач кискәләре өстенә тиз-тиз генә тактлар катырып, эскәмия сымак утыргычлар һәм сәхнә кебек нәрсә дә әмәлләп куйдылар, яктырак булсын өчен өстәмә ут тарттылар. Шулай итеп, импровизацияләнгән «тамашачы залы» күз ачып йомганчы әзер булды. Кич җитү белән авылның җыр-моңга сусаган ире-хатыны, яше-карты, бала-чагасы ашыга-ашыга шушы «залга» концерт карарга агылды. Эскәмияләр җитмәгәч, басып тыңлаучылар да байтак иде.

Менә «сәхнәгә» ыспай киенгән, төз буй-сынлы, бөдрәләнеп торган чәче, чем-кара чәчле, күз явын алырдый матур Рәшит Ваһапов чыгып басты һәм үзенчәлекле тавышы белән моңлы җыр сузып җибәрүе белән халыкны таң калдырды. «Әллүки», «Әлфия», «Зиләйлүк» һәм аның репертуарында булган татар халкының һәм композиторларының башка күп санлы әсәрләрен, озын көйләрен Рәшит зур осталык белән башкарды. Ул заманда микрофон юк иде, шуңа искиткеч талант иясе барлык җырларын «тере» тавышка җырлады, халык аны әсирләнеп, тын да алмыйча тыңлады, һәрбер чыгышын алкышларга күмде. Концертта Рәшит Ваһапов белән Җәваһирә Сәлахованың дуэт булып җырлаулары да бик җылы кабул ителде. Аларның бергәләп «Галиябану», «Зөләйха», «Мәрфуга» һәм тагын берничә җырны бик матур башкарганнары әле дә колагымда яңгырый сыман.

Сүз уңаеннан, бер кызыклы мизгел әле дә хәтердә тора. Концертны алып баручы конферансьеның (фамилиясе истә түгел): «Нишлим икән бу хатынны, кыз таба да, кыз таба?! Әй син димен моның хакта докторга барып кара!», – дигән шигъри юлларына каршы алдагы рәттә утырган билгеле бер җитәкче авылдашыбызның: «Мин дә бит хатыныма шул турыда сөйләп торам!» – дип сикереп торып диюе булды, халык дәррәү килеп кычкырып көлеп җибәрде.

Кыскасы, әлеге концерт Пожар халкы өчен, чын мәгънәсендә, олы бәйрәм булды. Вакыт төнгә якынлашуга, иртән эшкә барырга кирәк булуга карамастан, шактый озакка сузылган концертны тамашачылар ахырына кадәр карады, шатлыклы минутлар бүләк иткән өчен сөекле артистларына рәхмәт сүзләре белдерде.

Ә концерт беткәч, Казан кунакларын мин үзебезгә кунарга алып кайттым (элек артистларны теләгән кеше шулай кунарга алып китә иде), чөнки Рәшит Ваһаповның авылдашы, дусты, укытучы Әнвәр Ташбулатов минем тормыш иптәшем Әнвәрнең дә якын дусты иде. Өйгә кайтып ашап-эчкәч, әле озак вакыт төрле темаларга сөйләшеп утырдык. Танылган артист булса да, Рәшиттә берниндиә дә масаю, мактану сизелмәде, хәтергә ул гап-гади, үтә дә тыйнак, ачык күңелле, аралашырга рәхәт булган ягымлы кеше буларак уелып калган.

Сәхнә кешеләре бертуктаусыз юлда бит, икенче көнне иртә белән хөрмәтле якташыбыз җитәкләгән төркемне инде бүтән авылга, гастрольләрен дәвам итәргә озатып калдык.

Рәшидә ӘХМӘТҖАНОВА.
Кочко-Пожар.
«Туган як» газетасы.

● Сулдан уңга: беренче рәттә – Ләлә Шиһабетдинова, Зәйтүнә Ваһапова, Сайра Сәлахетдинова; икенче рәттә – Рәшит Ваһапов, Әзәл Янудин, Гали Җәмлиханов.

● Рәшит Ваһаповның концерт бригадасы. 1958 ел.

МК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

22 апрель – «Сәфәр» (А.Шакиров).
23 апрель – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
24 апрель – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
25 апрель – Шәрык клубында 15.00 – балалар өчен рәсем дәресе. 18.00 – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
26 апрель – 11.00, 14.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 18.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
28 апрель – «Көл» (К.Митани).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

23 апрель – «Турандот» (Дж.Пуччини).
25, 26 апрель – «Коппелия» (Л.Делиб).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

21 апрель – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (А.Бикбулатов, Й.Миңнуллина, Э.Дусаева, М.Гафурова).
22 апрель – 11.00, 13.00 – «Татар теле – сәхнә теле» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
23 апрель – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
24 апрель – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
25 апрель – «Аферист» (Н.Исәнбәт).
26 апрель – «Полиционер» (И.Зәйниев).
28 апрель – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

21 апрель – «Рөстәм маҗаралары» (Гадел һәм Рөстәм Кутуйлар әсәре, А.Әхмәдиев инсценировкасы).
22 апрель – «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла).
23 апрель – «Гөлчәчәк» (Татар халык әкиятенә нигезләнгән).
24 апрель – «Йосыф» (Кол Гали).
25 апрель – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.30 – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
26 апрель – «Микулай» (М.Гыйләҗев).
28 апрель – «Камыр батыр» (А.Җитковский инсценировкасы).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

21 апрель – «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков).
22 апрель – зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятенә нигезләнгән). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
23 апрель – фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Кәҗә белән сарык» (Г.Тукай).
25 апрель – «Әкият» театры буйлап экскурсия.
26 апрель – зур залда – «Волшебные сны Апуша» (Р.Бохараев). Кече залда – «Кәҗә белән сарык» (Г.Тукай).
27 апрель – зур залда – «Волшебные сны Апуша» (Р.Бохараев). Кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай).
28 апрель – зур залда – «Конек-горбунов» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Әлфия» (И.Зәйниев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

21 апрель – Татарстан Республикасы филармония джаз оркестры һәм Денис Мажуковның атаклы Элвис Преслига багышланган концерты.
22 апрель – 14.00 – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский). 18.00 – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
23 апрель – 14.00 – «Спящая красавица» балеты (П.Чайковский). 18.00 – «Жизель» балеты (А.Адан).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

21 апрель – Татарстан Республикасының Миләүшә Тәминдарова җитәкчелегендәге камера дәүләт хоры концерты.
23 апрель – 12.00 – «Шәрык әкиятләре» музыкаль кичәләр шәлкеменнән «Шүрәле» әкияте. 17.00 – Татарстан Республикасы кыллы квартетының «Язгы фантазия» дип исемләнгән концерты.

Планетаның үпкәсе

Кислород эшләп чыгарып, углекислый газны йотканга, күп кеше нәкъ менә урманны планетаның үпкәсе, дип саный. Чынлыкта исә безне кислород белән тәэмин итүдә һәм углеродны йотуда Бөтендөнья океанының әһәмияте күпкә зуррак. Агач һәм үсемлекләр барлык кислородның нибары 20 процентын җитештерә, калган 80 проценты белән исә безне океанда яшәүче фитопланктон тәэмин итә. Нәкъ менә фитопланктон һәм океанның тулаем экосистемасы эше нәтиҗәсендә Җир атмосферасы артык тиз җылынмый. Әмма кешелек, нефть суыртып, балык тотып һәм пластик белән пычратып, аны әкренләп һәлак итә. Океан углеродны йота һәм аны бик тирәндә саклый. Ул кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә һавага чыгарылган барлык углеродның 30 процентын үзенә ала. Әгәр Бөтендөнья океаны булмаса, планета бик тиз кайнарланыр һәм яшәү өчен яраксызга әйләнер иде. Диңгез суында углерод молекулалары башка химик кушылмаларга әйләнә яки фитопланктон өчен азык булып тора. Шул беркүзәнәкле суүсемнәр һәм цианобактерияләр ашаган молекулалар кислород һәм углеродка бүленә. Кислород суга кире кайтарыла, ә углерод фитопланктонда туплана. Әгәр океан углеродны йотудан һәм туплаудан туктаса, глобаль җылынуны берничек тә киметеп булмаячак. БМО мәгълүматлары буенча, дөнья океанының инде 40 проценты кеше гамәлләреннән зур зыян күргән. Һәр минут саен диңгезгә бер йөк машинасы пластик килеп эләгә, дип санала. Шулай дәвам итсә, 2050 елга океанда пластик балыктан күбрәк булачак. БМОга ышансак, бүген эре балыклар популяциясенең 90 проценты тотылып бетә язган, мәрҗән рифларының 50 проценты юкка чыгарылган.

(“РБК”).

Канәфер чәйнисеңме?

Бу дөньяда файдалы һәм зыянлы гына түгел, шактый сәер гадәтләр дә бар. Мәсәлән, канәфер бөресен чәйнәү. Мондый “сагыз” Һиндстанда берничә гасырдан бирле популяр ул үзе, хәзер исә Европада да әлеге тренд бик актив мактала. Нигә дисезме? Әгәр көн саен ике-өч канәфер кадагын чәйнәп йотсаң, организмда уңай үзгәрешләр башлана икән. Канәфер мае ашкайнатуны яхшырта, эч күбенүдән саклый. Иртән күңел болганса, 10 минут канәфер бөресен чәйнәү җитә, әмма йөкле вакытта аны кулланудан тыелу мәслихәт. Бавыр эшчәнлеген дә яхшырта. Көчле йогышсызландыру үзлегенә ия әлеге бөреләрне чәйнәү үртларны сәламәтләндерә, авыздан килгән тәмсез исне бетерә – стоматологиядә канәфер мае хәтта вакытлыча пломба составына да керә. Канәфер чәйнәп йоту иртән хәтта каһвәдән дә шәбрәк дәртләндерә, чөнки организмдагы матдәләр алмашын тизләтә, әмма бу киңәштән кан басымы нормада булганнар гына даими файдалана ала. Канда шикәр микъдары аз булган кешегә исә саклану мәслихәт: канәфер мае глюкоза эшләнүне киметә, шунлыктан гипоглекимия тагын да көчәергә мөмкин, хәтта аңны да югалту ихтимал. Канәфергә аллергия очраклары да шактый.

(“Лента.ру”).

Йоклаткыч йога

АКШтагы Гарвард университеты галимнәре йокысызлыктан коткара торган махсус күнегү булуын раслаган. Бу – “4-7-8” дип йөртелә торган сулыш техникасы, ул бер минут эчендә йокыга китәргә булыша. Башта 4 секунд буена борын аша суларга, аннары 7 секунд суламый торырга, аннары 8 секунд авыз белән суларга кирәк икән. Йокы килгәнче, шулай кабатлау зарур. Галимнәр әйтүенчә, әлеге ысулны һинд йогалары медитация процессында куллана. Экспертлар басым ясый: югарыда сурәтләнгән ритм буенча сулау кешенең нерв системасын кыска вакыт эчендә тынычландырырга сәләтле. Шуңа алар әлеге сулыш күнегүен төнлә йокыга китәр өчен генә түгел, бәлки стресстан, күңелгә ятышсыз хисләрдән котылу өчен дә кулланырга киңәш итә.

(“Die Presse”).



Озын-озак марафон

20 яшьлек Сидзо Канакури (1891-1983), Япониядә марафон дистанциясен иң тиз йөгерүче буларак, 1912 елда Стокгольмда уза торган Олимпиадага җибәрелә: башта корабта йөзә, аннары Транссебер магистрале буйлап поездда бара – өч атна вакыт сарыф итеп, Швециягә уеннар башланырга дүрт көн кала гына барып җитә. Канакури йөгерешкә үз системасы буенча әзерләнә торган була – дистанциядә бик каты тирләмәс, шул ук вакытта сусызлыктан да интекмәс өчен, үзе эчәсе суның күләмен төгәл билгели, әмма бу юлы ялгыша. Европага озак юл, гадәти булмаган ризык, 30 градуслы эсселек, ташлы трасса үзенекен итә – 33 нче чакрымда Сидзо трасса янындагы бер йортның ишеген шакый һәм эчәргә сорый. Хуҗа су алып килгәнче, аруы соң чиккә җиткән спортчы шунда ята да, йокыга китә һәм бер тәүлектән соң гына уяна. Шулкадәр оялә ки, ярышны оештыручылар күзенә күренмичә, ватанына кайтып китә. Трассада юкка чыккан катнашучыны эзләүче дә булмый – ул заман өчен бу бер дә гаҗәп түгел. Тәүге Олимпиадасындагы уңышсызлыкка карамастан, Сидзо спортны ташламый. 1916 елгы Олимпия уеннарында катнашырга тиеш була, тик аларны сугыш барганга үткәрмиләр; 1920 елны ул 16 нчы булып килә; 1924 елда тагын бер мәртәбә катнаша. Япониядә Канакурины бик хөрмәт итәләр, “марафон атасы” дигән кушамат тагалар. 1967 елда исә йөгерешчене швед журналистлары эзләп таба һәм беренче марафон дистанциясен төгәлләргә кызыктыра. 76 яшьлек спортчы бик теләп ризалаша, калган 10 чакрымга якын араны йөгереп үтә һәм 55 ел элек барып җитәргә тиешле финишында тәмамлый. Рәсми нәтиҗә теркәлә: 54 ел, 8 ай, 6 көн, 5 сәгать, 32 минут, 20 секундка сузыла бу марафон. Сидзо журналистларны: “Бик озын марафон булды бу. Мин өйләнергә, алты бала атасына, ун оныкның бабасына әйләнергә өлгердем”, – дип көлдерә.

(“Чемпионат.ру”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

24 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ ДИМӘ». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Акыл батл».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Равил Тумашев турында телеочерк. 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
18.20, 21.25 «БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ». 16+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
0.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА 2». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ЛЮДМИЛА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
22.40 «Большая игра». 16+
23.40 Подкаст.лаб «АстроУмные». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Ольга Фирсова.
7.35 «Шигирский идол».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 Спектакль «Дамы и гусары».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.50 XX век. «Сахалинские страницы».
12.15, 14.20 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 «Аттракционы Юрия Дурова».
13.25 Линия жизни. Александр Ксандров.
14.35 «ЛЕТНИЕ ГАСТРОЛИ».
15.55 «Агора».
17.15 «Тунис. Дворец Эссаада».
17.50 Оркестры России. Академический симфонический оркестр Московской государственной академической филармонии.
18.45 «Формула невероятности академика Колмогорова».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Алексей Вульфов. «Как железные дороги помогали развитию христианства, культуры и цивилизации в нашей стране».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Больше, чем любовь.
21.45 «Сати. Нескучная классика...»
22.30 «Последнее путешествие викингов».
23.20 «САС. Те, с которыми я... Екатерина Васильева».

«НТВ»

4.40 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.15, 0.00 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ». 16+

Сишәмбе

25 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «КИТӘМ ДИМӘ». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
15.45 «Татар сүзе». 6+
17.30 «Трибуна «Нового Века». 16+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Әнгам Атнабаев турында телеочерк. 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 21.25 «БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ». 16+
22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЮДМИЛА». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА 2». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Легкие деньги». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Алексей Ухтомский.
7.35, 14.15 «Математика и подъем цивилизации».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 Спектакль «Дамы и гусары».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.50 XX век. «XX век в кадре и за кадром. Юрий Яковлев».
12.15 Дороги старых мастеров. «Магия стекла».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 «Чародей. Арутюн Акопян».
13.30 «Игра в бисер» «Поэзия Беллы Ахмадулиной».
15.05 «Война Нины Сазоновой». Рассказывает Юлия Пересильд.
15.20 «Сати. Нескучная классика...»
16.05, 22.30 «Последнее путешествие викингов».
17.15 «Эрмитаж».
17.45 Оркестры России. Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского.
18.45 95 лет со дня рождения Юрия Яковлева. Острова.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Денис Прудник. «Как космос облегчает нам жизнь?»
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.45 «Белая студия».
23.20 «САС. Те, с которыми я... Екатерина Васильева».

«НТВ»

4.35 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.15, 0.00 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ». 16+

Чәршәмбе

26 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30, 0.50 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ ДИМӘ». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00, 0.25 «Каравай». 6+
11.30 Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен тапшыру тантанасы.
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00, 14.45 «И, туган тел...» Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәменнән турыдан-туры трансляция.
15.00 «Татар сүзе» нәфис сүз телевизион бәйгесенең гала-концерты. 6+
18.00 «Татарлар». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00, 0.00 «Соотечественники». 16+
22.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Сөй гомерне!» 6+
10.40 «Мин Тукайга киләм». Зәһрә Сәхәбиева. 6+
11.30, 21.25 Туган тел көненә һәм Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулуга багышланган тантана. 6+
13.00 «Галәм илчесеннән хәбәр бар». Габдулла Тукай турында телеочерк. 16+
14.00, 18.20 «И, туган тел...» Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәменнән турыдан-туры трансляция. 6+
15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
15.25 «Татар сүзе» нәфис сүз телевизион бәйгесе. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЮДМИЛА». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЧАО, ФЕДЕРИКО!» 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Письма». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Лидия Зверева.
7.35, 14.15 «Математика и подъем цивилизации».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «МЫ, НИЖЕПОДПИСАВШИЕСЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.50 XX век. «Авторский вечер композитора Евгения Крылатова в Колонном зале Дома Союзов».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 «Царица над царями. Ирина Бугримова».
13.30 Искусственный отбор.
15.05 «Война Анатолия Папанова». Рассказывает Андрей Мерзликин.
15.20 «Белая студия».
16.05, 22.30 «Последнее путешествие викингов».
17.15 «Библейский сюжет».
17.50 Оркестры России. Государственный академический симфонический оркестр России имени Е.Ф. Светланова.
18.40 «Фёдор Тютчев. Записка царю».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Глеб Запальский. «Гид по русскому монастырю XIX века».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.45 Власть факта. «Пропаганда в период наполеоновских войн».
23.20 «САС. Те, с которыми я... Алексей Герман».

«НТВ»

4.35 «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.15, 0.00 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ». 16+

Пәнҗешәмбе

27 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ ДИМӘ». 16+
10.00, 0.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Соотечественники». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 21.25 «Таз малай, әкиятче бабай - Хәли Җәләй». Хәлим Җәләлов турында телеочерк. 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20 «Аклык турында җыр». Зәһрә Сәхәбиева турында телеочерк. 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
23.10 «Кәмит Җәвит». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЮДМИЛА». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЧАО, ФЕДЕРИКО!» 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Илья Старинов. Личный враг Гитлера». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Анатолий Кони.
7.35, 14.15 «Планеты. Ледяные миры».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «МЫ, НИЖЕПОДПИСАВШИЕСЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «Звезды русского балета».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 «Профессия - Кио».
13.30 Абсолютный слух.
15.05 «Война Зиновия Гердта». Рассказывает Евгений Ткачук.
15.20 Юбилей Анны Каменковой. Эпизоды.
16.05, 22.30 «Последнее путешествие викингов».
17.15 Моя любовь - Россия! «От кокошника до шугая - мир русской старины».
17.40 Оркестры России. Национальный филармонический оркестр России.
18.45 Острова. Валентин Серов.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Анастасия Астафьева. «Для особого случая».
20.35 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 90 лет Леониду Рошалю. Линия жизни.
21.45 «Энигма. Ольга Перетятько».
23.20 «САС. Те, с которыми я... Алексей Герман».
23.50 XX век. «Звезды русского балета».

«НТВ»
4.45 «ПЛЯЖ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.15, 0.00 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ». 16+

Җомга

28 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КИТӘМ ДИМӘ». 16+
10.00, 22.10 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
23.10 «ЖАНДАРМ В НЬЮ-ЙОРКЕ».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 15.25, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Уроки истории». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Өзелеп җырлый торган җыр булса». Рафаэль Ильясов концерты. 6+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЛЮДМИЛА». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ВЛЮБИТЬ И ОБЕЗВРЕДИТЬ». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Война и мир Михаила Калашникова». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
20.00 «ЛЕОНАРДО ДА ВИНЧИ. НЕИЗВЕДАННЫЕ МИРЫ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.55 «Вызов. Первые в космосе». 12+
0.55 Подкаст.лаб «20 лет спустя». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.20 «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ». 12+
23.25 «Я ПОДАРЮ ТЕБЕ РАССВЕТ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Ирина Головкина.
7.35, 14.10 «Франция. Путешествие во времени».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «МИЛОСТИВЫЕ ГОСУДАРИ».
10.15 «ПРАЗДНИК СВЯТОГО ИОРГЕНА».
11.35 «Первый среди равных. Анатолий Кторов».
12.20 Цвет времени. Марк Шагал.
12.45 Открытая книга. Анастасия Астафьева. «Для особого случая».
13.15 «Первые в мире».
13.30 Власть факта. «Пропаганда в период наполеоновских войн».
15.05 «Война Владимира Этуша». Рассказывает Виктор Добронравов.
15.20 «Энигма. Ольга Перетятько».
16.05 «Последнее путешествие викингов».
17.15 Письма из провинции.
17.45 Оркестры России. Государственный академический симфонический оркестр Республики Татарстан.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «Тайна ожившего портрета».
20.35 К 65-летию Геннадия Красникова. Линия жизни.
21.30 «ФОРМУЛА ЛЮБВИ».
23.00 «2 Верник 2».
23.45 «ТАТУИРОВАННАЯ РОЗА».

«НТВ»
4.50 «ПЛЯЖ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.15 «БЫК». 16+

Шимбә

29 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Синә Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казаннан- казанга». 16+
12.00, 22.00, 0.10 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Татар халык җырлары». 12+
15.25 «Татар сүзе». 6+
15.30 «Әйдә, шаяРТ!» 16+
17.00 «Ватандашлар». 16+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.30 «ЖАНДАРМ ЖЕНИТСЯ».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Габәши язмышы». 16+
7.00, 15.10 «Синә Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Очрашулар эзләп» Габделфәт Сафин концерты. 16+
17.20 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Язмышларым сиңа бәйләнгән». Рөстәм Закиров һәм Люция Мусина концерты. 16+
22.45 Спектакль «Гөлҗамал». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «МИР ДЛЯ ДВОИХ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОПАСНОЕ ЗАБЛУЖДЕНИЕ». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Офицеры». 12+
15.45 «ПРОЩАТЬСЯ НЕ БУДЕМ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СПИСОК ЕЕ ЖЕЛАНИЙ». 12+
22.45 «ТОРН: СОНЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «ПроУют».
12.15 «Видели видео?»
14.00 «Рюриковичи». 16+
18.20 «Кто хочет стать миллионером?»
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «ЭЙФЕЛЬ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «ТОКСИЧНАЯ ЛЮБОВЬ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ОЧЕНЬ ПЛОХАЯ НЕВЕСТА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.30 «Либретто». Л. Делиб «Коппелия».
7.45 «ДОЖДЬ В ЧУЖОМ ГОРОДЕ».
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ФОРМУЛА ЛЮБВИ».
11.40 Исторические курорты России. «Липецкие воды».
12.10 «Даты, определившие ход истории».
12.50 «Все краски мира».
13.40, 22.55 «Три минуты тишины».
13.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.15 «ПОДКИДЫШ».
16.25 «Театр имени Моссовета. По-прежнему вместе...»
17.25 Спектакль «Шекспиргамлет».
19.45 «Романтика романса».
20.50 «ДЕВУШКИ ИЗ РОШФОРА».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
5.15 «Военно-исторические маршруты». 16+
5.30 «ПЛЯЖ». 16+
7.20 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Страна талантов». 12+
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.35 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

30 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Халкыбыз мирасы». 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Сәләт».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.15 «Сөенеч».
11.30 «Тархан». 12+
12.00, 17.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
13.55 «Татар сүзе». 6+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.45 «Батырлар». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ОГРАБЛЕНИЕ ПО-БЕЛЬГИЙСКИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Музыкаль мәйдан». 16+
8.00 «Яшәү көче килә җырыңнан». Мансур Шиһапов. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Габәши язмышы». 16+
14.50 «Күңелемдә яз». Георгий Ибушев концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Мирас - Наследие». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Планета Ай».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «ПРОЩАТЬСЯ НЕ БУДЕМ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПУТЬ К СЕРДЦУ МУЖЧИНЫ». 12+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «МИР ДЛЯ ДВОИХ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПАДЕНИЕ ТОКИО». 12+
22.45 «ЛЕОНАРДО ДА ВИНЧИ. НЕИЗВЕДАННЫЕ МИРЫ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.00 «Рюриковичи». 16+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 Международный конкурс песни на русском языке «Автора!» 12+

«РОССИЯ»
6.15 «ЛИЧНЫЕ СЧЁТЫ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Большие перемены».
13.05 «Петросян-шоу». 16+
15.00 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА».
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
8.10 «ВРАТАРЬ».
9.25 Диалоги о животных.
10.10 «СТАРШИЙ СЫН».
12.20 Невский ковчег. Теория невозможного. Феодосий Яновский.
12.50 «На холстах лета».
13.30 Юбилейный концерт Государственного академического Воронежского русского народного хора им. К.И. Массалитинова.
14.30, 23.10 «Три минуты тишины».
14.35, 23.15 «ФЛИБУСТЬЕР».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 Больше, чем любовь.
17.55 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА».
19.30 Новости культуры.
19.45 «КРАСАВЕЦ-МУЖЧИНА».
21.50 Пятая церемония вручения Международной профессиональной музыкальной премии «BraVo».

«НТВ»
4.55 «ПЛЯЖ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+

БАШКАЕНА БӘЛА ТАПКАН

Җинаятьчеләр башкаларга зыян салу гына түгел, үзләре дә михнәт чигә. Явызлыклар өчен җавап тотарга, җәза үтәргә дә кирәк бит. Еш кына алар ошбу бәлане эзләп таба дигән фикер дә туа.

Узган ел җәендә Чистайда яшәүче 1992 елгы Илнур Нургатин алты җинаятьчел гамәл кылып куя. Моңа гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки төрмә сукмагын күп таптаган кеше ул. Шулай да яңа иреккә чыккан тәҗрибәле рецидивистның, чынлыкта, үтеп барышлый юл уңаенда эшләнгән ахмаклыклары сәер тоела.

И.Нургатин җинаятьчелек юлына бала вакытында ук баса. 2007 елда, үзе кебекләр белән урлашкан өчен, хәтта өч мәртәбә суд каршына бастырыла, бары тик 14 яшендә генә булуы исәпкә алынып, колония урынына ике ел ярымга ябык типтагы тәрбия оешмасына җибәрелә, шунда урта һөнәри белем ала. Явыз малайлар белән бер түбә астында яшәү уңай йогынты ясаган дип булмастыр, чөнки аннан кайтып 18 яше тулгач ук, Илнур төркем белән талауда (разбой) катнаша, зарар күрүче саулыгына авыр зыян китерелә һәм 6 елга Түбән Камадагы колониягә утыртыла, аннан соң урлап тотыла, тагын бер елга иреккннән мәхрүм ителә. Бусы да акыл өстәми, билгеле. Күп тә үтми көч кулланып талау дигән җинаяте өчен ел ярымга колониягә озатыла. Шулай итеп, быелтыр 29 яшендә иреккә чыккан егет ярты гомерен япкынлыкта уздырган була инде. Чистайга кайтып, 14 яшькә өлкәнрәк абыйсы Радик белән икесе бер фатирда яши алар. Илнурның әйтүенчә, шабашкаларга йөреп тамак туйдыралар, ләкин аның 2022 елда кылган гаиләмәтләре яшәү рәвешләре башкачарак икәнен күрсәтә.

Беренче очрак «бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигән әйтемне искә төшерә. Ул көнне урта яшьләрдәге Е.Шәйдуллин, әйтүенчә, үзе генә бер яртыны бушаткач, велосипедына атланып һава суларга чыга. Исереклеге аркасында алга табаниләр булганын, өенә ничек кайтканын да хәтерләми, сәпитнең юкка чыгуын иртә белән генә күрә, файдасы булмас дип, полициягә хәбәр итеп торуны кирәк тапмый. Чынлыкта, әллә ни ерак китә алмыйча юл читенә мәтәлгән, күрәсең, исереклеккә бирелү-сугылуның тискәре йогынтысы да өстәлгәч, урыныннан кузгала алмыйча, татлы йокыга талган. Салмыш килеш шул тирәдә буталып йөргән И.Нургатин күктән төшкән табыш янынннан битараф үтеп китә алмыйча, юлын ике тәгәрмәчле транспорт чарасына атланып дәвам иттерә, аны үз йортлары янындагы ташландык сарайда саклый, ара-тирә утырып та чыккалый.

Көпә-көндез урам уртасында кылынган ошбу бурлыкның шаһитләре була, әлбәттә. Әйтик, шул мәлдә машинада үтеп барган парлылар күреп кала, берничә көннән ир-егет танышы Илнурга «Стингер»ны урынына илтеп ташлап, бәладән котылырга да киңәш итеп карый, ләкин тыңламый аны хөрәсән, авылга алып барып сатачагы турында сөйләнә. Соңрак абыйсы Радикта энесенең велосипед алып кайтуын әйтә. Ләкин урланган әйберне акчага әверелдерергә өлгерми ул. Хәбәрләр участок инспекторына барып җиткәч, сарайдагы сәпит алына, төп шикле бәндә мәгълүм булса да җинаять эше соңрак, көпчәкле мөлкәтнең хуҗасы ачыклангач кына кузгатыла. Ә ул 10 июньдә интернеттагы сайтта велосипедының фотосын күргәч, аны әчке эшләр бүлегендә икәне әйтелгән игъланны укыгач барып керә анда, каракны җавапка тартуны сорап язылган гариза калдыргач, ай буе күрмәгән «Стингер»га утырып өенә кайта ир-ат.

Полиция экспертлары велосипедтагы кул-бармак, сарайдагы аяк киеме эзләрен алып тикшергән булалар, аларны үзләренә яхшы мәгълүм рецидивист калдыруы расланса да, гаебен танымый ул, юл читендә чакта велосипедка кагылдым, сарай яныннан үтеп киткәнем булды дип урлашуга катнашы булуын кире кага. Ләкин урлау очрагы буенча җинаять эше кузгатыла.

Ул чакта аның тагын бер угрылыгын тикшерү бара. 2 июньдә кич белән өенә кайтып кергән 1959 елгы ханым бер тәрәзәсе ачыграк икәнен күрә, яба башлагач, аның каерылган булуын ачыклый да, әйберләрен барларга керешә һәм 14 кило карабодай тутырылган капчыкның һәм суыткычтагы өч кило туралган йорт куяны итенең юкка чыгуын белә. Полициядә 2030 сумлык азык-төлеген чәлдерүчеләрнең күршедә яшәүче Нургатиннар эше икәнен шикләнмәвен дә әйтә ул, чөнки берничә көн элек Радик, Илнур һәм аларның Илгиз атлы тагын бер агайнесенең, аның ягына ымлап, шикле әңгәмә коруларын ишетеп шөбһәгә төшкән була.

Полиция Нургатиннар фатирында шул ук төндә тентү үткәрә, куян ите алына, ярмалы ак капчык табылмый. Эксперт ханым суыткычындагы бармак, тәрәзә төбендәге кроссовка эзләрен алып тикшерә, аның нәтиҗәләре тагын И.Нургатин файдасына булмый. Әмма тәҗрибәле төрмәче акны кара дип раслауны кулай күрә. Ягъни минем аяк киемен теләсә кем кияргә мөмкин, суыткычка күрше хатыннан ит алырга кергәндә кагылганым булды дип ошбу дәлилләрне кире кагып маташа.

Әлеге каракълыкта катнашкан зат булып танылу куркынычы туган Радик башка төрлерәк сөйли. Аның күрсәтмәләренә караганда, кичкә хәтле ишегалдында аракы-сыра белән сыйланып утыра алар, бер мәлне исерек энекәше беренче каттагы бераз ачык калдырылган тәрәзәне каерып эчкә керә, абыйсы кисәтүләренә колак салмый, өйләренә итле төргәк, ярмалы капчык тотып кайта, карабодайның юкка чыгуын, үзе йоклап ятканда, энесе сатып өлгергәндер дип фаразлый ул. Тикшерү барышында И.Нургатинның әлеге каракълыгын гади урлашу гына түгел, абыйсы кисәтүләрен санга сукмавын исәпкә алып, ачыктан-ачык урлау, икенче төрле әйткәндә, талау дип бәяләнә һәм РФ Җинаять кодексындагы кырысрак җәза каралган маддә кысаларына кертелә.

Инде ике җинаятьтә гаепләнсә дә, туктарга уйламый сәрхүш. 6 августта шул тирәдә торучы Айрат гаражындагы тимерчыбык, машина ачкычлары, электр моторы, мангал, су савытлары һәм башка әйберләр югалуын, исәпләп карагач, 4250 сумлык мөлкәте чәлдерелүен ачыклый. Оперативникларда И.Нургатинга шик төшми калмый. Тиздән гараж идәнендәге эзләрнең аныкы икәне раслана, абыйсы Радик та шул көннәрдә энесенең тимер-томыр илтеп тапшырырга ярдәм итүен соравын әйтеп тора, булыша алмадым дип, әлеге эшкә дә катнашмавын белдерә. Илнур исә бу юлы да гаебен кире кага, ләкин җинаять эшендә өченче эпизод пәйда була.

Тәҗрибәле кеше итәгенә ут капканын аңласа да, туктый алмый, күрәсең. 12 июльдә тагын бер җинаять эшләп өлгергән була. Ул көнне 40 яшендәге Андрей аерылышкан, әмма аратирә аралаша торган хатынын эзләп йөри, аның Нургатиннар йортындагы фатирда яшәүче хатын-кыз белән салып йөри торган гадәтен белгәнгә, шул якларда сорашып йөри һәм ишегалдында шашлык кыздырып аракы эчү белән мәшгуль агайнеләр белән дә очраша. Әлеге әңгәмә бик тиз сүгенеп кычкырышуга әверелгәч, кигү ягына борыла, күп тә үтми пычак тоткан яшьрәк ир-атның артыннан чабуын күрә ул. Андрей явыз кулындагы пычакны тартып ала, ләкин бармаклары киселә, ашыгыч ярдәм һәм полиция чакырырга туры килә. Алар килеп җиткәндә, тегеләр юкка чыгып өлгерә. Ләкин полициягә баргач, оперативник Андрей каршына Илнур Нургатин фотосын куя, Андрей аны танып гариза яза. Бармаклардагы җәрәхәтләр сәламәтлеккә җиңел зыян китергән булып чыга. Дүртенче җинаять эше үтерү белән янаган өчен кузгатыла.

Санап үтелгән явызлыклар законда авыр җинаять саналмый. Ә менә 29 июньдә 14 яшьлек кызга карата эшләнгән кылынмышлары өчен бик кыйммәт түләргә туры киләчәк аңа.

Кичкә таба шушы юньсезгә очраган Милана (исеме үзгәртелә) – катлаулы язмыш баласы. 2007 елда Чита өлкәсендә туа ул, аңа 4 яшь чакта, эчкече әнисе аналык хокукыннан мәхрүм ителә, шуннан соң этисе белән Татарстанга күченеп кайталар, Чистай, Әлки районнарында торалар, 2021 елда икәүләп Казанда яши башлыйлар. Юньле ата белән мохтаҗлык күреп үсми кыз, туганнары да ярдәм итеп торалар. Узган ел җәй көннәрендә 9 нчы сыйныфка күчкән яшүсмер әнисенең бертуган сеңлесе Алия янында Чистайда була, 29 июньдә аның рөхсәте белән урамга чыга.

Кичке сәгать сигезләр тирәсендә «Кама яры» паркыннан чыгып барганда, бер исерек ир-ат аңа бергәләп сыра эчеп утырырга тәкъдим ясый, кыз баш тарткач, артыннан бара, бер төркем яшьләр күренгәч, арткарак калса да, бераздан куып җитеп эләктереп ала. Соңрак үткәрелгән медицина тикшерүе Милана тәнендә сәламәтлеккә зыяны тимәгән дип саналган бик күп җәрәхәтләр булуын ачыклый. Кызның әйтүенчә, алар тарткалаша, җиргә егылып әүмәкләшкән чаклары да була хәтта, бер мәлгә ычкынып киткән арада «112» телефонына шалтыратып хәбәр итәргә өлгерә, ләкин «Чистай» сәүдә үзәге янында артыннан җитеп, тегe бәндә аппаратны тартып ала. Әлбәттә, агачлыкка таба киткән кеше артыннан калмыйча телефонны кире бирүен таләп итеп кычкырып бара кыз, ахыр чиктә, күрәсең, кеше күзенә чалынудан шүрли башлап, явыз бәндә телефонны куаклыкка ыргытып юкка чыга. Милана аны көч-хәл белән эзләп таба.

Шул арада полиция экипажы килеп туктый, әчке эшләр бүлегендә дүрт ир-ат, шул исәптән, И.Нургатин фотосын күрсәткәч, кызый аны бик тиз танып ала.

Кыю кыз тарткалашкан вакытта телефондагы диктофонны да эшләткән була. Аудиоязма Нургатин аркасында 17 секунд кына дәвам итә, ләкин анда кызның өч тапкыр «отпустите меня» дип кычкыруы, үзенә 12 генә яшь дип алдагач, тегенең шоколад бирергә җыенуы язылып өлгергән була. Әлбәттә, әлеге дәлил җинаять эшенә теркәлә.

И.Нургатинның бәясе 10 мең сум дип белдерелгән «Редми-9» телефонын талавы бәхәссез. Моны ул үзе дә таный. Аның өчен иң яманы шунда, кыз бала, тарткалашкан вакытта, аның ярамаган урыннарын тотуын, кочуын, муеныннан үбәргә маташуын, куаклыкка алып кермәкче булуын һәм башка гамәлләрен санап үтә һәм, чынлыкта аңа хөкемнең иң кырысын чыгарып куя. Чөнки тикшерү комитетының Чистай районара бүлегеннән Ленара Гыйбадуллина женси рәвештәге башка төрле гамәлләре хакындагы маддә буенча җинаять эше кузгата. Күрәсең, ике атнадан 15 не тутырырга торган кызның үзенә 12 яшь дип әйтүе нәтиҗәсендә, ул әлеге җинаятьне 14 яше тулмаган затка карата кылуда гаепләнә. Әгәр бу судта да расланса, 30 яшьлек иргә 12 елдан 20 елга чаклы иректән мәхрүм ителү яный.

Шулай итеп өч-дүрт ай азатлыкта йөреп калган Илнур Нургатин тагын япкынлыкка әләгә, эзли торгач бәлане таба. Тирә-якталар зур зыянга тарымаса да, аңа хөкем кырыс булачак.

Наил ВАХИТОВ.

Тынгы белмәс язу остасы

Рамазан аенда «Хәзинә» милли сәнгать галереясында дин кардәшләребезнең күңелләрен тагын да нурландырып матур язу остасы, галим, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе Нәҗип Нәккашның шәмаилләр һәм тугралар күргәзмәсе ачылды. Быел җәй күренекле хәттат Нәҗип ага үзенең 75 яшен билгеләп үтәчәк. Әлеге экспозиция – утыз алтынчы шәхси күргәзмә.

Нәҗип агага сокланып туймаслык. Аның кебек күп хезмәт куючы, фән, сәнгать, каллиграфия һ.б. өлкәләрдә эшчәнлек алып барып, зур нәтиҗәләргә ирешүче шәхесләребез күп түгел. Без аның олуг рәссамыбыз Бакый ага Урманчедән дәресләр алганын, 1990 елларда бик катлаулы чорда шәмаил, гарәп каллиграфиясен торгыза башлаганын, «Мирас» журналында бер-бер артлы шәмаилләрен бастырып, укучыларны сөендергәнен һәм осталыгын камилләштергәнен беләбез. Әмма Н.Нәккаш шәмаил, тугра сәнгатьләрен кайтарып кына калмады, татар чигүләрендә кулланылган орнаментлар, төсләр аша, үзенең халыкчан милли стилен булдырды. Нәҗип аганың шәмаилләре республикабызда гына түгел, бөтен Россия буйлап таралып, татар, мөселманнарның өйләрендә түр урынны алды. Шуңа күрә без аны чын мәгънәдә халык рәссамы дип әйтә алабыз.

Әмма Н.Нәккашның таланты кәгазь, пыяла нигезгә генә сыймыйча, мәчет интерьерларындагы бизәкләр, кабер ташларындагы орнаментлар булып та гәүдәләнде.

Күпләребез өчен шәмаил күзне иркәли торган матур рәсем булса, Н.Нәккаш өчен ул – сәнгать әсәре генә түгел, фәнни төгәллек белән башкарылган тирән мәгънәгә ия белем чыганагы. Мондый югарылыкка ул утыз ике ел дәвамында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында урта гасырлар әдәбиятын өйрәнеп-тикшереп ирешә. Ул – чын мәгънәдә энциклопедик белемле шәхес.

Бүген матур язу осталарының күплеген күреп күңел сөенә. Аларның байтагы – Нәҗип аганың шәкертләре. Н.Нәккаш хәтта чит милләт вәкиле булып, үзгә дин тоткан олпат рәссам В.Поповны гарәп каллиграфиясе белән кызыксындыра алды. Бүген Владимир дәдәй – үзе зур оста һәм форсат чыккан саен остазы Н.Нәккашка олы рәхмәтен җиткерә.

Шәкертләрнең байтагы Фәйзрахман улы Нәҗипнең Россия Ислам университеты һәм Татар дәүләт гуманитар институтындагы каллиграфия курсларыннан үсеп чыкты. Әйтергә кирәк, бүген дә күренекле хәттат язу аша яшьләргә мәгърифәт тарату эшен дәвам итә: шәһәребезнең К.Насыйри исемендәге мәктәптә күргәзмәсен оештыру, Казан кооператив институтында ел саен татар шәҗәрәсе бәйгеләрендә жюри рәисе буларак мөнләгән баланың эшен кулыннан үткәрү дисеңме һ.б.

Соңгы елларда Нәҗип Исмәгыйлев татарның танылган дин эшлеклеләре, шагыйрь, язучылары, галим-голәмәга багышлап каллиграфия шәлкемен иҗат итә. Алар арасында олуг шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган иҗат эшләре аерым урын алып тора. Алар өчен рәссамны республикабызның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе белән бүләкләделәр. Эшчәнлекләре пыялада милли төсләр, татар орнаментлары белән сурәтләнгән дин, фән эшлеклеләре, иҗат ияләре арасында Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, К.Насыйри, И.Гаспралы, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, М.Җәлил һ.б. бар.

● Г.Тукайга багышланган шәмаил-плакат.

● Мәҗит Гафуригә багышланган шәмаил-плакат.

● Татнефтьнең элеккеге генераль директоры Ренат Галиевнең тугрысы.

● Шәмаил. Җину.

● Шәмаил. Милләтемә мәхәббәтем.

Н.Нәккаш – үзе эш җанлы шәхес кенә түгел, эшләгән кеше өчен сөенә белүче дә. Бүген рәссамнарыбыз дүрт-биш бүлеккә аерылган, композитор язучыны, шагыйрь музыкантны танымас, санга сукмас хәлгә җиткән заманда, Нәҗип ага милли эчтәлекле бер генә чараны да калдырмый, коллегалары рәссамнарның һәр шатлыгын, һәр сөенечен уртаклашырга тырыша, күп йөри, күпне күрә.

Нәҗип аганың 1990 елларда башлаган эше шул дәрәҗәгә җитте ки, аны яшьрәкләр күтәреп алды, мәсәлән, галим, архитектор, рәссам Р.Шәмсутов Кремльнең йөрәге Кол Шәриф мәчетендә шәмаилләр галереясы ачып, дәһри заманнарда читкә тибәрелгән дини сәнгатебезне кабат түр урынга кайтаруга ирешә. Ни кызганыч, суверенитетыбызга юл ябылган кебек, бүген татар шәмаиле галереясы да ябылды. Әмма ул эшләгән вакытта никадәр яшь иҗатчы гарәп язуын үзенә гомерлек һөнәр итеп сайлады. Шуңа да дини сәнгатебез тарафдарлары барыбер кыйбладан талпылмаячак, шәмаилне түргә кайтару эшен дәвам итәчәк. Н.Нәккашның Кремльнең үзәгендә – «Хәзинә» милли сәнгать галереясындагы шушы күргәзмәсе дә моңа дәлил булып тора.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир
Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:
222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны:
(843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 19.04.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2614

16+